**Киньябулатов И.Л.**

# Урал курае

Шигырьләр, поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Баш)-5
К11

*«Каләмнәр туганлыгы» сериясе*
*1994 елда булдырылды*

**Киньябулатов И.Л.**

Урал курае: шигырьләр, поэмалар / Ирек Киньябулатов; кереш сүз авт. Х.Әюп; башкортчадан тәрҗемә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 367 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01668-1

Күренекле башкорт шагыйре, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М.Өметбаев, М.Гафури, З.Биишева, Ф.Кәрим, Р.Гарипов, С.Чекмарев исемендәге премияләр лауреаты Ирек Киньябулатовның бу китабына төрле елларда иҗат ителгән шигырьләре һәм поэмалары тупланды.

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Баш)-5

ISBN 978-5-298-01668-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Киньябулатов И.Л., 2008

**Шагыйрь гомере — утлы күмер...**

Әйе, бу чыннан да шулай. Күренекле башкорт шагыйре Ирек Киньябулатов шигырьләре белән танышканнан соң моңа ихластан ышанасың, менә-менә җаныңа ут кабар шикелле тоела башлый, бу катлаулы заман шаукымыннан иелә төшкән башларың күтәрелә, күңел күзләреңә яңа бер балкыш сирпелә, һәм инде син берничек тә битараф кала алмыйсың. Югыйсә ул, әллә ни зурдан купмыйча:

Минем гомер — утлы күмер,
Башкаларга тик бер сабак... —

*(«Тик бер кабат»)*

дип кенә язган кебек иде бит! Әнә шулай гади генә сүзләр белән дә йөрәккә үтеп керә белү куәсе хас Ирек Киньябулатовка. Шагыйрьнең әсәрләрен басмага әзерләгәндә, мин моны яхшы тойдым. Каян килә бу сыйфат, тамырлары кайда аның, сәбәбе нидә?

Шигырь мине, үзе эзләп табып:
«Менә хәзер утыр, яз!» — диде.
Өстәп аңа әрнү, сагыш куштым,
Монысы да әле аз иде...

Алар гына аз, бик аз булыр иде, әлбәттә. Һәм шагыйрь үз шигырьләренә тормышны, бөтен дөньяны, халыкның, заманнарның уй-кичерешләрен кушарга алына, моны гомер буена ювелирлар осталыгы белән башкарып та килә.

Һәр туган көн яңа сорау куя,
Мең-мең сорау ала халкымнан.
Әллә дөнья шулай акыл туплый,
Әллә яза булган акылдан?

*(«Елкы елы»)*

Уйларның, кичерешләрнең киңлеген, тирәнлеген сыйдырыр өчен инде өстәл өстендәге кәгазьләр генә җитми башлый:

Йөзең якты, нурлы йөзең балкый,
Җирем — башланмаган ак дәфтәр...

*(«Җирем — ак дәфтәр»)*

Әнә шулай яңа гына кар явып киткән ап-ак җир йөзе, сафлык үзе кулай булыр сыман Ирек Киньябулатов шигырьләрен язар өчен.

Башкорт шагыйрьләре белән байтактан аралашып яшәргә туры килде миңа, кайберләренең китапларын да туган телебездә чыгарырга насыйп булды. Әмма әлегә кадәр бу каләм остасының әсәрләре белән таныш түгел идем. Бик олы байлыктан мәхрүм булып яшәгәнмен икән ләбаса! Менә хәзер дөньям түгәрәкләнә төште, Ирек Киньябулатов иҗатында мин рухи туганымны таптым шикелле.

Шагыйрь Зөлфәт үзенең бер мәкаләсендә шигырь анализларга алынуны гамәлгә яраксыз бер хәл, ахмаклык дип бәяләгән иде. Мин дә, әнә шул ахмаклыкны эшләүдән курка-курка гына булса да, Ирек Киньябулатов шигырьләрендәге көтелмәгән сурәтлелекне, хәтергә кереп урнашу гына түгел, җаннарны әйләндереп сала алырлык сүз куәтен әйтмичә кала алмыйм. Аның шигырьләрендә «көн белән төн бәрелешкәннән чаткы булып кояш чыга», «тоташ кояшны күтәрә әнә агач башлары», «авыры — дөньяның ярасын яралы йөрәктә саклавы». Гади адәм баласы:

Ачсам күзем дөньяга мин —
Сабый кебек кенә.
Ә барласам кичергәнне,
Мең яшь кебек миңа... —

дип юкка гына язмагандыр. Мәңгелек белән, илаһи затлар белән ниндидер бәйләнеше бар аның. Җитмеш ел эчендә (быел шагыйрьгә 70 яшь) мең яшькә җитә алыр идемени ул югыйсә! Шуңа күрә язганнарын үзең күздән кичерергә, ул дөньяга үзең керергә, анда үзең яшәп карарга кирәктер дә.

Бу китапта «Гашыйк Кеше — чын Кеше» исемле тупланма бар. Мәхәббәт шигырьләреннән генә тора ул. Әгәр дә Ирек Киньябулатов каләменнән шундый затлы хисләр гәүдәләнеше агылып төшмәгән булса, аның иҗаты тулы булмас иде кебек, ул үзе дә шундый нечкә тойгылар кичерү белән чын кеше, чын шагыйрь булып җитлегә алгандыр шикелле. Ул шигырьләрне укыганда, сафлык дөньясына чумасың, җаннарың рәхәтләнә.

Чыктым бөтен дөньялардан — сине,
Синнән бар дөньяны эзләргә...

Эзлик һәм табыйк без, китек калдырмыйк яшәешне...

Сүземне утлы күмердән башлаган идем. Күпме күргәнебез бар: утлы күмердән эз кала, янган эз. Шагыйрь гомереннән дә заманага, чорга төшкән эз ярылып ята. Әйдә, сездә дә калсын ул эз: яныгыз-көегез, борчылыгыз һәм шатланыгыз, сөегез һәм сөелегез — әмма бернәрсәгә дә битараф калмагыз. Утлы күмернең тоташ ялкынга әйләнәчәген барыбыз да беләбез. Аның яктысыннан сез дә балкып китәрсез, мин моңа ышанам. Амин, шулай була күрсен!

*Харрас Әюп*

## Җирем

Җирем, мәңге җырлар җырым,
Улың тагын кочагыңда.
Кайттым сиңа. Төннәр буе
Утлар сүнмәс учагыңда.

Көткән мине барчасы да:
Урман, таулар, яшел болын.
Әнә, бала чагым булып,
Чабып килә сабый колын.

Туфрагыңда шул колындай
Очып-җилеп үтсәм иде.
Күреп барын, җирдә булган
Яшәү серен сүтсәм иде.

Алтын бишек диләр сине.
Тирбәт әйдә бишегеңдә.
Син бит минем тел ачкычым,
Җырга чыгар ишегем дә.

## Сагынып кайтам җиремне

Шәһәр урамында
Җир җылысын
Тоймадыммы әллә таш аша?
Туган җирләремә кайтып төштем,
Бер сикергән кебек баш аша.

Басуларым, тугайларым минем,
Һәр сулышым сезгә береккән.
Күңелемә яңа җырлар килә,

Җырларым да җиргә җиреккән...

Кыр җилләре әбәк әйтеп үтә,
Кырда җилне ничек тотасың?!
Җилләр куып мин җиремнән китмәм,
Мин еракта утлар йотмамын.

Әнә алда игенчеләр җыры,
Чыгыйм әле хәзер аръякка.
Баскан көе озаграк торсам,
Тамыр җәяр сыман аяклар...

## Буразна

Тартып тора буразна,
Торсаң иде беразга.

Туфрагы да нур гына,
Күңел күрсә, җыр гына.
Карар күзгә кап-кара,
Шуннан җанга ак бара.

Булмас димен ят холык —
Алам аннан яктылык.

## Тәүге яңгыр

*(Этюд)*

Иркәли дә ялый җирне
И яңгыры!
Ташлар һаман тели кебек:
Мул яугыры...

Чыга үлән күз белән каш
Арасында.
Хәтта кинәт күз өйрәнми,
Карасаң да.
Бөтен дөнья шыпырт кына
Алмашына.
Яңгыр теле көллесенә
Аңлашыла.

Һәр тамчысы такмаксыз да
Биеп тора.
Таулар, шып-шым, яшел җилән
Киеп тора.

## Басу юлы

Басу юлы — минем сабый чагым,
Яшәвемнең тәүге адымы.
Син яшәүгә башлап ут кабыздың,
Хыялларның бетмәс азыгын

Бирдең миңа.
Бүген шул хыяллар

Нинди киңлекләргә юнәлтте!
Белемне мин тугры юлдаш итеп,
Канат иттем гади хезмәтне.

Байрак итеп олы хакыйкатьне,
Таулы-ташлы юллар үтәрмен.
Тормыш, тормыш!
Мин бит басу улы,
Серләреңне әле сүтәрмен!

Юлларымның монда башы гына.
Ә әзермен, әгәр ил кушса —
Кайда кирәк, шунда.
Юллар — миңа,
Мин юлларга юлдаш.
Тик үткенче булмам тормышта...

Басу, синнән әти яуга китте,
Тик әйләнеп кабат кайтмады.
Ә без сине көн дә әни белән
Өмет өзми күпме таптадык!

Хат ташучы әнә узып китте...
Алга килде үткән хатирә:
Шул хәл мәңге онытылмас булып,
Чыкмас булып калган хәтердә.
Күз алдымда тора хәзер дә:
Урак өсте.
Әни арыш ура.
Әзер кебек очып үтәргә.
Төш алдыннан хат ташучы безгә
Әллә нинди хәбәр китергән.

Урган арышмыни — ауды әни,
Их, мин, гамьсез, нигә белмәдем?
Ә шулай да анам кулларыннан
Очып киткән хатны эзләдем.

Таптым.
Аны иң якыным күреп,
Кулны җәеп, җиргә егылдым...
Камыллы кыр шулчак әтиемнең
Яңаклары төсле тоелды.

## Өч торна

Яз язлыгып, ничек соңлап йөри:
Тозлыкүл буенда өч торна...
Сагышлы җыр туа йөрәгемдә,
Ул җыр безнең хакта, өч торна.

Ак кыш үтеп, аккош кайтыр чакта,
Дөнья тагын акка күмелгән.
Ак дөньяга минем кара уй юк,
Кош язмышы авыр күңелгә.

Тозлы, әче күл буеннан очкан
Өч торнаны күрдем үткән көз.
Быел тагын алар өчәү кайткан.

Күлдәй ачы язмыш белән кайткан,
Әйтергә соң кемгә үпкә сүз?
Мондый язмыш кемгә, кемгә үз?
Нигә торна шулай ишсез калган? —
Алардан мин сорап тормадым.
Без, ичмасам, шушы җирдә ялгыз
Яшәтмәсәк иде торнаны.

Их, без кошлар телен белгән булсак,
Әйтер идек — кем соң кул сузган...
Аккош ялгызлыктан үлә, диләр,
Торна түзә икән, ул узган.

Тозлыкүлнең тозлы суы сыман
Әче булгангамы язмышлар,
Шушы күл буена кайтасыз сез,
Иртә кайтасыз сез, әй, кошлар!

Бәлки, менә безнең туган якта
Ятып калгандыр да берегез,
Шушы җирләр, Тозлыкүлдер сезнең
Иң кадерле, якын җирегез...

Соңлап килгән язны сүгеп түгел,
Соңгы яуган карны сүгеп түгел,
Ялгыз, тугры калган торнаны
Хәтта жәлләп түгел —
Данлау өчен генә җырладым.

## Ялбыр каен

Басуымда ялгыз каен,
Ялгыз каен, ялбыр каен.
Тукталам да узган саен,
Серләшәбез табып җаен.

Яфраклары шыбыр-шыбыр,
Көйлиме җыр, әллә шигырь.
Шатлыгындыр ул, күрәсең,
Сөйли шулай шыбыр-шыбыр.

Гарасатлы иде еллар,
Авыр иде үткән юллар.
Әле һаман йөрәкләрдә
Еллар салган авыр юл бар.

Барсына да шаһит каен:
Кайгысына, шатлыгына.
Аның моңы шуңадыр да
Булмады һич шартлы гына —
Илгә икмәк кирәк чакта.
Ут алганда изге чикне,
Ир-ат яуда, хатын-кызлар
Сыер җикте, иген икте.
Әниләрдән калмадык без,
Иген белән бергә үстек.
Бәләкәйдән сабан сөрдек.
Яшь чыкмады һичбер бөртек.

Хезмәт белән куандырып,

Әниләрнең яшен сөрттек.
Ат куарга шул каенның
Ботакларын ала идек.
Менә шушы ялбыр каен
Сыргавылдай* кала иде.
Үзе һаман без кайтканда
Каравылга кала иде.
Афәт җиле исәр булса,
Сызгырды ул җир уятып...
Үтте еллар,
Атты таңнар,
Бар дөньяга нур буятып.
Менә каен киткән үрчеп,
Тәлгәш-тәлгәш ялбырланган.
Тавышы да шатлык кына,
Сызгырмый ул, сабырланган.
Яфраклары шыбыр-шыбыр,
Көйлиме җыр, әллә шигырь.
Җир бәхетен ул, күрәсең,
Күккә сөйли шыбыр-шыбыр...

## Урам көе

Урам көен уйнап үтте яшьләр,
Күк күкрәтеп минем күңелдә.
Бу көй мәңге колагыма сеңгән,
Чыңлап тора күңел күгемдә.

...Ул чак әти яуга китәр булган,
Мин күчәргә мендем сөенеп...
Күз алдында — чаңлы** басу юлы,
Яңгыравы урам көенең.

Киткән атлар ярсып кабат кайтты,
Юл чаңнары күккә ачылды.
Чаңлы юлдан атлар китте, китте...
Урам көе күпкә басылды.

Уйнар кеше әллә калмадымы —
Уйналмады озак ул нигә?
Шул көй белән киткәч,
Шул көй белән
Кайтыр төсле иде ул миңа.

Юк.
Кайтмады.
Хәтта сугыш беткәч,
Урам көен күпме сузсалар,
Ярсу атлар чаң туздырып юлдан
Кайтыр якка күпме узсалар,

Кайтмады ул.
Мин аңладым хәзер:
Эш булмаган икән ул көйдә.
Үзем дә бит чиккә сакка киттем.
Шул көйләрне тыңлап,
Шул өйдән.
Урам көен уйнап китте яшьләр,

Күк күкрәтеп минем күңелдә.
Юлдан чаң туздырып узды алар,
Чаң купмасын диеп күгемдә.

## Синең аша

Син, агаем, әти урынына
Бөтен көчкә җиктең кулларың.
Тәмамлана икән кайда гына
Безнең өчен үткән юлларың?

Кеше күрмәгәнне күргәнсеңдер,
Ә без аны артык күрмәдек.
Тәүге җилләр сиңа бәрелгәндә,
Юллар авырлыгын белмәдек.

Маңгаеңда — шуңа юллар саны.
Чәчләреңдә — шул юл тузаны,
Табышмак җавабыдай калдымы
Шул елларның ничек узганы!

Әтине мин тик сурәттән беләм,
Шомырт-кара аның чәчләре.
Ә кемлеген белдек синең аша,
Ничеклеген әти хәстәре.

## Сабантургай

*Рәми Гариповка*

Күксел күктән яшен үткән күптән,
Тарткан җәйгор алтын чымнарын.
Сабантургай күчә чымнан чымга,
Саный микән ялкын-чыңнарын?

Ул кояшка оча,
Җирне коча,
Белми кебек кая барасын.
Моңнар белән әллә ялгыймы ул
Кояш белән җирнең арасын?
Җирем белән мин моңыңны эчәм,
Биектәге җырлар санаты*.
Җырмы сиңа талмас канат биргән,
Җырлы итә микән канатың?!

## Гомер

Узган гомер агымсудай, диләр,
Шулай диләр...
Алай түгел лә.
Су юллары җирдә тиз уңа ла,
Гомер юлы ята күңелдә.

Су юлларын беләм: уңай ага,
Кешенеке алай буламы?
Урау-урау яткан тормыш юлын
Хыялымда әле буйладым.

Шулар гына белә юл шатлыгын, —
Кемнәр юлда җиңә алырлык.
Ул булмаса, сиңа нәрсә кала
Юлларыңны искә алырлык?

Әй, юлда бул таңнар атканчы,
Гомер үтәр керфек какканчы.

## Яңа елга аяк басканда

Бер олы туй сыман көткән идем,
Туган тойгылардан исереп.
Килеп җиткәч, моңсуланды күңел,
Үткән хыялларны кичереп.

Тәүге көне, әйе, күңелле дә,
Бәйрәммени узган еллары?
Йөрәгемдә ята ел юшкыны,
Маңгаемда аның юллары.

Узган елга күпме бурыч калган,
Эшләнмәгән күпме эшләрем.
Хыялларым калган тик хыялда,
Җырымда юк күпме хисләрем.

Моңсуланып бактым иске елга,
Бирәчәкне искә алдым да.
Яңа елны каршылыймын шулай,
Җаваплымын вакыт алдында.

*** * ***

Су-күл чагы җитте тагын,
Өзелер инде ара.
Кар сулары, үч иткәндәй,
Артканнан-арта бара.

Вакыт акты, су-күл кайтты.
Күрешү якын микән?
Су-күл белән безнең ара,
Их, агып китсә икән!

*** * ***

Язын кар китсә,
Кар кайтмас димә.
Башта чал юкка
Картайтмас димә.

Җирне кар япса,
Яз килмәс димә.
Агарса чәчең,
Картлыгым димә.
Нәни кайгыңа
Кара көн димә.
Шатлыкка һәрчак
Бу бәхет димә.

Алдаса дустың,

Юк, хаклык димә.
Яхшылык күрсәң,
Гел хаклык димә.

Тик җиңеп килсәң,
Җиңелмәм, димә.
Җиңелсәң берчак,
Мин җиңмәм димә.

## Киләчәк

Киләчәкне ул киләчәк, диләр,
Киләчәкне, диләр, җитәчәк.
Шулай да ул,
Ләкин кем соң безне
Киләчәккә алып киләчәк?
Кул кушырып әгәр көтеп ятсак,
Килер микән безгә киләчәк?
Алай булса, тик калырбыз аннан,
Ә киләчәк ары җиләчәк.
Киләчәк бит үзе килмәячәк,
Көтеп алмас аны берәү дә.
Ул бит көрәш, уч төбендә сөял,
Ул — туктаусыз яну, эзләүләр.
Килер ул тик без алышсак кына,
Хыялларны узып киткәнче.
Вакыттан да һәрчак алда булсак,
Иртәгәне бүген иткәнче.
Без эшлисе иртәгәгә калса,
Иртәгәләр гафу итмәсләр.
Киләчәкне без бит китерәбез,
Киләчәк ул — бүген, иптәшләр!

## Йолдызлы җир

Йолдызлар кайда күбрәк,
Җирдә микән, күктәме?
Җирем кайчан килер телгә,
Йолдыз туе күпкәме?

Йолдызлар өнсез аңлаша,
Ә миңа өнсез кыен.
Япа-ялгыз карап барам
Җиремнең йолдыз туен.
Туйга җилеп килә җилләр,
Йолдызлар куа-куа.
Атлап барам: кар шыгырдый,
Йолдызлы хисләр туа.

Шыгырдавы — җир сәламе!
Ул кайтканны ишеткән.
Ак кар түгел, ак биләүдә
Йолдызлы җир бишектә.

## Борчак яңгыр

Ал-ял белми коеп тора
Кургаш сыман борчак яңгыр.
Башка тиеп китәмени
Болытлары ялбыр-ялбыр.

Суландым мин көшел кебек,
Килеп ятам ерак юлдан.
Тел тидерми һичбер нигә
Атлый бирәм, уйлар елдам...

Уелдылар кинәт уйлар —
Борчак ап-ак чәчкә аткан.
Ярым чәчкә шул борчакка
Ымсындыра, тамак ачкан.

Күз алдына баса шул мәл —
Кургаш яуган яман заман;
Борчак белән тамак ялгау
Онтылмый һаман-һаман.

...Чыбыркысын инде күптән
Сакламыйдыр Сәет карт та.
Эзләре дә безнең сыртта
Уңып бетте, калды артта.

Мөлдерәмә чәчкә борчак
Шулай уем бүлеп куйды.
Бүлмәде ул минем юлны,
Дәвам итәм куйган уйны.

Атлый бирәм, коя яңгыр,
Болыт үтә ялбыр-ялбыр.
Яууына һич үпкәм юк,
Яусын әйдә борчак яңгыр,
Коймасын дип кургаш яңгыр.

## Кыяларда

Изү чишеп, Идел кичеп
Таптадым кыяларны.
Кыялардан очтыммы мин,
Кыялар таялармы?!

Әкияттәгедәй күчәмен
Кыялардан кыяга.
Кыл очында кала гомер,
Тайпылсаң бер аяга*.

Шундый мәлдә аңладым мин
Яшәүнең кадерен дә.
Гомер әл дә өстә кала,
Ә үлем — каберендә.
Яшәү ул — кыя арасы,
Була шом да салган чак.
Кадерле итә гомерне
Кыл очында калган чак.

## Уралда таң

Кояш чыгып килә таулар аша
Түгелергә торган ут сыман.
Итәгендә үскән карагайлар —
Атылырга корган ук сыман.

Утлар, уклар күргән, кайгы төргән
Уралымның һәрбер карышы.
Кайгы күргән җирдә каен үсә,
Карагайлар белән ярышып.

Каен үскән җирдән кайгы киткән,
Дөнья шомы хәзер ук түгел.
Таулар аша чыгып килгән кояш
Яулар кабындырыр ут түгел.

Каенлы җир кайгы күрмәсен лә,
Чыкмасын ла кояш ут булып;
Кайгы эчкән җирдән карагайлар
Очмасын ла тагын ук булып!

## Искән җилләр

Искән җилләр, кайда сезнең илләр,
Каян чыгып, кая киттегез?
Нинди якны урап үттегез сез,
Кай җирләрне якын иттегез?

Һәрвакыт бит сезне шаян күрдем,
Гомер буе бактым көнләшеп.
Бүген сагыш кына салдыгыз сез,
Шатлыкларны кайда өләшеп?

Җиргә ятып тыңлап калдым сезне:
Тавышыгыз моң да зар гына.
Бар дүрт тараф өнсез карап кала,
Озата шул җиңел кар гына.

Елый-елый ары җилдегез дә
Өерелеп кире килдегез.
Карлы җирне кочып уйладым мин:
Булмагангадыр дип илегез.

## Һаман ут яндырып

Исеңдәдер, әни, иң соң ятып,
Иртә торганнар да без идек.
Юлаучылар юлы өзелмәде —
Ишек ачып кына түз иде.

Күпме кеше кереп юл сорады,
Күпме юлчы китте җылынып.
Шырпы-тәмәкесез юлчылары
Күп иде шул сугыш елының.
Төннәр буе, әкияттәге сыман,
Ут сүнмәде безнең учакта.

Юлчыларның нәни маякчысы, —
Керфек какмадым мин шул чакта.

Мин аларны көтеп мичне яктым,
Самавырда кайнар чәй булды.
Юлчыларым китте ерак юлга...
Салкын кышлар үтте, җәй булды.

Еллар китә үз юллары белән,
Шул юлларда әмма уйларым.
Юлчылардан берни сорамадым,
Әкиятләрен генә тыңладым...

Онытылгандыр иң очтагы өй дә,
Иң очтагы өйнең уты да.
Мин төннәрен һаман, ут яндырып,
Шул әкият белән утырам.

*** * ***

Тик гашыйклар йөрер сәгатьтә,
Булмаса да юньле сәбәп тә,
Мин ашкынып чыктым урамга,
Йөзне каршы куеп буранга.

Ярсый давыл кемгә карышып?
Буран белән барам ярышып.
Ниләр генә булмас бу мәлдә:
Юлдан язар, бәлки, бер бәндә.

Ялгыз юлда куйса буталып...
Киттем йөрәгемдә ут алып.

## Акъярда

Ничәмә көн, ничәмә төн,
Акман-токман көнне тукмый.
Күк — торганы көйсез сабый.
Шул үчекчән кайчан туктый?

Килгән дә юк, киткән дә юк,
Барып булмый барыр җиргә.
Күрәм димә, китәм димә,
Бар соңлаулар тарыр бергә.

Акъяр — ак кар, чумган карга.
Тик юк карга ачу, каргау.
Кар таулары — иген, диләр.
Уңыш өчен булыр зур дау.

Читтән килгән үкенәдер:
Нигә юлым төшкән юктан.
Ә акъярлар шундый тыныч:
Эштә алар — акман-токман.

## Байрак төсе

Байрактагы ал кан.
Байрактагы ал таң —
Җиде генә түгел,

Җитмеш буынымның кан төсе;
Җиде гасыр аша ыруымның
Җиде яктан көткән кан төсе.
Тәхет өчен түгел, бәхет өчен
Хак юлында башын салганнар —
Бар дөньяның күз карасы сыман,
Байрак төсе булып калганнар.
Җилбердәсә җилдә — тоям анда
Ялкын төсен, янган ут көчен.
Тик изгене һич көйдермәс ул ут,
Ул ут белән килә кот күчеп.
Танышларны табыштырды да ул,
Китерде ул телгә телсезне.
Туганлыкны гына туган итеп,
Илле итте илдә илсезне.
Кешелек тә аны таң төсенә,
Кан төсенә белеп буяткан:
Шуңа аның җиле
Күпме еллар элек
Йокысыннан ирне уяткан,
Йокысыннан җирне уяткан!

## Бүгәслетау — Җаек ярында

Кайдан гына үтми батыр юлы,
Җир сакламый ләкин барын да...
Ил улына тере һәйкәл тора
Бүгәслетау — Җаек ярында.

Җирем өчен биреп көчен, күпме
Ятып калган батыр башлары.
Шул батырлар үткән эзне табып,
Үбәр идем баскан ташларын.

Салаватым анда ат эчергән,
Юган бит ул батыр канын да.
Әй, чал шаһит, хәйран калып торам,
Бүгәслетау, синең яныңда.

Салаваты кебек якын күреп,
Күз өстендә торган каш итеп,
Бер тавына халык исем биргән,
Ярның тауларына баш итеп,
Җаек өстендәге каш итеп.

## Туган көнем

Юлда үтә туган көнем,
Талгын җил чәчем тарый.
Уй җыя узган гомерне
Йә берчә чәчеп карый.

Юлларымны юллап-юллап,
Уйларны уеп чыктым.
Вәгъдәләрне һәм эшемне
Чиратлап куеп чыктым.
Тау-тау тора вәгъдәләр,
Ә эшләр түмгәк чаклы.

Дус дигәнем дошман булган,
Тегесе — минем яклы.

Эзләгәнем ятып калган,
Кирәкмәсне тапканмын.
Ятмас чакта мин ятканмын,
Ятар вакыт чапканмын.

Әйтерсең лә мин моңача
Ялкынсыз сүнгән күмер.
Сүзләрем сүздә калганнар,
Әй, бушка күнгән гомер...

Юлда үтә туган көнем.
Җавап алдым үземнән,
Тирә-юньдә бер шаһит юк,
Көлмәсен җир сүземнән.

## Казлар китә

Соңгы яфракларга сары куна,
Соңгы казлар китә тезелеп.
Казлар китсә, сары яфрак болгап,
Ияреп чаба идек без элек.

Кая очты алар, кайда ул чак,
Казлар очып җитмәс аралар?
Яфракларга һаман сары куна,
Шул ук юлдан казлар баралар.
Ничәнче көз икән китә алар,
Ничәнче яз кире кайталар.
Киткән-кайткан каз юллары, җайлап,
Маңгайларга икән яталар.

Тагын менә кыр казлары китә,
Кул болгамый калам күз атып,
Казлар белән кире кайтмас якка
Байтак гомеремне озатып.

Каңгылдашып казлар кайтыр бит ул,
Яшьлегенә кайтыр җир генәм.
Яшьлегенә җирем ел да кайта,
Ә без нигә икән — бер генә...

## Биеклекләр тартсын

Әллә соңгы кабат күкрәвеңме,
Яшьлегемнең соңгы яшене?
Бу күкрәүне күпме көтте күңел,
Көтеп тордың кайда яшренеп?

Менә кинәт тормыш-дәрья мине
Ярларыннан атты ярына.
Әле күккә очтым, әле төштем,
Куәт кенә артты барыннан.

Тормыш-дәрья, әйдә чайкалт әле,
Калсын күккә түбәм тиеп тә,
Минем тынгы белмәс күңелемне
Биеклекләр тартсын биеккә!

## Уралда кич

Аяк астым — бәбкә үлән,
Йолдызлы күк — түбәмдә.
Көмеш күгем күккә тарта,
Алтын җирем — түбәнгә.

Уртада мин — канатлы кош.
Күңелдән канатланам.
Җиремнән гайрәт алам да
Күгемнән канат алам.

Күккә баксам — күк минеке,
Җиргә бассам — җирем үз.
Кулдан килеп, әйтсәң иде
Үзегезгә тиң бер сүз.

Көмеш күгем, йолдызларың
Җырыма кунса икән.
Уралымда яралган җыр
Йолдызлы туса икән!..

## Рәхмәт, буран!

Тәүге карга тәүге эзләр салдык,
Дөньяда тик син дә мин идем.
Бөтен дөнья — безгә, ә күңелләр
Карның сафлыгына тиң иде.

Атна буе бүтән кар төшмәде,
Саклады җир безнең эзләрне.
Нигә шунда буран купмаган да,
Ни туктаткан икән җилләрне?!

Кардагы эз озак ятмас, бәлки,
Тик йөрәктә бетмәс һичкайчан.
Давыл чыкты менә белгән кебек,
Буран юар аны, ичмасам.

...Эзләреңне ул себереп үткән,
Шул җирләрне йөреп урадым.
Әй, яшәсен җирдә кар бураны,
Булмасын тик тормыш бураны!

## Бурычым бар

Барсына да бурычлымын,
Бурычым бар искән җилгә;
Үләннәргә бар бурычым,
Юлларымда үскән гөлгә.

Һәрнәрсәдән авыррак
Иң зур бурыч — туган җиргә.

Атландырып тәү кат атка
Ерак юлга куган иргә.

Мәңге бетмәс бурыч йөри
Тиң-ишемә, дусларыма:
Нинди шатлык салырмын соң
Мин аларның учларына?

Менә миннән җавап көтеп
Бөтен дөнья баккан бергә.
Шул бурычны каплар өчен,
Аклар өчен бастым җиргә.

## Йокыларым кача

Йокыларым качты, йокыларым...
Төн карасы какмый канатын.
Ярсуларым тагын ярдан аша,
Басылырмы йөрәк, таң атып?

Минем җиргә әле йолдыз ява,
Явар микән инде төн буе?
Йолдыз яуган мәлдә күңелемдә
Бар өнсезлек яна өн булып.

Тоям, әле ерак җирдәшләрдә
Йолдыз түгел, бомба явадыр.
Йоклар ирләр мендәрләргә түгел,
Ялкын өсләренә авадыр.

Ирләр күз алдында йолдыз булып
Сүнәдер ул дөнья җай гына.
Аларга бит җитми йолдызлы төн,
Җитми бары йөзгән ай гына...

Кайчы булып керфекләрем кисә
Кара төннең кара япмасын.
Чыксын кояш,
Карашларым белән
Тартып ачам таңның капкасын.

## Төшлектәге кояш

Каушап калдым кинәт көн өстендә:
Язмыш җиле кире истеме?
Ак көнеңне томаларга әллә
Бәхет юлын хәсрәт кистеме?

Баскан җирем ят бер чит җир кебек,
Кайда сугылырга, кай төшкә?
Әйтерсең лә җирем алмашынган,
Кояш урынына ай төшкән.

Юк!
Әле бу һаман көн уртасы.
Кояшым да балкый төшлектә.
Минем ярты көнем ничек үткән?
Төшлегем бит җавап — эш көтә.

Баш очында, төшлегемдә — кояш,

Аңа җавап белән интегәм;
Көнем баеп, иңгә эңгер ятса,
Сорау булып калыр Җидегән.

Баскан туфракларым үз итәрлек,
Кояш нуры хәрам булмаслык
Бармы минем эшем? Күңел өши,
Көнгә ни төс бирдем уңмаслык?

Җиң сызганып эшләр ярты көн бар,
Вакыт, заман миннән эш көтә.
Көн югалыр, җиргә ни кайтыр дип,
Кояш тора әле төшлектә.

## Ашыгам

Ашыгам мин, ашыгам мин һаман,
Ашка пешкән чаклар булса да;
Ашыгудан, ашкынудан кайчак
Шатлыгыма хәсрәт кул сала.

Көн нурына сусап, ашыгып мин
Атар таңга киләм төн аша.
Бөтен саклык, сабырлыклар аша
Иртәгәгә керәм төн аша.

Кич баеган кояшны да шулай
Иртә күрү өчен ашыгам.
Бәхет көтсен!
Кешеләргә тими,
Кайгы әйдә килсен каршыга.

Ашыгам мин хаклык угы белән
Хаксызлыкның күзен чәнчергә.
Миңа дигән бәхет орлыгыннан
Җиргә кирәк шатлык чәчәргә.

*** * ***

Йөрәгем очарга омтыла,
Омтыла керештәй тартылып.
Дөнья, бир очарга юлыңны,
Очарга офыклар артылып.

Вакытның кереше тартылды,
Тартылды атылыр киң җәя.
Очырсын. Очар юл биектән,
Биектә офыклар киңәя.

## Синең аша күрәм

Туган җирем! Синдә төс таныдым:
Кара икмәк исен, су татыдым.
Күңелемә күчте бар шатлыгың,
Моңсулыгы юллар чатының.

Сабакларың һаман санланырлык
Аерырга хакны, ялганны.
Сабак алып, озын юлга чыктым,

Дөньяга мин синнән ялгандым.

Минем өчен төс ташласаң берчак,
Матурлыгың куйса күз тиеп.
Күз нурларым сүнәр, туган җирем —
Минем өчен дөнья күзлеге.

## Ялгыш бастым...

Ялгыш бастым тагын һәм егылдым,
Үзәкләргә үтте зәһәре.
Алга карап барып, күздән читтә
Аяк астым калган, каһәрең.

Юл ярганда ерак максатларга,
Чабам икән бакмый җиргә дә,
Уңыш, беләм, әллә кайда ята,
Бәла яткан була эргәдә...

## Агымсу

Агымсу акканда
Агыза һәммәсен.
Нәкъ шуның шикелле,
Әй, гомер, үтәсең.

Ага да ага ул,
Сугылып ташларга.
Ул кая ашыга,
Ул каян башланган?

Агымдай сарылып
Күңелдә моң ага.
Нәкъ шушы — сәер моң —
Агымда ком ага.

Кушылып комнарга,
Ишелеп таш ага.
Агымсу кайсылай
Ташларны ашаган.

Гомерем — агымсу,
Азагы, башлары.
Ашалып аксыннар
Язмышның ташлары.

## Шатлык килә

Шатлык килә кояш кебек,
Йөзе балкып килә шатлык.
Кайгы килсә, өнсез килә,
Елан кебек кайгы — сатлык.

Килер шатлык — төкле аяк,
Бар күңелгә күнеп китсен.
Ә кайгылар каерылып

Кадалыплар гына китсен.

Кештәктә дип кешенеке,
Кешенекен белми калсам,
Яшәү нигә? Аңлармын тик
Чит кайгылар алсам-салсам.

Кояш алсын шатлыгымны,
Алып җиргә, җиргә сипсен.
Җилләр алсын кайгыларны,
Кайгы яше җилдә кипсен.

## Иртән яуган карлар

Быелгы кыш әллә ничек килә,
Иртән яуган карлар төш эри.
Ел борылып, әллә язга тарта,
Күңелемдә әллә төш йөри.

Кыектагы бозлы тамчыларның
Тамчылары тама түгелеп.
Туңган тәрәз кебек ачыла бит,
Ачыла бит көнем, күңелем.
Карап торам: менә гөл төбендә
Туңган күбәләккә җан керә.
Шул күбәләк гөл тузанын кага,
Һәм гөлләргә кинәт ямь керә.

Күренми дә иде ул күбәләк,
Тоелмый да иде җәй элек.
Әй туйдырган икән тирә-юньдә
Күз алдаучы җансыз ямьлелек.

Йөрәгемдә моңлы җыр талпына,
Шул күбәләк кебек сак кына.
Оч син, җырым, канатларың белән
Күңел тузаннарын как кына.

Иртән яуган карлар төш эресен,
Күбәләкләр тагын туңмасын.
Оч, күбәләк! Оч, җыр! Гөлләргә дә,
Күңелгә дә тузан кунмасын!

## Имән ауды

*Сибай башкорт драма театры артисты*
*Мөхәммәт Шәрипов истәлегенә*

Син имәндәй идең яшәгәндә,
Бактык сокланып.
Кинәт менә шул имәндәй авып,
Яттың — йокладың.

Булды төрле җилләр, башын иде
Үләннәр генә.
Җил-давылны тоймый инде бары
Үлгәннәр генә.

Язмыш күгендә яшенле давыл
Кагылды аңа.
Яшен-үлем үләннәрне түгел,
Имәнне суга,
Имәнне ега.

## Нигә әле...

Нигә әле шулай ярсыдым да,
Нигә әле шулай ашкындым?
Мин үземә урын табалмадым,
Язгылары кебек ташкынның.

Күңел күккә менде, үзем — җирдә.
Күңел күккә менсә, җир тартты;
Ярсуыма, ахры, берни булмас,
Бер кимеде дә ул, бер артты.

Тагын, тагын мин дөньяга бактым —
Күңел кошым кая оялар?
Әй гафу ит, дөнья, шуннан күпне
Эзләгәнмен нигә? Күзләр — күкне,
Аякларым җирне тоялар.

## Синең йөрәгең...

*Профессор*
*Җәлил Киекбаев истәлегенә*

Сулык-сулык җанга тамчы тама,
Март айлары җитсә,
ел саен.
Хәтта кояш бүген туды сыман,
Яшь аралаш кына елмаеп.

Аяз көнне яшен яшьнәдеме, —
Күк ишелде,
әллә көн сүнәр?
Юк, яшеннән хәтәр иде хәбәр —
Ул хәбәрдән ташлар көрсенер.

Мартлар, язлар килерләр дә,
ләкин —
Басылырмы йөрәк сызлавы?
Шушы сызлау — минем йөрәгемдә
Еремәскә туңган бозлавык.

Ә син яшәгәндә, туры басып,
Бозлавыклы юлдан юл ярдың.
Ярып төнне, маяксыз да бардың,
Белеп бардың шундый юл барны.

Юл гынамы!
Күреп ачык,
Яңа галәм ачып,
Иң-иң серле сыртлар аркылы
Очыш ясап, үзең артык иртә

Кинәт йолдыз сыман атылдың.
Очтың, очтың белем җиһаныннан —
Чал Уралның чая бөркете.
Шушы юлга чыгучылар хәзер
Берәү генә түгел, бер төркем.

Олы юлдан барган нык егетләр
Синең эздән алды терәген.
Чөнки синең, нәкъ космонавт сыман,
Орбитада калды йөрәгең.

## Килермен

Куанычтан чакырма, дус,
Үз өеңә сыяр шатлык.
Сөенечне гел бүләбез,
Аны бүлеп артык шаштык.

Бүлешик без кайгыларны,
Күмәкләшеп үткәрикче.
Чакырмасаң да, килермен,
Көч җиткәнче күтәрикче.

## *

Табын нурлы, табын җырлы,
Һәммәсе дә сузып кулны,
Берәм-берәм чират белән
Йөртә бүген минем улны.

Улым йөри кулдан-кулга,
Өстәл буйлап очтан очка.
Килер вакыт: шушы малай
Шатлык салыр учтан учка.

## Вакыт җитми

Күрше хәлен белешергә
Көн дә менә вакыт җитми;
Күрешкәндә сөйләшергә
Ярты сәгать вакыт җитми.

Хат язарга туганнарга
Кичә җитми, бүген җитми;
Чакырмаса, дус өенә
Бару өчен күптән җитми.

Эш итәргә төп эшеңне
Вакыт чак-чак җитми кала.
Сөйгәнеңә әйтер сүз дә
Вакытында җитми кала.

Йөргән чакта булмый вакыт
Үз-үзеңне дәваларга.
Аугач кына сагындыра
Чыгып йөрү һаваларга.

Һаман шулай яшибез бит
Акланудан ары китми:

Вакыт җитми!..
Көннәр җитми, еллар җитми,
Гомер җитми...

## Ана әманәте

Ачык күзем белән күрмәс борын,
Әни йолдыз дип күкне күрсәтте.
Күз ачылды, йолдыз табылмады,
Ә миңа дөнья күпне күрсәтте.
Күкне күрдем — исемсез йолдызлар...
Йолдыз булып янарга уем юк.
Җитмәс кулны сузмыймын югары,
Тормышта тик чыны бар, уен юк.

Әни миңа һаман киңәш итә,
Җирдә яшә, дип, йолдыз яндырып,
Карашың күктә булса да яшә,
Бөтен яктыңны җирдә калдырып.

Кулымнан килмәсә инде алай,
Әниемнең бар бит әманәте:
Яхшылыгың калмас булса әгәр,
Ичмасам, калмасын яманатың.

## Канатлар оча җил белән

*Якташым — мәгърифәтче*
*Мөхәммәтсәлим Өметбаев*
*каз каурые белән язган*

Канатлар оча җил белән,
Канатлар оча илемә.

Кулыңнан синең очамы,
Юлыңнан синең очамы?

Ул иде бердәнбер коралың,
Яктыга тарткан ораның.

Канатлар синең заманнан
Очалар кебек һаман да.

Очалар алар җил белән,
Очалар алар илемә.

## Бәләкәй Шәүрәгә

Бер сирпеләм — күз тимәсен,
Кыеш әйтеп, сүз тимәсен.

Яткан була кеше булып,
Белеп яткан ише булып.

Курчагын ул тотып ята,
Бөтен серне отып ята.

Җирең бирер сиңа канат,

Күгең тора йолдыз санап.

Үс тизрәк, үс син, Шәүрә,
Күрсә сине — дөнья әүрәр*.

## Ел чатында

Бурап-бурап яуган карлар
Акчарлактай иңгә төшә.
Көтә дөнья Яңа елны,
Ап-ак келәм җиргә түшәп.

Атлап килә бу Яңа ел
Ак юл белән ак келәмнән.
Минут булып үткән еллар,
Үтә еллар ак җиләндә.

Хушлашачак иске елым
Эленеп торган тамчы сыман.
Әй, елларны, ашыктырып,
Куа вакыт камчы сыман.

Юл чатында торган кебек,
Басып торам ел чатында.
Уйлап торган бөтен уй да
Юл хакында, ел хакында.

Тагын бер ел төшеп чума
Мәңгелекнең дәрьясына.
Ә яңасы ни китерер,
Миңа нинди өлеш суза?

Ел, бул җиңел, басмагандай
Иңнәремә өелгән кар.
Чөнки сездән кагылган да
Шул ук сездән сөелгән бар.

Торам менә ел чатында,
Килер еллар кулын сузсын.
Бүген кияр күлмәгем дә,
Килер ел да имин тузсын.

Яусын карлар бурап-бурап,
Агачларга элсен сырга.
Көттермәсен яз кояшы,
Җәен яусын яңгыр кырга,
Яшикче тик яшәртергә,
Тузганнарны яңартырга,
Яшәртергә, яңартырга!

## Язгы һава

Яз һавасы каен суы сыман,
Күпме эчмә — кайтмый тансыгым.

Басуларым буйлап атлап киләм,
Кояш белән бергә таң чыгып.

Шул җирләрдә йөреп алдан тоям
Шаулар башакларның тавышын.
Борын төрткән минем шатлыгыма
Яшел дәрья килеп кавышыр.

Каен суыише генәмени
Пешәр башакларның исләре?
Яшел дәрья алтын төскә керсә,
Шатлыгыма бәхет өстәлер.

Ак карлардан кара җиргә басып,
Яз һавасын сулап йөримен.
Сәламлимен кулым болгап күккә
Канат каккан кошлар өерен.

*** * ***

Әллә ничек үтә вакыт,
Ул атылган бер йолдызмы?
Оча, оча, иярми күз,
Үтеп китәр, күз йомдыңмы.

Кичә генә кырпак төште,
Бүген март җилләре исә.
Кар гомере җил иркендә,
Ак карларны җилләр кисә.
Мин көнләшәм искән җилдән,
Көнләшергә хак бар сыман.
Үтә вакыт, үтә гомер,
Шиңеп барган ак кар сыман.

Ул ел сыман үтә китә,
Бәхәсләшеп тормый ваксып.
Үтендерә, үкендерә,
Үзенекен итә вакыт.

Яңа кояш, вакыт нуры
Ак карларны кырка төшә.
Күңелемдә — март җилләре,
Ә чәчемә кырпак төшә.

## Әти кулы

Тормыш һаман үзгәрүгә бара...
Безнең әле әти киткәндә
Утыртылган капка баганасын
Энем тотып бүген кискән дә
Өр-яңадан куйган.
Тик әнием
Бу эшенә төпчек улының
Моңсу карап үтте, —
Бу бит соңгы
Истәлеге ата кулының...
Беләм, беләм, ул кичерер аны,

Андыйларны гына күрмәгән:
Карагызчы аның чәчләренә —
Кылган кушып аңа үрмәгән!
Ул күтәргән дөнья авырлыгын,
Тормыш михнәтләрен татыган,
Чәчләренә тигән заман җиле,
Әзер бәхет булган ят аңа.
Бүген барысы, әни, сезнең өчен,
Яшәү — бәхет кенә торганы.
Ил алдында син бурычлы түгел,
Капканың да яңа корганы
Тик шатлыкка ачык,
Энекәшләр, абайламый кайчак
Зур күңелне берүк китмәгез,
Тетрәүләр бит аңа күптән җиткән,
Дөнья кылы шул йөрәктән үткән,
Ул кылларны бушка чиртмәгез.

## Каенлыкта

Февраль киче.
Килдем карлар кичеп,
Билдән көрттә япь-яшь каеннар.
Ботакларын иеп бәсләр кунган,
Бәсләр эреп микән бозлар туңган,
Баш игәннәр барча каеннар.
Әйт, каенлык, нинди кайгың бар?

Түбәмдәге түтәрәм ай боек,
Агачларның ап-ак бәсләре;
Каткан бозлар гүя күз яшьләре.
Дөньяның бу нинди хәстәре:
Каеннарның ап-ак чәчләре,
Аккан көе туган яшьләре.

Сагыш елы...
Сүрәнәйгән кичләр...
Кич утырган моңсу апалар
Шул каеннар кебек килеп басты,
Яуда иде безнең атайлар...
Күз алдыннан үтә яшеренеп
Яшь каеннар түккән яшьләре,
Бер кич кырау кунган чәчләре,
Дөнья хакындагы хәстәре...

Күз алдыма килә бүген ул чак,
Еллар аша күңел өшенә.
Бездән үтте, кермәсеннәр алар
Хәтта каеннарның төшенә.

## Апрель йөри

Апрель килә җиргә дөнья иңләп,
Яшәү йөри бөтен җир буйлап.
Бар табигать әнә телгә килә,
Ашкынамы икән ул туйлап.

Шатлык балкый кеше йөзләрендә,
Бәхет оча күзгә күренеп.
Ташкын сулар җирнең битен юа,
Яшәрә җир гөлгә төренеп.

Кояш нуры җиргә яшьлек түгә,
Арта яме кеше күркенең.
Егетләрен ошатмаган кызлар
Йөри кебек бүген үкенеп.

Бөтен җирдә туу һәм яңару,
Үлән шыта, чатный бөреләр,
Әйтерсең лә апрель җилләреннән
Дөньяга тик яшәү өрелә.

Дөнья буйлап җирдә апрель йөри,
Апрель йөри тормыш илтергә.
Үлемгә ул үлем алып килсә,
Ә яшәүгә яшәү китергән.

## Рәхмәт сүзе

Кунадан кайткан кыз сыман,
Әй ашыгып кояш калка;
Күк Зөһрәсе колагыннан
Өзелә Ай — көмеш алка.

Тәрәзәмә җилбер-җилбер
Җилеп килеп җилләр кага.
Төн бушаган тын бүлмәмә
Өлге тулып нурлар ага.

Тән языла, җан языла,
Сулыш алам күкрәк киереп.
Төндә күңелен тырнаган
Шикләр югалалар шиңеп.

Күпме бәхет хакы тора
Шул иртәне күрү генә.
Сүнми торган куз сала ул
Яшәвемнең күрегенә.

Мин уянам, җир уяна,
Кояш нурын таратканга.
Рәхмәт инде, хозур дөнья,
Кеше итеп яратканга.

## Ерак ара

Еракка җибәрмәм инде
Бүтән сезне;
Хушлашканга күп тә түгел,
Көтәм сезне.

Бер дә аерылышмыйча
Өйрәндек тә.
Хәзер миңа ямь беткәндәй
Ирәнлектә.

Куанычтыр аязлары,

Әй көненең,
Монда инде юк җылысы
Җәй көненең.

Күз алдыннан сыны китми
Айгөлемнең;
Кызыма бүләк ит шәбен,
Әй гөлеңнең!

Ерак ара нык белдерә
Якынлыкны;
Арабызда мәңге сүнмәс
Ялкынлыкны.

## Кичке сер

Җирләремне яман җилдән саклап,
Бураннардан — кышкы салкында,
Күпме еллар кыя сыман тора.
Шундагы таш кыя хакында
Кичке җилләр миңа сер сөйләде,
Тыңладым мин өнсез, аптырап.
Тыңлады җир тыныч. Баш очында
Мең-мең йолдыз торды калтырап.
...Күптән, күптән шушы мәгъруур кыя
Гашыйк булган күктә йолдызга.
Йолдызга ни-нәрсә!
Чөнки әле
Исәпсез дә инде ансыз да
Ымсынганнар аңа күктә, җирдә,
Бар дөньяга ул бит күренә.
Ә кыя бит бары җирдә, имеш,
Ничек җитсен җиһан түренә.
Тик күз яше кыя түкмәгән,
Гомере дә зая үтмәгән.
Нинди киң булмасын җиһан иле,
Йолдыз йолдызларга сугылып
Янгач инде бер таш булып төшкән,
Кыя итәгенә уелып...
Кичке җилләр шуны сөйләп үтте,
Мин тыңладым өнсез, аптырап.
Тыңлады җир тыныч.
Баш очында
Мең-мең йолдыз торды калтырап.

## Кышкы юлдан

Төн басудан офык шиңә,
Күк кузлана кузлар кунып.
Сиңа барам кышкы юлдан,
Керфегемә бозлар туңып.

Син ничексең, әллә миңа
Ерактагы салкын кузмы?
Мин ышанган, юлга тарткан,
Күз терәгән ялкын-бозмы?
Әгәр мине син дә көтсәң,

Көндез дә, өндә көтсәң,
Минем капка кагуымны
Төшләреңдә, төнлә көтсәң,

Барсам өшеп, күктән төшеп,
Күңелемә кузлар керер.
Синең ерак сулышыңнан
Керфегемдә бозлар эрер.

## Көтмәгәндә

Юлда көтмәгәндә очрадың да
Үтте мине йөгереп узып,
Сине хәтта шәйләми дә калдым,
Үттең, киттең якты нур сузып.

Ашыктыңмы, каян, кая киттең,
Оялдыңмы,
Әллә яшь идең?
Мине узып киткәч, тагын туктап,
Карап алдың үзең яшренеп,
Шулдыр, ахры, минем яшьлегем.

## Яфрак яндыралар

Өеп-өеп яфрак яндыралар,
Җиргә мунча исе таралган.
Яфрак өчен киң урамнар тармы,
Яндырыргамы дим яралган?

Башым иеп мин атлыймын таштан,
Янар яфрак ява өстемә.
Иңгә алар шундый ихлас төшә,
Алып китәр дигән төс белән.

Китәр идем алып җиргә, юлга
Түшәр өчен яфрак мендәрен.
Гелән яфрак минем өскә яумас,
Гел күтәрмәс инде иңнәрем.

Җирем төсле яфрак юрганына
Күнмәгән шул кала урамы.
Ә кадерле миңа, юлымны да
Тик яфраклы юлга борамын.

Озак ятмый яфрак, утка керә;
Янарлар да алар сүнәрләр.
Күз алдымда торыр очкан яфрак,
Очкан яфрак сыман гомерләр.

*** * ***

Тагын яшен, тагын яңгыр
Каршы язмыш чарасына.
Яшен яктысында барам
Ут белән су арасыннан.

Уты белән, суы белән
Әллә тормыш сынап уза.

Сиңа илткән юлы белән
Утын суза, суын суза.

Мин ризамын барысына, —
Күңелемне кайтсам чишеп.
Гомер итәргә әзермен
Яшен йотып, яңгыр кичеп.

Менә сиңа юлым өзек,
Яшен, яңгыр узды ничә.
Мин еракта тын көндә дә
Утлар йотып, сулар кичәм.

## Әйгә киләм

...Синең туган җирләреңдә булдым.

*М.Кәрим*

Үзең кебек күрәм туган җирең,
Һәр сыйфаты якын күңелгә.
Ул да көткән микән, эзләремә
Саф чык түгел, яше түгелә.

Сиңа карап үскән ак каеннар,
Уйчанлыкны биргән Әй сиңа.
Карашларың кебек җитез җилең
Чабып килә кебек бәйгедән.
Бөтен җанлы дөнья белгән кебек,
Көткән кебек каршы алгандай,
Шөпшәләрнең серле кубызына
Синең сөю шулай канат куйды,
Җил җитәкләп килә җиңемнән.

Үзең генә түгел, җирең ихлас,
Аякларым булсын җиңелдән.

* * *

Өзә сугар яфрак җиле исә
Чумар мәлдә җирем чәчкәгә.
Өркеп тора дөнья, туктап калган
Борын төртеп килгән чәчкәләр.

Ул җилләрнең хикмәтен җир белә,
Белеп исә яфрак җиле дә.
Шушы җилләр бөреләрне ачар,
Яшәү генә өстәр җиремә.

Ал да гөл иде бит безнең ара,
Көтмәгәндә нинди җил исте?
Яфрак җиле үтәр — чатнар бөре,
Яшел үлән күмәр җир өстен.

Игелекле җилләр исеп киткән,
Була бит ул җилләр кискен дә.
Аралардан әгәр җилләр иссә,
Яфрак җиле булып иссеннәр.

## Чәчкәләр

Чәчкәләрем,
Җирем чәчкәләре,
Гомерем буе сезгә гашыйкмын.
Тик мин барыгызны изге күреп
Хыялландым. Ахры, ашыктым.

Күбәләкләр булып кунмадым да,
Күз нурларым сезгә камашты.
Һәм берегез көтмәгәндә генә
Ялмап алды минем карашны.

Сүз әйтергә кыймасам да үзем,
Килә идем аңа талпынып;
Челпәрәмә килде барысы да,
Узгынчы җил аңа кагылып.

Күз алдымда ул таҗларын ачып,
Күз алдымда бетте, коелды...
Хыялларым сүнеп, мине шулчак
Яшен суккан төсле тоелды.

Ә кырымда мең-мең чәчкәләр
Җир бизәрлек нурлар чәчәләр.

*** * ***

Булсын сөю ачык диңгез сыман,
Киткән саен тирән, чиксез ул.
Аңа беркем киртә куя алмас,
Гомеренә ачык, биксез ул.

Тиңләшерме безнең сөю белән
Диңгезләрнең тирән, тиңсезе;
Кулларыма кулларыңны салсаң,
Юлларыңа юлларымны алсаң,
Тиңләшерме тормыш диңгезе?

## Үз нурларын кайтар

Яшәвемнең яме китте, җаны китте,
Кая китте нуры күңелнең?
Син кояшын алдың көннең,
аен — төннең.
Йолдызларын алдың күгемнең.

Яшәвемнең яме булсын, җаны булсын,
Бар яктысын балкыт күңелнең.
Кояшыма, айга үз нурларын кайтар,
Йолдызларын балкыт күгемнең!

## Ядәч аерыштык

Вакыт белән ядәч аерыштык,
Мин отарга тиеш вакытны.
Сабаклары хәтеремнән чыгып,
Гел отылдым, инде ялкытты.

Вакыт отты мине, отып килде,
Янә мин аныңча эшләдем.

Сөюләрдә, көюләрдә отты —
Мәхәббәт дип телне тешләдем.

Ул сабырлык биреп отты кайчак,
Йә сабырлык бирми отты ул.
Юлга чыксам, серле сукмак куеп,
Кулларымнан тагын тотты ул.

Бүген тагын ядәч аерыштык,
Шаһит аңа ачык көн бите.
Ачык көнгә инде аек багам,
Саташмыймын төшне өн бит дип.

Отылулар онытырлык түгел,
Онытмадым иртән, кичен дә.
Төш җитсә дә, әле кич булмаган,
Сабаклары хәзер исемдә,
Исемдә.

## Сыерчыклар бала очыра

*(Лирик поэма)*

*Әниемә*

### I

Сыерчыклар чыр-чу бала очыра,
Әле төшеп,
Әле калкынып.
Ә син тагын
Күтәрмәдә калдың,
Нәкъ сыерчык кебек талпынып,
Шул язмышы ана халкының.
Шушы килеш
Күтәрмәдә менә
Син ничәнче кабат каласың.
Кошлар кайтмас,
Мин кайтырмын очып,
Көтеп-көтеп күзең талмасын,
Очырганда кошлар баласын.
Сәфәр чыгам,
Кошлар канат сыный,
Нинди юллар миңа дим очрар?!
Аналар да,
Кошлар да бит бер үк,
Балаларын шулай очыра,
Очмый булмый безнең бу чорда.
Без очарга туган,
Заман шулай
Көн дә канат куя яңадан.
Еракларга төбәп карашларны,
Каурый каккан җирне сагынам,
Канатлы кош булып кагынам.
Кайтыр микән кабат бу кошкайлар,
Онытырлар микән оясын?
Кошлар оя ташлап китә очып,
Тик моңсулык кына тоясың,
Нишләп ташлый алар оясын?
Ләкин беләм,

Канатлары җиткәч,
Ятмас инде алар ояда.
Тик очканда гына
Ныгый канат,
Очтым соңлап — шуңа оялам,
Озакладым бугай ояда.
Әллә кая
Юл алырлар алар
Күз ачып күз йомган арада.
Кошларда да
Нинди сәер язмыш!
Кошлар да бит ничек тарала,
Күз ачып күз йомган арада.
Таралыша,
Тавыш-тын басыла,
Эзсез-юлсыз оча кош кына.
Кошлар кошлар инде,
Тик без генә,
Без очмасак иде буш кына,
Эзсез очып яши
Кош кына.

## II

Чыр-чу үскән вакыт алга килә,
Очкан коштай
Үткән балачак.
Канат җиткергән җир —
Оям минем
Иң кадерлем булып калачак,
Бер көн — кола,
Бер көн ала чак.
Үкенмибез —
Булсын ала, кола.
Андый сүз чыкмастыр арадан.
Шуңамыдыр
Иртә күз ачылды,
Һәм аердык акны
Карадан,
Яман сүз чыкмады арадан.
Канатлана белдек
Канатсыз да,
Бала очырганда сыерчык.
Уйлаган бер —
Туйдырган җир иде.
Төшкә керә иде кыерчык,
Тешкә керми иде кыерчык.
Бөтен үлән тәмен
Татыдык без,
Кошлар татымаган тамырны.
Алар әллә каян җим тапсалар,
Белмәдек без каян табарны,
Тапкан булдык
Бары тамырны.
Табак-табак балтырганны инде
Иң-иң тәмле ашка санадык.
Иң кадерле икмәк икәнен дә
Ис белмәстән элек аңладык,
Иң-иң кадерлегә санладык.
Сыерчыклар

Парлап җим ташыса,
Син таптың бит безгә
Берүзең!
Ничек рәнҗемәдең дөньясына,
Әй булсачы икән бер сүзең,
Барысына булдың берүзең.
Шушы сыерчыклар сыман, үзең
Авызыңнан өзеп каптырдың.
Хәлеңне дә
Белмәгәнбез ул мәл,
Тик таптырдык,
Мин дә таптырдым,
Барыбыздан хәтта арттырдым.
Таңнан кырга китеп,
Тагын да син
Эшкә чумдың кайта иден дә,
Ул чак әллә
Колхозы да, без дә
Тик көн күрдек
Синең иңеңдә,
Торды дөнья синең иңеңдә.

## III

Вакыт үтте.
Кош баласы кебек
Авыз ачып көтеп ятмадык.
Авыр вакыт
Ару булмаса да,
Язмышка да
Каргыш атмадык,
Исемеңне һич тә сатмадык.
Тормышыңда күрдек
Хаклык хакын,
Һәр адымың бетте ятланып,
Шуңа да бит
Сиңа охшар өчен
Авыр, дөрес юлдан атладык,
Шушы хаклыкларга атланып.
Юлда, күктә булсын —
Бер җирдә юк
Хаклыктан да олы таяныч.
Аның белән була
Киерә басып,
Таянычың булмау аяныч,
Хаклык — җирдә иң нык таяныч.
Сыерчыклар да бит
Күмәк оча.
Ничек ансат
Очу ияреп,
Безне вакыт
Толпар булып көтсә,
Әзер торган заман ияре,
Һәр заманга җилдек ияреп.
Ә бит тормыш
Җилеп үтү түгел,
Белеп үтү өчен чак әле.
Толпарың да

Тиз дулатыр сыман,
Абайламыйчарак чап әле,
Тезгенеңне тотып чак әле.
Ерак максатларга
Юл ярганда,
Күз алларым китсә караеп,
Синең үткәнеңә
Күз салам мин,
Юлларыңа синең карыймын,
Күз алларым китсә
Караеп.
Синең баштан үткән авырлыклар
Бетмәс гайрәт,
Бетмәс көч бирә.
Шул көч белән
Барам хыялыма.
Ул дошманны җиңәр үч бирә,
Дустым таянырлык
Көч бирә.
Очыра да бөтен кош баласын,
Ярый әле кеше
Кош түгел.
Көтәсең син безне
Җәй дә, көз дә,
Салкыны юк,
Кышы кыш түгел,
Кайтуыбыз да бит еш түгел.
Гел көтәргә,
Әтиемне көтеп,
Күзең яшькә күпме югансың.
Әйтерсең лә
Бу дөньяга бары
Көтү өчен генә
Тугансың,
Шуның өчен дөнья кугансың.
Сыерчыкның балаларын үтеп,
Канат җиткерделәр улларың.
Без очабыз инде
Еракларга,
Уңсын гына диеп юллары,
Каш өстендә һаман
Кулларың.
Күзең юлда,
Уең бездә һаман,
Һаман бездә бөтен хәстәрең,
Шул хәстәрләр белән
Хәсрәтләнеп,
Хәсрәтеңнән ап-ак чәчләрең,
Кайчан бетәр икән хәстәрең.
Төшләреңне
Кат-кат сөйләп калдың,
Тагын кайтыр өчен тиз урап.
Сайламадык
Җирдә җиңел юллар,
Максат ерак әле, юл ерак,
Фатихаң бар изге юл юрап.
Кылалмыйча
Кылыр эшләремне,
Икеләнеп торган чагымда,
Синнән генә сорар

Киңәш туа,
Киңәшләрең тарта тагын да,
Эшкә кул бармаган чагымда.
Шундый чакта
Күңел юлга тарта,
Уйда барам синең киңәшкә;
Икеләнсәм,
Белер идем барын
Киңәшләрең булса янәшә,
Уең белән уйдан киңәшәм.
Гөнаһ кылсам,
Иң беренче булып
Керәсең син минем төшемә.
Шулчак үз-үземә хөкем ясап,
Хаталарга үзем төшенәм,
Син керәсең тәүдә төшемә.
Бөтен юл да
Туры гына түгел,
Күзне ача төрле хаталар.
Үч иткәндәй алар,
Юлда посып,
Гел сагалап кына яталар,
Яңа дөнья ача хаталар.

**IV**

Тагын менә
Күтәрмәдә калдың,
Нәкъ сыерчык сыман
Талпынып.
Баш очында кошлар
Канат сыный
Әле төшеп,
Әле калкынып,
Куанычларыннан талпынып.
Чыр-чу килеп
Оча сыерчыклар,
Алар белән бөтен күк тулы.
Башлап канат җилпи
Бала кошлар —
Нинди җиңел икән күк юлы,
Алай түгел җирнең күп юлы.
Кошлар оча...
Минем юлым җирдә...
Аерма син, юлым, җиремнән.
Соңгы тирем минем
Шуңа тамсын,
Әремле тузан булсын ирендә,
Тозлы тирем калсын җиремдә.
Күздән югалдылар сыерчыклар,
Авылым да,
Син дә яшрендең,
Кулың һаман
Каш өстендә калды,
Җил сөрткәндер тамса яшеңне.
Күк томанда калып
Яшрендең.
Көн битендә юлны үбим әле,

Зәңгәр офык аша артылып.
Ераклашкан саен
Якынаям,
Әни, сиңа күңел тартылып,
Үзем барам офык артылып.
Аяз тора көне,
Күңел кебек,
Кайнар кояш балкый түбәмдә,
Томан кунар җирдә
Рәшә уйный,
Яшел үлән аңкый түбәндә,
Балкып тора көне түбәмдә.
Сәфәр чыктым
Сыерчыклар белән.
Юлым ерак,
Булыр газабы.
Күңелемдә сиңа рәхмәт җырым,
Юлның,
Җырның булмас азагы,
Ничек булсын инде
Азагы?!

# «Сөю иртәсе» китабыннан

# (1988)

**Хәерле иртә!**

Хәерле иртә, дөнья!
Хәерле көн!
Сиңа хәерле кич телик без.
Яңа көнгә,
Елга,
Гасырларга
Төкле аяк белән килик без.
Хәерле иртә, җирем,
Бар кыйтгалар,
Кар астында калган тамырлар.
Ышанаек:
Туңган орлыклар да
Язын шыту юлын табарлар.
Шаулы елгаларың
Әле тыныч,
Боз астында акса сулкылдап.
Туң читлеген
Үзе бәреп чыгар,
Җиргә гомер өстәр дулкыннар.
Чәчкәгә дым артыр,
Кошларга моң кайтыр,
Яуган карлар эреп акканда.
Бәхет мәңге бизмәс,
Җир өстендә
Таңнар һаман тыныч атканда.
Хәерле иртә,
Газиз кешеләрем!
Сезнең кулда — җирнең тоткасы!
Бер минутка ычкындырма,
Әле ышанычлы тоткансың.

Хәерле иртә, дөнья!
Хәерле көн!
Сиңа хәерле кич теләек.
Яңа көнгә,
Елга,
Гасырларга
Төкле аяк белән киләек!

## Вакыт оча ярсып

Авызлыгын тешләп җилә вакыт,
Бер көн кебек үтә мизгелләр.
Бүген бозлар тотса, иртәгәсен
Сулар ургып таша Иделдә.
Илнең бер чигендә кояш чыга,
Бер чигендә инде көн байый.
Яшәлгәнне менә барлап кара:
Минут кебек үткән көн, ае.
Ярсу заман! Вакыт оча ярсып,
Үтә еллар керфек какканчы.
Бүгенгесе белән киләчәкне
Уйлау кирәк иртүк, ятканчы.
Ак биләүдәмени — кар астында
Җирем черем итә изрәп.
Туң туфракка орлык түзми ята
Шытып чыгар өчен тизрәк.
Кыш еш түгел, елына бер килә,
Кар да түгел йөкнең авыры.
Җирем белә шушы карның эреп,
Беркөн яңгыр булып яварын.
Вакытында булсын бөтенесе:
Тиз китмәсен мизгел тиз килеп.
Мизгелләрдән, елдан, җилдән, күктән
Җирем күзе көтә изгелек.
Ярсу заман! Вакыт оча ярсып.
Имин торсын инде юллары.
Еллар имин килсә — дөнья имин,
Куанычлы булыр еллары!

## Куанам

Мин куанам: туганыма,
Чыкларга бит юганыма,
Торганыма, ятканыма,
Яңадан таң атканына.
Мин куанам: җил искәнгә,
Агачлар һәм гөл үскәнгә.
Сандугачны тыңлавыма,
Җирдә моңнар тынмавына.
Мин куанам: тереклеккә,
Бар табигать тереклеккә.
Тауда киек булганына,
Суга балык тулганына.
Мин куанам: туган җиргә,
Җандай күргән Туган илгә,
Аның бетмәс куәтенә,

Иң-иң изге ниятенә.
Мин куанам: кешеләргә —
Җир яшәтер ишеләргә.
Олы сугыш юклыгына,
Халыкларның ныклыгына.
Һәммәсенә мин юанам,
Һәммәсенә мин куанам,
Таңда куанып уянам.

## Дуслык төяге

Иң олы сүз бездә дуслык бит ул,
Ни кадерле ныклы дуслыктан?!
Илемдәге бу какшамас рухны
Алмадык без барып бушлыктан.
Ул яралды хаклык теле белән,
Куәтләнде туган телемдә.
Җирне имин тотар бүгенгем дә
Шуннан туды минем илемдә.
Без әйтерсең дуслык милләтеннән,
Барыбыз да тиң, шат, затлыбыз.
Үзебез тапкан уртак кот-бәхеткә
Бөтенебез бердәй хаклыбыз.
Җирем бүген бәхет төягедәй,
Монда мәңгелеккә таң аткан.
Тагын яктыракка талпындыра
Дуслык дигән талмас канатлар.
Ул нурларны, ул җылыны хәзер
Сабый тоя хәтта бишектән!
Нинди телдә сәлам бирмәсеннәр —
Бездә һәрчак ачык ишекләр.
Җирем белә: нинди дус килсә дә,
Туганыдай башкорт кочканын.
Уралымда, дуслык түбәседәй,
Бәхет, шатлык, хаклык төягедәй,
Балкый минем Башкортстаным!

## Йөрәк яше

Йөрәгемнең була төрле чагы:
Унҗидедә кебек типкәне;
Шулай тибә кайчак — уйлап куям:
Әллә йөзне үтеп киткәнмен.

Төрле чагы була йөрәгемнең:
Унҗидедә, әллә йөздәме?
Әллә гомер бакый, кораб сыман,
Шушы аралыкта йөзәме?

Унҗидедә тоеп йөрәгемне,
Артык аптырап та куямын;
Ил ирләре белән уйланганда,
Йөздәге карт кебек тоямын.

Йөрәк биреп эшләгән эш кенә
Ул ирләрне шулай ир иткән,
Туган, торган җирләремне алар
Дөнья сокланырлык җир иткән.

Мин, чамалап алар кимәленнән,
Барлап-барлап чыктым эшемне.

Тик башкарган эшем асылыннан
Тойдым шулчак йөрәк яшемне.

## Җирем — ак дәфтәр

Ап-ак җирем — чиксез сихри дөнья,
Бөтен нәрсә чумган шатлыкка.
Гүя акка төшәр кара беткән,
Кайгы өреккән ап-ак сафлыктан.
Йөзең якты, нурлы йөзең балкый,
Җирем — башланмаган ак дәфтәр!
Карлар хәтта кузгалырга кыймый,
Әйтерсең лә сабыр, сак дәртләр.
Агачларга ялтыр бәсләр булып
Сәер моң сарылган тавышсыз.
Кышкы кошлар гына аңлыйдыр ул
Шушы моңның чын, хак аешын*.
Җирем, синдә татлы хыялымы
Туй күлмәге кигән яшь кызның?
Кыекларда боз бармаклар ялтлый —
Көн битендә нигә яшь койдың?
Мөгаен, ул шатлык яшьләредер,
Көлгәнсеңдер күңел аязда...
Кояш күпме җиргә якынайган,
Килеп чыккан көндез ай каян?
Алар сиңа сокланалар шулай,
Сокланалар карап якыннан.
Ай соң нәрсә уйлап туктап калган
Синең белән кояш хакында?
Ул — мәңгелек изге мөнәсәбәт,
Намустай саф сезнең арагыз.
Син бит гүя ак биләүдә генә,
Ә кояшның — тәүге карашы.
Йөзең якты, җирем, балкый нурың,
Күңелләрдә — ярсу, саф дәртләр.
Ихласлыкка гына ачылган ул,
Ак җир — башланмаган ак дәфтәр.

## Иске Бәпестә сугыш корбаннарына куелган обелиск янында

Бүрек салып,
Тагын уйга баттым.
Ярсу февраль һаман шашына.
Бура карлар сылый
Болай да бит
Байтак карлар яуган башыма.

Күпме исем.
Ташка язылганнар.
Монда — әллә ничә йөзләгән...
Миннән алда
Сукыр ана килеп,
Һәр хәрефне капшап,
Улы исемнәрен эзләгән.

Басыл, буран!
Бүген килүчеләр
Мин — тәүгесе, түгел соңгысы.

Аккан күз яшьләре — нигә икән? —
Карны тишә,
Килми туңасы.

Исемеңне, әткәй, карап торам,
Уйлавы да бераз ятрак:
Яшькә хәзер
Сине үтеп киттем,
Яшьне еллар елдам арттыра.
Син дөньяда
Яшьли торып калдың.
Дәвам итәр юлың
Алганмын.
Кичерәмен —
Синең йөрәк белән,
Җиргә —
Күзең белән багамын.
Максат итеп
Син калдырган юлны
Бар яшәвем белән аклыймын.
Көн дә кояш чыга.
Карлар ява.
Планетаны имин саклыймын.

## Чыршы тургайлары

Учлап көмеш акча сипкән сыман,
Пыр-пыр күчеп күрше чыршыга,
Салкыннарда җылы эзләп китми,
Урманына тугры кыш чыга.

Буран дими оя кора алар,
Җылыталар салкын оясын.
Авыр чакта туган яшь кошчыклар
Бизи, нурлый урман дөньясын.

Берләнбер хәл — гаҗәп! Кыш өстендә
Бу тургайлар бала очыра...
Сезне ничек тотып яратырга,
Кайнар йөрәгемә кысарга?

## Мизгелләр

Буталгандыр кебек мизгел,
Буталгандыр кебек ай.
Көзләре килә ашыгып,
Язлары килә бик җай.

Башланды кыш әллә ничек,
Йә яңгыр, йә кар яуды.
Әллә кышның үз-үзенә
Күңелеме тарайды?

Юньле кар юк, зәһәрле көн,
Кышның каты салкыны.
Җәендә — кышның суыгы,
Кышта — җәйнең ялкыны.

Без бит җәйдән җәй көтәбез,
Кышны кыштан көтәбез.
Мизгелләргә үпкә белән
Сукранышып бетәбез.

Менә бер ачуланыпмы,
Гарьләнепме чак кына,
Катырып-туңдырып алды,
Буран өрде сак кына.

Үзенә кереп китте кыш,
Чая ир кебек әнә...
Җәен туңган күңел эри,
Туңар йөрәгем яна.

## Юлда

Сирәк-саяк күзләреңә багам,
Юл ашыгыч түгел, вакыт бар.
Онытылып өнсез калган чакта,
Тик шыгырдап куя салкын кар.

Синең белән озын юлга чыктым:
Күрәселәр бардыр бетмәгән;
Төшкә кермәгәннәр өндә булыр,
Уңышлар да үзең көтмәгән.

Мин ялкынлы юлда барганым бар,
Уттай көндә, уттай кабынып;
Ут дөрләтеп дуслар атладылар...
Ә көн уты сүнде, ягылып...

Күпне күреп, азны тойдым микән,
Тик ялкында дисәм якынлык?!
Яуган кардай синең сабыр караш,
Җылы бирә тыныч салкынлык.

## Аюлар

Салкын дөнья өшәндереп китә,
Әче җилләр капшый колактан.
Аю сынлы аю әллә кайчан
Өннәренә кереп олаккан.

Хәтта тургай чыркылдаган була,
Очкан килеш туңып төшсә дә.
Ә бу чакта, беләм, өндәгеләр
Җылы төшендә дә өшәнә.
Җәйнең балын ашап, малын ашап,
Җылы чакта ничә ай уза.
Дөнья җылытырлык җан кирәктә
Өннәрендә ята аюлар.

## Кыска көннәр

Бер күрсенү хәтле генә
Гомере кышкы көннең.
Аның шәме баш очында
Кабынды дисәм, сүнде.

Гашыйкларның хыялымы —
Кыска көн, озын төннәр?!
Ил аягы һил булмастан*,
Уяна назлы өннәр.

Көн җиткерми, төн җиткерми
Ялгана таңга таңнар.
Мәңге яшәсәң, бетмәслек
Бурычлар бара янда.

Көн үтүе, гомер кебек, —
Күз ачып йомган ара.
Кыскарган саен — исәпле,
Тик кадерләнә бара.

## Бәрәңге чәчкәләре

Бәрәңгеләр шау чәчкәдә вакыт,
Чәчкә аткан шундый күпереп.
Балачакның өмет чәчкәләре —
Яшәвемә илткән күперем.

Шул иде дә күзне терәп торган,
Бары шул иде бит ышанган.
Бакча уртасында өнсез торам,
Бернәрсә юк янда кымшанган.

Бәрәңгеләр күкрәп чәчкә атса,
Өмет чәчкәләре шыттылар.
Шуның белән генә үткәрелде
Язны, көзне, салкын кышны да.

Куанганда җирдә яшәвемә,
Ул һәрвакыт минем исемдә.
Әле дә бит өнсез торганымда —
Рәхмәт укып торам эчемнән.

Алма бакчасына кермичә, мин
Кереп китәм олы бакчага.
Шушы чәчкәләрне шәһәрләрдә
Табып булмый хәтта акчага.

Ерак ызан күз алдыннан уза.
Еш-еш тибә йөрәк сулкылдап:
Ап-ак чәчкәләргә әллә чыклар,
Әллә яшем тама тупылдап.

## Башкалар шикелле

Яшимен каршылап һәр таңны,
Иртәне беренче күргәндәй.
Моңаям, кояшым — ал йомгак —
Иң соңгы нурларын төргәндә...
Мин дә бит башкалар шикелле.

Һәр көнне эшемә киткәндә,
Тауларны аударыр көч тоям.
Кулымны чак селтәп кайтканда,
Арудан тагын да көч җыям...
Мин дә бит башкалар шикелле.
Исемнән чыкмастыр кичергән,
Йөрәкне яндырып үткәннәр;
Һаман да тып-тыныч китмимен,
Матурлар яныннан үткәндә...
Мин дә бит башкалар шикелле.
Тугрымын мин сиңа, тик аны
Кирәкме торырга кабатлап?!
Әйе шул, төрлерәк булды шул
Бу тормыш укыткан сабаклар...
Мин дә бит башкалар шикелле.
Бу дөнья туйдырмас: мин беләм,
Бер китсәң, кайтмассың әйләнеп.
Шуңа да айларга, елларга
Язмышны ныгытып бәйләдем...
Мин дә бит башкалар шикелле.

## Уңдык

Әйе, уңдым, күп нәрсәдән уңдым.
Миннән уңдымы икән бүтәннәр?

*М.Кәрим*

Уңдык, синнән уңдык. Рәхмәт яусын!
Ил кушылыр ихлас сүземә.
Синнән дә нык уңдык синнән,
Сиздерүе авыр үзеңә.

Туган, торган җирләреңнән уңдык,
Бер туфракка тора-авабыз.
Шатлыкларың, кайгыларың уртак,
Әле дә уртак сулар һавабыз.

Бер чаткысы гына шушы сүзем
Олы канәгатьлек хисенең.
Читкә чыксак, һәрчак алдан йөри
Бер танытма булып исемең.

Җирем төсе бары җырың аша
Күз алдына баса күпләрнең.
Исемең белән җирем исемен,
Аның данын ничек күтәрдең.

Илем өчен үзе бер куаныч —
Шулай биек башкорт очканы.
Ил агасы булыр ул тудырып,
Уңды синнән Башкортстаным.

## Әбиләр чуагы

Быелгы көз сәеррәк булды:
Җылы нурлар бармый түгелеп,
Әби чуакларын көтә-көтә,
Әниләрнең талды күңеле.
Тезелешеп сирәк утырдылар,
Сирәк утырдылар чуакта.

Тәңкәләрен саран сипте алга
Эргәдәге сары куаклар.
Хәбәр-хәтер үтә кыска булды.
Таралышты алар өшәнеп.
Бергә күрешүдән, кояштан да
Эчләренә җылы төшмәде.
Заманында алар җир җылыткан,
Ир җылыткан, илне җылыткан.
Шуңа безнең йөрәгебез кайнар,
Тамырларда таша җылы кан.
Аналары илнең өшәнмәслек
Җылы таратыйк без күңелдән, —
Күңел җылысыннан өзелмәсәң,
Ул ким булмас җылы күгеңнән.
Әби чуагыннан мәхрүм көннәр
Салкын булмас әле алай ук.
Әбиләрнең җанын җылытырлык
Һәрберебез кояш булаек!

*** * ***

Көн авышып килә. Ниләр эзләп
Сукмакларны кат-кат тападым?
Тапканымны күпме югалтсам да,
Югалтканны кабат тапмадым.

Югалтулы булды байтак юлым:
Җан дусларны күмдек иртәрәк.
Барганыңда әле олы юлда
Күпме ир таяныр ир кирәк!

Мәхәббәтнең җете нәкышләре
Томалады кайчак күзләрне.
Ләкин аның ачы сагышыннан
Ачылдылар азак үзләре.

Җәпле сүзем чәпкә* тими калды,
Әйле-шәйле күреп чәпләрен.
Тынгысызлык җанны тындырмады,
Бушка булгалады хәстәрем.

Абзарымны гел ныгыткан булдым,
Аргамагым инде югалгач.
Өметләрем кабат томаланды,
Тай-тулагым җилеп юл алгач.

Яшьлегемдә, яшьнәр көннәремдә
Уйлаган бар: әле соң түгел.
Бүген килеп хисап сорасалар,
Бөтенесе, аһ, дим уң түгел.

Көн авышып килә. Җитәр бермәл
Аның күз бәйләнер чаклары.
Көн калдырган нурларны мин җыям,
Күңелемне кат-кат актарып.

## Киек казлар тавышы

Һаваларны уттай ярып бара
Кыелып очкан казлар тавышы.
Һава түгел, йөрәкләрне яра,
Аңлап булмый бөтен аешын*.

Көз китәчәк кызлар моңымы ул —
Нәкыш-нәкыш чигү чиккәндә?
Яшь солдатның ярсу җырымы ул —
Ил сакларга чиккә киткәндә?

Аксакалның хатирәсе мәллә —
Җир селкеткән чагын уйлавы?
Җитмеш яшьлек әби уе мәллә —
Яры аның ничек урлавы.

Ул тавыштан ялкын ягылып китә,
Чагылып китә сулар агышы.
Ул тавышта — күкнең күкрәүләре,
Газиз җирнең бөтен нәкыше.

Казлар китә шулай табигатьне
Көзге йокысыннан уятып.
Агачларда, үләннәрдә — сагыш,
Һәр тарафта кала уй ятып.

Күп уйлардан тубал булган башлар
Чатнап китә шушы тавыштан.
Ничек шулай казлар иңрәвендә
Ут-су, җир-күк бергә кавышкан?..

## Урал курае

*Заһир Исмәгыйлевкә*

Туган җирем — торган бәхет иле —
Моңнар белән яши уралып.
Курайларның өне агылганда,
Телгә килә бөтен Уралым.

Һәр авазда яңгыраган кебек
Кичергәне газиз җирләрнең...
Тавышында чагылгандай була
Җирнең меңәр еллык серләре.

Аннан шулай җирем моңы таша,
Кеше күкрәгенә тулышып,
Мәңгелекнең өметләре ага,
Анда җирнең бөтен сулышы...

Төяккәем — моңнар бишеге ул,
Балкый дөнья җырдан нур алып.
Офыгында моңнар ургылганда,
Телдән язмас мәңге Уралым.

*** * ***

Кичнең шәме — ерак айга бактым,
Нәрсәгә дип нуры кимеде.
Нигә кинәт уты тоныкланды,
Җаны китте дөнья яменең?

Ай өстеннән, баксаң, болыт ага,
Ай йөзенә төшкән күләгә.
Кичне бизәр мөлдерәмә нурлар
Болытларга икән эләгә.

...Хисне бизәр күңел нурларын да
Кайчак капламакчы болыт бар.
Ул барыбер күләгәләр сала,
Янсаң да син ялкын булып та.

Күз алдыма килде бер хакыйкать
(Айны әйтәм, түзгәч түзә бит):
Айны каплый язган кара болыт
Аннан күпкә түбән йөзә бит.

*** * ***

Көтмәгәндә туктатты бер телсез,
Ни сорыйдыр миңа өн бәреп.
Күзләрендә шундый утлар яна,
Берничек тә булмас сүндереп.
Үтенече, сүзе — шул утларда,
Аңлашылмый бары ым гына.
Юл чатында, ярдәм итә алмый,
Мин баш ватып торам шым гына.
Ул китте дә бетте,
Ләкин минем
Шуны күпме искә алган бар:
Синең алларыңда телле көе
Ничә кабат телсез калган бар...

*** * ***

Тәрәзәмнән тышка караем:
Иртә башлана бит кар ае.

Каңгылдашып казлар китмәгән,
Канатлары ныгып җитмәгән.

Кар аралаш микән очарлар?
Әллә нишли мизгел — чорлар да.

Көз беләң җәй иртә буталды...
Йөрәгемне тагын ут алды.

## Сөю иртәсе

Җирем гүя иртән матуррак,
Кояш гүя иртән шатрак.
Сулар гүя иртән татлырактыр,
Һава гүя иртән сафрак.

Иртәнге җыр кичәгедән моңлы —
Тыңлап туеп булмый һич кенә.
Иртәнге җыр тагын да ягымлырак,
Иртәнге йөз якты кичкедән.

Таң тудымы — күзләреңә карыйм,
Тәүге тапкыр гына баккандай.
Кояш синең өчен чыга сыман,
Таңнар синең өчен аткандай.

Соңгысыдыр кебек һәрбер иртә,
Каршы алам көтеп-сагынып.
Яшәү, гүя ямең шул иртәдә,
Мин яшимен таңга табынып.

Белми калма берүк, сизми калма —
Иртәләрнең нуры, иркәм, син.
Каршылыйк без бергә иртәләрне,
Һәрбер иртә — сөю иртәсе.

## Сүз солтаны

*Галимҗан Ибраһимовның 100 еллыгына*

Солтанморат,
Солтан булмасам да,
Бүген морадыма ирештем.
Ул сулаган һаваларны сулап,
Шул туфрактан атлап килешем.

Кичерешләр сөйләп бетергесез,
Күреп туйгысыз бит кешеләр;
Һәркем монда дәрәҗәсен белә:
Күңелләре бөек, эше дә.

Яңа очышларга, биеклеккә
Алар тагын юлын табарлар.
Бүген матур җимешләрен биргән
Җирдә җәйгән тирән тамырлар.

Орлыклары җиргә төшәр алда
Яралгандыр тормыш утыннан.
Ул тамырлар янә куәт алган
Башкорт туфрагының сутыннан.

Солтанморат хезмәт, иҗат иле —
Монда һәрчак шулай таң атар,
Шушы горур исем алда күпме
Яңа буыннарны уятыр.

Сүнмәс йолдыз балкыр һаман күктә
Халык күңеленең чулпаны.
Ул — тылсымлар асыл сүзләрнең
Морадына җиткән солтаны.

## Карлар булып...

*Игенче якташларыма*

Карлар булып җиргә бәхет ява,
Карап туймам ничек яуганын;
Йөгерешеп йөреп сабыйларның
Бәхет өсләрендә ауганын.

Карлар булып җиргә сафлык ява,
Күңелләрне били пакь уйлар.
Күз алдында матурлана дөнья,
Сабый карда дулый сабыйлар.

Карлар булып җиргә байлык ява,
Ләкин түгел алтын-көмешләр.

Алтыннардан артык ил эчендә
Хаклы мәхрүм булмас өлештән.

Карлар булып җиргә ырыс* ява,
Кар-яңгырлы еллар ырыслы.
Яуган карлар уңыш булып калкыр,
Урманнарның аңкыр ылысы.

Рәхмәтләре булып аксакалның,
Сабыйларның аклап өметен,
Бар дөньяны берчә сафлап-пакьләп,
Әйдә яусын карлар көне-төн.

Кеше уен тоя табигать тә,
Ул да бүген нинди инсафлы.
Бөтен нәрсә изгелеккә өнди,
Хыялларның туа иң сафы.

Әй, мизгелнең шундый сихри чагы,
Гаҗәеп мәл кышым иртәсе.
Яуган карлар алдан сөйләп ява
Еллар хәерлегә илтәсен.

*

Эре иләктән әллә иләнәме,
Җилпучтан ул әллә җилпенә;
Оетыплар бурап кар яуганда,
Оеп торган күңел җилкенә.

Кара җирем әнә балкып киткән,
Ак он сипкән сыман агарып.
Как түмгәкләр ак калачтай булып,
Пешеп чыккан гүя кабарып.

Ел уңышлы, дибез, иген уңса,
Билгели дә еллар уңышын.
Шуңа карый җирем тын алышы,
Бөтен кешелекнең сулышы.

Әнә шуңа басуларга чыгам,
Карлар яуса — уем игендә.
Иген белән дөнья имин килә,
Тормыш тора икмәк иңендә.

*

Әй җырлыйсым килә игенчене,
Әй зурласым килә кулларын!
Күрсәтәсе иде күңел-уен,
Изгеләрдән изге юлларын.
Беләм үзем җырлый алмасымны
Сабан тургаеннан арттырып:
Күпме ярышсам да аның белән
Көн баетып, таңнар аттырып.

Һәр икмәктә булган җылы сөйли

Аның кулларына тиңлеген.
Дәрья булып шаулап басу җырлый
Күңеленең нинди киңлеген.

Иген дәрьялары, пешкән икмәк
Башлап кулларында ярала.
Күңелемдә, хыялымда шытып,
Шуннан гына кырга тарала.

Нинди телдә әйтеп була икән
Сиңа булган кеше рәхмәтен?
Ничек итеп аңлатырга була
Синнән күргән дөнья рәхәтен?

Барсында да синең катнашың бар:
Таш актару, оек бәйләүдә;
Җиһаннарга очу, җир сөрүдә,
Мал көтүдә ерак җәйләүдә.

Синсез беркем бер генә көн тормый:
Биюче дә, җырлар язган да.
Чиктә постта торган, ГЭСлар корган,
Сулар эзләп кое казыган да.

Һәммәсендә синең катнашың бар,
Кулларыңда тора тереклек.
Икмәк хакын белгән кешеләр бит
Пешкән икмәк кебек беректе.
Пешкән икмәк!
Җирдә кояш кына,
Кояш кына шулай яшәтә.
Пешкән икмәк белән янган кояш
Планетаны, җирне яшәртә.
Җирдә кояш кына икмәк кебек,
Тик ул гына мәңге ялкытмый.
Ә икмәксез калсаң,
Хәтта кояш
Көннәреңне артык балкытмый.

*****

Бурап карлар ява...
Искә төшә
Калган еллар карлар астында.
Еллар! Сезнең алдыгызда торам,
Малай гына булып бастым да.

Әле булса өшәндереп үтә
Ул елларның кары-бозлары.
Яман төштәй исләремә төшсә,
Дертләп китәм,
Тыгыла бугазым.

...Туңган тәрәз кебек күгәргәнбез,
Учакларга ягар утын юк.
Кайнар умач сөйләп саташабыз, —
Үзәкләргә үтә кыенлык.

Шул мәл карны каргаганым булды,
Салкынлыгы өчен каргадым.
Истән чыкмас төннәр: утын өчен
Әни белән көртләр ярганым.

Зарланмады әни кыш салкынга,
Кар яуганга, каты буранга.
Сабыр гына сөйләп китәр иде,
Күз салыр да карлы урамга:

— Түзегез сез, балалар, яусын гына,
Иген белән тулар буралар;
Мал ишәер, китмәс муллык килер,
Җанланырлар бөтен куралар.

Яусын гына. Еллар әйбәт килер,
Кар-яңгырлы еллар игенле.
Буран туктар, бермәл тынар туплар,
Мәңге килер җиргә иминлек...

*

Сүзләрең хак булды.
Килде көткән.
Карлар ява... Сүзең хәтердә...
Шул сүзләрне мамык карны изгән
Малаема кирәк әйтергә.

Басуларга, җилгә таратырга
Сөенчеләп китәм атлыгып.
Җирдә торган саен ныграк тоям,
Әни, сүзләреңнең хаклыгын.

*

Сөенечтән ераккарак чыгам,
Кереп тормый күрше-күләнгә.
Яфрак ярыр агачларга китәм,
Юл буенда үсәр үләнгә.

Салкын сукмаганмы уҗымнарны,
Кар астында ничек җир тыны?
Җилләр кырга нинди хәбәр ташый,
Әле ярсып, әле бер тынып.

Бетәшкәнме җирем ярыклары
(Ярылды бит коры көннәрдә).
Җир ярыгы, күңел ярасыдай,
Сызландыра җылы мендәрдә.

Менә хәзер басуларга чыккач,
Кайда күчте күңел ярасы?
Карлар булып җиргә шифа яуган,
Шуннан канатланып барасың.

Тракторлар гөрләп кар тоталар,
Балкып кала ап-ак тасмалар.
Алар тракторчы хыялында —
Калкып ятар калын ясмалар*.

*

Карлар ярып, яныл кайтып киләм,
Юешләнеп беткән чабулар.
Тәңкә-тәңкә булып түшәлә кар,
Элеккечә карда — сабыйлар.

Беләм, бүген бер мин генә түгел
Канатланган шулай, куанган;
Түбәләре биек күккә тиеп,
Тик берүзем түгел юанган.

Таулар ярып яңа юл салганнар,
Изү чишеп урман кичкәннәр.
Карга карап бердәй сөенәдер,
Кар өереп җилләр искәндә.

Игенченең, тегүченең дә бит
Шатлыклары бер үк зурлыкта.
Һәркем күңелендә бәхет шыта,
Җиргә төшәр алтын орлыктай.

Туар көннең яктылыгы төшеп,
Балкып яна атар таңыбыз.
Көн сулышы белән тын алабыз,
Гайрәт таша,
Кайнар каныбыз.

Ышанамын: уңган игенчебез
Максатына эшен тиңәйтер.
Күтәрелеп торып тәнен язса,
Иңе белән офык киңәйтер!

## Җир ярасы

Язгы сулар җирне ертып аккан —
Ат очарлык тирән ерынты.
Җир ярасы бетәшердәй түгел,
Шуңа әрни күңел, җырым тын.

Канлы яра сыман кызыл ярлар
Тирәнәеп һаман арталар.
Җир ярасы миебезгә бәрә, —
Гүя алар минем аркамда.

Язлар ярсу, язлар изге дә бит...
Нинди яра кала җәйләргә!
Аларны соң ничек дәваларга,
Нинди куллар белән бәйләргә?

## Ак яңгырлар

Ак яңгырлар килә — әйтерсең лә
Ак толпарның ап-ак яллары.
Шул яңгырлар килсә, хәтта кичен
Яктыргандай күзем аллары.

Ак яңгырлар ява. Ә мин менә
Хәтерлимен аның карасын.
Күрмәгән бер адәм, кара яңгыр
Булмый, диеп әйтеп карасын.

Була, була! Әле сабый идек,
Үтә авыр сугыш заманы.
Ак яңгырлар бер дә яумый иде,
Бик еш яуды кара, яманы.

Салам башлы безнең иске өйнең
Түбәсендә давыл котыра.
Түшәмдәге кара туфрак аша
Яуды өйгә яңгыр туп-туры.

Өреккән куян баласыдай булып
Баса торган идек мөешкә.
Көннәр буе кара яңгыр коя, —
Үтә мул эләкте өлешкә.

Ничәмә ел ак яңгырлар килә,
Каршы алам аны кул чабып.
Кайчак дертләп китәм, искә алып
Кара яңгыр яуган ул чакны.

Ак яларын чайкый яңгыр-толпар,
Кирәк түгел камчы сугасы.
Яңгыр коеп үтә. Җәйгор калка —
Ак толпарның алтын дугасы.

## Сибай

Бар дөньяга даның китмәсә дә,
Минем карамакка син зурсың.
Күңелемдә син бердәнбер кала —
Тик үзеңчә генә матурсың.

Ирәндекнең иркен итәгендә
Рәхәтләнеп канат җәйгәнсең.
Салкын кышта җирне җылытасың,
Бер гөлләмә — бизәк җәйгә син.

«Сибай — сыбай» дип тә кемнәрдер бит
Әйтеп куйды синең хакында.
Чабып китәргә син җыенмыйсың,
Даның гына җилсен атыңда!

Мәңгелектән калкып чыккансың син,
Шундый яшәү уйлый халкың да.
Тамырларың синең тирән киткән,
Тамырларың бакыр, алтыннан...

## Уен кыска икән

Бу гомернең шундый мәле житте,
Шундый чагы житте, кордашым:
Чәчелмәгән күпме безнең өлеш,
Күпме урылмаган кырлар соң!

Яңа гына ябык, бүз малайлар
Онытылып туплар типтек бит.
Туплар әллә кая очкан кебек,
Без күкләрне хыял иттек бит.

Уен кыска икән. Без тормышта
Җитди ярга килеп җиткәнбез.
Уйнау уйда да юк. Күп нәрсәне,
Ахры, уен кебек көткәнбез.

Җилләр биткә бәреп каты исә,
Җиңел түгел буын катса да.
Безгә инде бил бирергә түгел,
Кемдер каршылыклар атса да.

Без тормышның шундый ярындабыз,
Ир яшендә күптән һәммәбез.
Бүз малайлар карап торган чакта,
Комга терәлмәсен көймәбез.

*** * ***

Синең шундый матур чагың иде,
Минем шундый батыр чагым иде.

Күккә кәпәч чөйдем табышканга,
Түбәм күккә тиде кавышканга.

Вакыт хәзер төрле эзләр салды,
Юллар саны инде йөздә калды.

Мин яшимен матур чагың белән,
Ә син — минем батыр чагым белән.

## Яңабаштан

Кай эшләрең барып чыкмаганда,
Яңабаштан килә башлыйсың.
Вак-төяген кайчак эзсез генә
Онытасың килә, ташлыйсың.

Ләкин мәңге онытылмаслык нәрсә
Ята дулап күңел төбендә.
Кулдан килсә кабат кайтыр идең,
Яңабаштан башлап бүгеннән.

Сорасаң да, күпме ялварсаң да,
Үткән инде: «Әйдүк, йә!» — димәс.
Үкереп еласаң да, күп нәрсәне
Кабат башлау, беләм, тәтемәс.

Әйләнә җир. Кояш көн дә чыга,
Язлар килә гөлгә күмелеп.
Тик белмисең икән күп нәрсәнең
Яңабаштан мөмкин түгелен.

*** * ***

Эчем поша: төркем бүз тургайлар
Фырлап очып күздән югалса,
Көзге кызгылт учак яфраклары

Җырлап очып соңгы юл алса,

Мин шатланам: теге бүз тургайлар
Яңа язда ишле күренсә,
Кызгылт яфрак яткан сутлы җирдән
Яшел үлән көнгә үрелсә.
*** * ***

Агыйделдә актарылып ага,
Язгы бозлар ага ахактай.
Күңелемдә акмас бозлар ята —
Рәнҗетелүдән алар, нахактан.
Гайрәтле яз, миңа өйрәт әле:
Ничек эретергә бозларны?
Боз акканга карап торам үзем,
Күңелдәге бозга бузарып.

## Чыкты

Көн белән төн бәрелеште:
Чаткы булып кояш чыкты;
Тәүге ләйсән җиргә сеңде —
Кинәт шытып кыяк чыкты.

Чит берәүнең шатлыгыннан
Куанычлы яшем чыкты.
Бер туң йөрәк эндәшмәүдән
Йөрәгемнән яшен чыкты.

Кем соң әле — үрләү өчен —
Җан дустыннан аша чыкты?!
Башка берәү чит өчен дә
«Җылы» җирне ташлап чыкты.

Тик буталчык хәлләрне дә
Теге мескен ерып чыкты.
Мин шуларны күреп тордым, —
Шуңа шушы җырым чыкты.

*** * ***

Мине таңда уятмагыз,
Таңда үзем уянам,
Урманнарга чыгам әле
Кош очканчы оядан.

Кошларны дим уятыйм мин,
Алар мине көтмәгән.
Ә бит саф чыкларны коеп,
Әле берәү үтмәгән.

Көтсен, суынсын да әйдә
Әниемнең ашлары.
Тоташ кояшны күтәрә
Әнә агач башлары.

Туган җирнең бер бәйрәме —

Чыгам таңда атлыгып.
Кояш белән уянмаган
Беләме көн шатлыгын?

* * *

Башка берәү гөнаһына
Сугып егалар мине.
Үпкә тотмадым һичкемгә,
Хата миндәдер дидем.

Егылган туймый көрәштән, —
Мин тагын торып басам,
Китәм икенче мәйданга,
Юл капчыгымны асам.
Башка берәү гөнаһына
Сугып егалар мине.
Үпкә тотмыймын һичкемгә,
Ялгышканнардыр димен.

Егылган туймый көрәштән, —
Мин тагын торып басам.
Киләм өченче мәйданга,
Юл капчыгымны асам.

Башка берәү гөнаһына
Сугып егалар мине.
Сискәнеп киттем, ниһаять,
«Болай түгелдер» дидем.

Егылган туя көрәштән...
Ачудан капчык асам.
Китәм иң тәүге мәйданга,
Аякны киереп басам.

* * *

Ян тәрәздән тургай карады дип,
Бөтерелеп йөри әнкәем:
Төче коймак тугыргамы җәһәт,
Өлгертергәме дип йә чәен.

«Ян тәрәздән тургай бакса әгәр,
Кайтып төшә иде берәрсе...»
Үзе сөйли шул тургайдай очып,
Күмеренең карый терсен.

Көн кичегә, шәфәкъ балкый башлый,
Тере кузлар җайлап сүнәләр.
Әнкәй йөзе сүнә, алар шулай
Көтә-көтә инде күнәләр.
...Тургай кунган саен кайтып булмый.
Белеп булмый кайчан барасын.
Ичмасам, шул безнең сагыш булып,
Ян тәрәздән тургай карасын...

## Көйгән каен

Ничәмә ел, кара көйгән каен,
Сүнгән кисәү кебек торасың.
Нидер көтәсең син соңгы көндә?
Кем соң сиңа килеп урасын?

Табигатьнең күпме гарасаты
Башка агачларны тындырмый,
Сине инде хәзер урап үтә:
Яшен атмый, давыл сындырмый.

Сине кисеп-егып китәргә дә
Кешеләрнең кулы бармыйдыр.
Син беркемнән шәфкать сорамыйсың —
Чулак кулдай нигә тырпайдың?

Сиңа нинди ярдәм күрсәтергә,
Яшел җирнең кара каены?
Үткәннәрне уйлап, мин алдыңда
Ыгы-зыгылардан айныдым.

Кара көеп эчтән күпме яндым,
Чыгармадым тышка кайгымны.
Сабырлыгын күреп таңга алдым
Аягөсте көйгән каенның.

*** * ***

*Равил Бикбаевка*

Беләм хәзер, җаның сызланганда,
Барганыңны төбәп кайларга:
Юлың үтә карт имәннәр буйлап,
Эзең китә олпат тауларга.

Сиздем, дустым, тамакларың кибеп,
Сусаганда кая барганың:
Җәен үләннәрдән чыклар сөзеп,
Кыш бәкегә карлар ярганың.

Сиздем инде ничек итеп яраң —
Басуларың каны акканын:
Ак каенга табиб итеп килеп,
Юл яфрагы йолкып япканың.

Сиздем бугай кайчан калганлыгын
Керфегеңдә дымнар сакланып.
Берәү күрмәгәндә, белмәгәндә
Елаганың җиргә капланып.

Белдем инде ярсу бәхәсләрдә
Карлыкканда синең тамагың,
Тавыш сорап асыл кошка түгел,
Күкрәүләргә, дустым, багасың.

Тоям, тоям, кайчак миең чатнап,
Кысылганда кайчак алкымың*,
Идел ташларына башың салып,
Көткәнеңне көннәр балкуын.

Баш очыңда ал шәм — кояш чыга,
Ә түшәмең — күкнең гөмбәзе.
Алларыңда Урал — эш өстәлең...
Балкыт безгә моңсу көннәрне.

* * *

Гөлдән яфрак очып төште
Мин язган кәгазьләргә.
Яфрак очты. Кем сәбәпче
Гөл яшен агызганга?

Селкенде гөл. Тамды тамчы —
Гөлнең ул күз яшедер.
Җаныңнан җан өзелгәндә
Күз яшен кем яшерер?

Моңсу уйлар килде кинәт
(Билгеле тумыштан да):
Килер вакыт, без китәрбез
Өзелеп тормыштан да.

Тик кәгазем яфрак хәлен
Хәтерләтмәсен иртә.
Ниятләремне сизгәндәй,
Ал нурлар тәрәз чиртә.

Нәфселәрем чама белән,
Өметем түгел зурдан.
Мәхрүм булмасын күңелем
Дуслардан төшкән нурдан.

* * *

Күпме яшәлде вакытлыча диеп:
Үтәр әле диеп, үтә дип.
Көткән шул үткәннәр бүген менә
Үзәгемне минем өтә бик.

Кызык диеп кылмас эшләр кылып,
Тик соңыннан күрми кызыгын,
Тәүбә итеп тәртәләргә кердем,
Үткән чакта чама сызыгын.

Бөтенесе язык булмагандыр,
Кайберәүгә азык булгандыр.
Уйнаганда язмыш минем белән,
Кемнәргәдер кызык булгандыр.

Яшьлек беркатлыгым күпме еллар
Йөрәгемне әзме ышкыды.
Вакытлы дип вакытымны алган
Вакытның мин кырам юшкынын.

* * *

Язгы сулар, сер бүлешеп,
Минем телдә аккан сыман.

Искән җилләр тәрәзәләрне
Минем телдә каккан сыман.

Бөтен кошлар киткән чакта,
Саубуллашып очкан сыман.
Күк болытлар газиз җирне
Минем аша кочкан сыман.
Алар бары өйрәнгәндәй
Минем телне отар өчен —
Һәрчак аны тыңлагандай
Һәрбер өнен йотар өчен.

Кош тавышын тыеп калам,
Аңлап торам искән җилне.
Бар табигать, хәтта кошлар
Аңлый икән минем телне.

## Гомер яфраклары

Елның кәүсәсеннән берәм-берәм
Яфрак сыман оча көннәр, төннәр.
Ел агачы шәрәләнгән саен,
Шаулагандай колагымда өннәр:

«Өлгерденме күзең ачып-йомып,
Уйладыңмы көнең үтәр тәмам.
Шул көннәрдә яфраклары оча
Синең дә бит гомереңнең һаман...»

Гомеремнең яфраклары кими
Очкан көннәр, үткән төннәр белән.
Көнне төндә тотам очырмыйча,
Керфек какмый идек мендәр белән.

Күңелемдә төнен яралса җыр,
Көндез оча канатлары җитеп.
Очырамын һәрчак өмет белән
Гомеремнең яфраклары итеп.

## Ут алырга кайтам

«Китәсең дәмени, — диде әни, —
Күргәндәй дә әле булмадым:
Ут алырга гына кайткан кебек,
Кайтасың бит гелән, оланым...»

Ут алырга, әйе, ут алырга,
Ут алырга кайтам мин гелән.
Әни, син дә аны белдеңмени, —
Беләм икән дисәм мин генә.

Йөрәгемдә утлар кимегәндә,
Эшләремнән күңел сүрелсә,
Һавадагы торналарны карап
Күңел белән начар күрелсә,

Әни, сиңа — туган җиргә кайтам,
Кайтам күзләремне ачарга,
Олы юлга чыгар сукмак эзләп,
Булган ваклыклардан качарга.

Йөрәгемнең утын дөрләтергә,
Ялкын өстәр өчен каныма,
Ут алырга, бары ут алырга
Кайтам, әни, синең яныңа!

## Җәй уртасы

Бер мизгел дә миңа чит-ят түгел,
Әмма бар шул үтә якыны;
Кояш кайнарлыгы гына микән
Җәйнең күңелдәге ялкыны.

Бөтен юмартлыгы ачылган чак,
Түлле чагы хозур җиремнең.
Көннән муллык агып торыр вакыт,
Җәлләмәсәң хәләл тиреңне.

Куәтләргә яңа куәт өстәр
Күкне терәп торган башаклар.
Аңа атап күпме җыр тумасын,
Алар яңаларын башлата.

Юкәләрдән баллар тама гүя,
Җир сыгыла сыман барлыктан.
Кошлар сайрап туймый. Әллә алар
Мәңге бетмәс моңга тарыккан?

Канатланган чагы хыялларның,
Кайнар көндәй туган тойгылар.
Тик тойгылар көндәй үзгәрмәсен —
Көннәр сүрелеп тә куйгалар.

Менә шунда асыл көннәреңнең
Әрәм үтүеннән куркасың.
Һәр минуты алтын бөртегедәй,
Җәй уртасы — эшнең уртасы.

## Кайтты батыр туган җиренә

*Салават Юлаев һәйкәле ачылуга*

Ике гасыр җирем түр сайлады,
Ике гасыр мәрмәр сайлады.
Көтеп-көтеп сине талды күзләр,
Кар яудымы? Атың җайлады?

Урау-урау юллар аша икән
Кайтмас җиркәйләрдән кайтуы.
Ике йөз ел көтеп чыкты кояш,
Ике йөз ел калыкты ай тулып.

Ярсып арыдымы әллә атың,
Атладыңмы җәяү төшеп тә?

Сагынган ай хәзер синең учта,
Кояш тора анда төшлектә!

Дәвер аша күзен текәп көткән!
Туганнарың тыныч-иминнәр.
Аргамагың җирне тотып торса,
Күк гөмбәзе ятар иңеңдә.

Бөтенесен урынына куя,
Рәхмәт инде бөек гасырым.
Заманымның иң алдына чыктың,
Тулпарыңны үрә бастырдың!

*** * ***

Ашыкмагыз сукранырга,
Юлдан чыкса колын-сабый.
Вакыт җиткәч — табар юлны,
Көтегезче, булып сабыр.

Көтмәгез тик алашаның
Юл бозарын озын юлда.
Бозса, тик ул җаваплымы? —
Тезгене бит сезнең кулда...

## Дустыма кырык тулганда

Кырык эшем ятсын кырылып,
Килдем һәммәсеннән арынып.

Кырыгыбыз шулай кырык яктан,
Сиңа бүген төгәл кырык чакта,

Килеп төштек синең табынга,
Бар утларың дөрләп кабынган.

Күчтәнәч юк затлы-кыйбатлы,
Күчтәнәчме, дуслык кыйммәтме?

Куанабыз җилле итте дип,
Егет чагы җилле үтте дип.

Без әйтербез, җилле иттең дип,
Котлаганда, иллең җитте дип.

Туган көннәреңә җилеп җит,
Эзләреңдә калсын егетлек.

## Гомер үтә, дибез

Гомер үтә, үтә, үтә, дибез,
Буламы соң тотып, нукталап.
Гаҗәпләнәм тагын: үтмәсә бит,
Үтмәсә бит гомер туктала.

Берни уйламыйдыр тукталырга,
Җил исмәскә, сулар акмаска;
Кар яумаска, бөре тулышмаска,
Чәчкә уйламыйдыр атмаска.

Барсын гомер,
берни тукталмасын —
Һәммәсеннән шуны үтенәм.
Гомер үткәненә үкенмимен,
Бушка үтсә генә үкенәм.

## Тагын теләп

Тагын теләп юлга чыгам,
Күзем терәп офыккача.
Мин канатлы — юлым чиксез,
Офыклардан офыккача.

Һаман шулай чәчи-чәчи,
Тузан йотып алга узсам,
Үпкә тотмам бу дөньяга,
Ятып түгел, юлда тузсам.

Туздыра юллар ирләрне,
Тудыра юллар ирләрне...

## Юл яфрагы

Юл буенда үләннәрне
Җилләр белеп чәчкән.
Кирәк мәлдә — юл яфрагы,
Ерак торсын чәчкәң.

Үлән булсам, үсәр идем
Бөтен юллар тулып,
Янган яраларга ябар
Юл яфрагы булып.

## Яшен кайтаргыч

Аның башы югарыда,
Тамырлары киткән тирән.
Яшеннәрне тоту өчен,
Йоту өчен шулай кирәк.

Кайтармый ул яшен утын,
Ә үзенә тора тартып.
Анда-монда күк күкрәсә,
Пошынмыйбыз шуңа артык.

Басып һәрчак аягүрә,
Саклый тоташ җирем котын,
Алсыз-ялсыз постта торып,
Гомеренә яшен йотып.

Мәңге шулай түзсен инде,
Торсын инде терәү белми.
Рәхәтмедер, кыенмыдыр,
Тик анысын берәү белми.

## Әти җыры

Бара торгач бер утырам
Агач салкыннарына.
Агач булсам, янар идем
Эчем ялкыннарына.

Әтиемнең иң яраткан җыры
Шул иде, дип сөйли әнием...
Үземә күрә мин дә җырлыймын бит
Һәм үземчә янып яшимен.

Җырларыңны кабатлыймын, әти,
Җырың, утың тоташ күчкәнме?
Чыккан җырым җылынырлык микән,
Әллә янам көчкә-көчкәме?

Дөрләмәсәм тормыш утларында,
Төтенендә генә чәчәсәм,
Җирдә йөрүемә көч килер ул,
Янар-янмый пыскып яшәсәм.

Янам, әти, күкрәгемдә утың
Тора кебек бүген талпынып.
Әнә агачның да, агачның да
Янса гына чыга ялкыны.

## Үскән саен

Үскән саен дөнья серен ачты,
Чиртә килде бөтен кылларны.
Шуңа тиз-тиз зураясы килде,
Тизләтәсе килде елларны.

Кабаландык, үтә кабаландык
Колачларны иртә киерергә;
Кызлар белән иртә танышырга,
Яшь җитмәстән эшкә керергә.

Кайда гына барма, кемне күрмә,
Гел арттырып әйттек яшьләрне.
Бер тын белән йөгерәсе килде,
Бер тын белән дөнья яшәрде.

Һаман шулай җилдергәндә, бермәл
Җиңнән тартып намус туктатты.
Мин үземне-үзем, аркам куеп,
Камчысыннан аның тукматтым.

Өлгермисең әле эш кылырга,
Йөгереп түгел, атлап barганда.
Җиңел-җилпе үтеп булмый икән
Син үзеңә юллар ярганда.

Йөгергәнмен уйлар уйлар чакта,
Гомер үтеп барган, нишләргә?
Яшьләремне яшәртергә кирәк,
Эшләрем күп шундый эшләргә.

Малай чакның исәр истәлеге —
Ул елларым калды, яшрендә.
Гомер юлын хәзер атлап үтәм,
Яшерәмен хәзер яшемне.

* * *

Тагын ялгыз ятам. Баш очында
Эленеп тора Урал картасы.
Сине Урал аша шул картадан
Тыным белән микән тартасы.

Мин ялгыз да, мин бергә дә түгел,
Башларыма мең уй уралган.
Уйларымны җиңеләйтү өчен
Башым терәп ятам Уралга.

## Туган төяк

Суың татын, һаваларың затын
Әллә соңлабрак аңлавым;
Бу сүзләрем йөрәгемнән чыга,
Түгел ярамсакның данлавы.
Җырларыма кайчак тының җитми,
Бөреләргә кирәк сут сыман.
Җаннарыма, була, җылы җитми,
Адашканга кирәк ут сыман.
Туган төяк, синнән күпне алам,
Һәм түләргә алам алгач та,
Бөтен яшәү тамырларым синдә,
Тамырыңда үсә агач та.

## Йолдыз җитми кебек

*Каләмдәшем*
*Гали Ильясовны хәтерләп*

Син хәбәрсез, чакырмыйча килдең,
Бәйрәм иттең гади бер кичне.
Хәзер менә хәтерләргә генә
Шунда туып калган бер хисне.

Ул кышкы кич шундый аяз иде,
Эре, якты иде йолдызлар.
Күктә, дидең, нинди могҗиза бит,
Һәр дуска да тиңдәш йолдыз бар.

Якыннарның исемнәрен әйттең,
Йолдызларга тиңләп күрсәтеп.
Кем уйлаган мәңге җуелмас дип
Күз алдында шул кич сурәте.

Күп йөрдек без озын төн буена,
Сибай күге белән сокланып.
Җырларыңны, кураеңны тыңлап,
Таң алдында гына йокладык.

Төрле чакларында күңелемнең
Җиргә, күккә багам бүген дә,
Күк яктырып тора, ә шулай да
Йолдыз җитми кебек күгемдә.

* * *

Учлап-учлап кулга туфрак алам,
Тукталганда җилгән машина.
Ул туфракта — мәңгелекнең сере,
Мең-мең сорау минем башыма.

Янымдагы япь-яшь шофер егет
Уйлыйдыр да эчтән сантый дип,
Болай да бит һава — туфрак исе,
Бөтен җирдә тузан аңкый дип.

Минем уйлар башка, баштан ашкан
Кемнең язмышлары учымда?
Шул туфракны тапап, таплап-аклап
Азмы узган ялган, чыны да.

Учларымда — еллар елъязмасы,
Мөмкин түгел аны ябарга.
Мәңгелекне укый ала торган
Әлифбаны каян табарга?

* * *

Их, яшьлекнең яшел чагы,
Өздек шул сиреньнәрне,
Чәчкәләргә исердек без,
Онытып иреннәрне.

Әнә тагын яшь-җилкенчәк
Өзә бит сиреньнәрне.
Китә алар минем генә
Тешләтеп иреннәрне.

## Хак

— Гомереңнең хакы күпме?
— Мәхәббәтем хакы!
— Мәхәббәтең хакы күпме?
— Гомеремнең хакы!

## Өлгермәдек рәхмәт әйтергә

*Фәрит Исәнголов истәлегенә*

Барчабызга җылы өләшергә
Ашыктың син, төшеп җан тиргә,
Изгелегең тиде һәммәбезгә —
Өлгермәдек рәхмәт әйтергә.

Син өлгердең җирдә барысына,
Барысына алдан өлгердең.
Шатлыкларың ихлас бүлештең син,
Кайгылыга башлап йөгердең.

Терәксезгә терәк булып тордың,
Ярып әйттең гадел сүзеңне,
Заманыңның ыжгыр җилләреннән
Йөрмәдең син борып йөзеңне.

Бар суларын үтеп бу тормышның,

Үтеп анның бөтен утларын,
Ничек кулы барып, әҗәл сине
Ничек йолкып алды куптарып?

Азаккача янып яшәдең син,
Бер яугире булып бу җирнең.
Сиңа күпме рәхмәт әйтәсе бар, —
Ә син көтми китеп өлгердең.

## Учак

Кар өстендә дөрләп ут янса,
Дертләп китәр түң көрт йокласа.

Карда учак ягу мактала,
Бары сүнгәч кара тап кала.

Ут астында нидер чыжлавы —
Карның тәне пешеп елавы.

## Өлге

Трамвайлар шыгыр-шыгыр бара,
Чыгып бара кеше тыннары,
Берәү өреп өлге эшләмәкче,
Берәүләре мактый туннарын.

Туңган трамвай килә җай гына,
Тукталышка җитсә ярый да.
Кайберәүләр кеше язмышына
Туң өлгеләр аша карыйлар.

Шул күңелне ничек эретергә,
Шул өлгене ничек юк итәргә?

## Тоз сибәләр

Тайгак юлга бүген тоз сибәләр,
Тоз сипсәләр, таймый бозлавык,
Беләм, яраларга тоз сибәләр;
Берәү аны тиз уңалтыр өчен,
Берәү арттырырга сызлавын.

Әй, тоз, синең күпме сыйфатың бар,
Син бит һәр кешенең ашында.
Ак ашъяулык өсләрендә әле,
Берчә аяк асларында ята,
Боз капланган урам ташында.

Кайберәүгә кайчак «тозсыз» дип тә
Әйтәбез бит чара калмаса;
Ашаганда азык булырын да,
Тапаганда язык булырын да
Искә алмыйбыз шул алмасак.

Тайгакта да беркем курыкмасын дип,
Урамда дип тормыш кайнасын,
Тозның тозын хәтта җәлләмибез,
Бозның бозын тозлап хәйләлибез,

Кеше генә, кеше таймасын.

## Кош юлы

Ак дөнья алдында бик каушап,
Калтырап киттеме кыш кулы,
Гөлт итеп ут алды урамнар —
Җиремдә кабынды кош юлы.

Шуалар фаралар җемелдәп,
Әйтерсең йолдызлар атыла.
Анда да, монда да кош юлы,
Берсеннән-берәүсе артылган.

Бер — күккә, бер җиргә карыймын,
Кош юлы кайда дип яктырак.
Биектә таныш юл бик тонык,
Ул үзе калгандай аптырап.

Офыкка тоташып торалар,
Белмичә кайларга туктарын,
Уфамның җиремдә балкыган
Кош юлы көнләшер утлары.

Әй, моңсу җансыз күк — тын бушлык,
Кош юлы биектә, бик ерак.
Җиремдә кабынган йолдызлар
Күңелдә җылырак, нурлырак.

## Баймак ягы

Һәрвакытта килеп булмый
Ничек кенә, ничек сагын.
Кәеф нинди булганда да
Тартып тора Баймак ягы.

Көтә-көтә киләм монда,
Канатланып менә тагын.
Озаграк юл төшмәсә,
Сагындыра Баймак ягы.

Һәр мизгелең күз алдымда,
Тарта мине бөтен чагың.
Йөрәгемә ялкын биргән —
Якын миңа Баймак ягы.

Оча-атлап киләм һәрчак,
Күңел кошым, канат кагып.
Тансыгымны кандырырга,
Табынырга киләм тагын.

## Авылымның олы юлы

Авылымның олы юлы
Күз алдымда мәңге торыр,
Юл төшмәгән вакытларда
Уйларымны юлга борыр.

Юллар чаңы, юллар таңы
Сабый чактан тартты инде,
Олы юлга омтылуым
Ис кергәннән артты инде.
Уйлый идем юктыр диеп
Аннан олы юл да җирдә.
Шуннан башка һич кызык та
Булмаганмы әллә бер дә.

Бар хәрәкәт юлда икән,
Бакканмындыр шулай кызып.
Экрандагы кино сыман,
Бөтенесе булган кызык.

Шушы юлдан сунарчылар
Аудан кайтты, ауга китте...
Сугыш чыккач, бар авылдан
Узаманнар яуга китте.

Шушы юлдан көтү-көтү
Атлар үтте, тайлар үтте.
Олы юлдан күзне алмый,
Көн артыннан айлар үтте.

Дүрт аяклап чыгып, шунда —
Олы юлда уйнадым мин.
Юлда тузан уйнаганда,
Ул чак нәрсә уйладым мин?

Бермәл шулай олы юлдан
Ат көтүе үткән чакта,
Үрле-кырлы шашып бер тай
Чабып килә минем якка.

Чабып килә миңа табан,
Мине тапап сытаргамы?
Шушы тайдан куркып микән
Кинәт торып сыпырганмын.
Тайдан өркеп, менә шулай
Олы юлда аяк бастым.
Өскә менеп килгән тайдан
Әллә җанны аяп бастым.

Мин сикереп торып баскач,
Тай үзе дә миннән өреккән.
Җилеп барган тайның җиле
Миңа да тузан бөреккән.

Килеп кергәч үзем атлап,
Аптыраган өйдәгеләр.
Хәбәр итеп шушы хәлне
Озак-озак сөйләделәр.

Күңелемә күчкән микән
Чабып барган тайның чәме.
Тузанымы йогып калган —
Телләремдә туфрак тәме.

Ятты тузан. Малай булдым.
Каршысына искән җилнең.
Тузан кубарып, чиратлап,
Шул тайларны менеп җилдем.

Үтте вакыт, очып үтте,
Күтәрелде тузан хәзер.
Тайдан күчкән шул дәрт белән
Күп юлларны узам хәзер.

Әзер юлдан юлга чыккач,
Үзем дә юл салсам иде.
Соңгы адымны басканчы
Олы юлда калсам иде.
*** * ***

Иртүк түгеп яңгыр коя,
Үзе көлеп кояш калыккан.
Юындырган сабый сыман,
Җирем көнгә ята чалкан.

Кайгысымы, шатлыгымы —
Җиргә нәрсә килә икән?
Бу дөнья да хәтта үзе
Яшь аралаш көлә икән.

*** * ***

Барчасын да әйтеп бетмимендер,
Сөйләп бетмимендер һәммәсен.
Минем тоташ ачылганымны да
Көтмисеңме, әллә көтәсең?

Әле алда аңлашырбыз димен,
Җитәр серем бөтен гомергә.
Өстәп торыр утын калмаганда,
Мөмкин хәтта учак сүнәргә.

## Уем да юк

Яшьлекне төзәтеп,
Язмышны үзгәртеп...

*Җырдан*

Бүгенге уй, акыл белән
Яшьлегемне төзәткәндә,
Ялгышларын ямаштырып,
Язмышымны үзгәрткәндә...

Нәрсә калыр яшьлегемнән,
Хәтерләргә нәрсә калыр.
Яшьлек инде төзәтелгәч,
Яшьлек мәлен картлык алыр...

Бөтенесе калсын шулай,

Калсын яшьлек булган көе.
Үткән инде кире кайтмас,
Нинди файда аңа көеп?

Киләчәкне — мөмкин әле,
Юк төзәтү үткәннәргә.
Үкенечне ясамаска
Киләчәк бар көткәннәргә.

Кабатланмас яшьлегемдә
Һәр борылма хәзер — сабак.
Үзгәртергә уем да юк,
Бүген тагын килсә кабат.

## Тик көтәм

Күпме еллар үтте,
Күпме юллар үттем —
Синнән башка җирдә юк бүтән.
Өмет янып сүнә,
Күңел шуңа күнә,
Килмәсеңне беләм — тик көтәм.

Сызлый минем йөрәк,
Күпме түзем кирәк,
Басылырдан инде ул үткән.
Еллар һаман җилсен,
Соңгы көнем килсен,
Килмәсеңне беләм — тик көтәм.

*** * ***

Син бит бәләкәчсең, дисең миңа,
Олы уйлар белән саташма.
Ул бәләкәй генә башың белән
Олы дөнья белән маташма.

Беләсеңме, олы бу дөньяда
Мин зур түгел, үзем оялам.
Тик бәләкәй уйлар белән яшәп,
Зураеп та булмый дөньяда.

## Язмыш

Язмыш дисәм, ялгышылып тора,
Бер калкынып чыгам, бер төшәм.
Ләкин әле җирдә басып торам,
Баш очымда күгем — бер төшәм.

Язмыш диеп баш ияргә түгел,
Һәм йөрергә түгел масаеп;
Язмышыма һичбер үкенмимен,
Язмышымны үзем ясыймын.

## Антлар аша

Вакланмадык түгел. Булды.

Хәзер инде акланмыймын.
Үткәнемнең алдында да
Акланып һич вакланмыймын.

Һәммәсенең бетмешенә
Нигә кирәк төшенергә?
Таңнан юкка ашыкканчы,
Мөмкин аңа төш керергә.

Тыпырчынмый торып була,
Табаннарың өйкәлмәскә*.
Авыз пешкәч, инде беләм:
Сөймәгәнгә сөйкәлмәскә.

Күңелләрем язгы судай,
Ташмый сыман ярларыннан.
Хәзер ярлар үзгәрмәс, дим,
Язгы сулар ярдәменнән.
Әйләнә җир күчәрендә,
Бара дөнья үз җаена.
Шаулама, су, ярсыма, яр,
Еллар көткәч, түз аена.

Син уемнан чыккан чакта,
Дөнья белән китек арам.
Үзем тагын сиңа табан
Антлар аша китеп барам.

## Зарланма!

Тормышны кормыш дип
Зарланма син бушка.
Туктаусыз сорарга
Сиңа соң кем кушкан?

Ябылмас авызлы
Тик карга баласы.
Син дә бит нәкъ шулай:
Аласың, аласың.

Тормыштан күп алдык
Бурычка болай да.
Үткән ай калганны
Түлик без бу айда.

Алырга барысын
Сиңа ни, кем кушкан?
Тормышны кормыш дип
Зарланма син бушка!

## Җәяүле буран

Әллә җирдән кача, әллә каян
Көтү-көтү булып бу карлар.
Үзләреннән туеп кача дисәң,
Карлар котылырдай җир кайда?

Без чат ябышабыз туган җиргә,

Үз-үзеңнән туйган мәлдә дә.
Нигә карлар җәяү качып бара,
Җилләр юри куган хәлдә дә?

## Ир канаты

Улымның ат күргәне юк,
Менә «ат» дип чыкты теле.
Ансат булганга әйтәме —
Сөйли икән каян белеп?

Ир канаты ат икәне
Сеңешкәнме шулай канга.
Теле чыккан сабый да бит
Суга икән аны санга.

Нинди ат, дип эндәшәмен
Сорау белән алмашыма,
Чөнки хәзер ир канаты
Атлар да бит алмашына.

Йөрәгеңдә антың булса,
Илнең сиңа аты булыр.
Атның да дим уйламаган,
Без күрмәгән заты булыр.

## Бүген тагын

Бүген тагын туар көн тыныннан,
Төшкән таң нурыннан уяндым.
Тәрәзәләрнең корганнарын тартып,
Мин дөньяга ачтым дөньямны.

Күңелемне һәрчак әйдәп торган
Дөньяның шул серле сараен
Мин бит көн дә меңьяшәр карт күзе,
Сабый күзе белән карыймын.

Һәр туар көн мине үзе уята,
Шатлыгымны әйтер сүз җитми.
Яман күзләр иртә ачылмасын,
Дөнья калсын мәңге күз тими.

*** * ***

Кичтән генә әле көзге бакча
Шаян җилләр белән шаярды.
Уртак тел табыпмы җилләр тынды,
Ә таң белән тәүге кар яуды.

Кияү егет сыман җил басылган,
Баганалар карап шаккаткан.
Әйтерсең лә туйга әзерләнеп,
Бакча күлмәк кигән ап-актан.

*** * ***

Дөнья, синнән күпне сорамыймын —

Бөтенесе җиңел табарлык:
Давылларың бары дәрман бирсә,
Ә тауларың синең — сабырлык;

Утларыңнан миңа ялкын йокса,
Кеше өшегәндә янарлык;
Дуслар сусаганда, суың булса,
Сусыннары гына канырлык;

Юлларыма кайчак кыя авып,
Каушап калыр җирдә дәрт бирсәң;
Урынсызга чыгырымнан чыккач,
Үз-үземне тотар көч бирсәң;

Тиң-тошыма шатлык эзләр идем,
Түбәләрен күккә тигезеп.
Артык бәхет миңа кирәкми дә,
Шулар белән бирсәң тигезен.

Шуңа риза. Алар хәзер кирәк,
Нигә кирәк өскә кар яугач...
Биргәнеңә бер дә үкенмәссең,
Китәрмен тик аны кайтаргач.

## Төшсен кояш күзләремә

Кара күзлек кигән берәү,
Бөтен нәрсә аңа кара.
Менә дигән ак дөньяны
Кара итеп карап бара.

Ә кояштан курка микән,
Янәсе, ул күзен саклый.
Әллә кеше күзләреннән,
Күзен каплап, үзен саклый.

Бер уйласаң, монда бер дә
Юктыр сыман гаҗәбе дә.
Аның ничек баруының
Шул тиклемдер хаҗәте дә.

Аны мин дә язмас идем,
Язганда да кем соң укыр?
Көтмәгәндә шунда каршы
Очрамаса бер дөм сукыр.

Ул кимәгән кара күзлек,
Тик оныгы килә тотып,
Баш күтәреп, үргә карап,
Һәрбер нурны килә йотып.

Аны беләм. Сугыштан ул
Шулай кайткан дөнья буйлап.
Үзе өчен сүнгән кояш,
Башкаларга кояш уйлап.

Тоядыр ул чама белән
Кояшның да үткен нурын...
Шул кояштан, шул нурлардан
Сакланырга бармы урын?

## Бары бер сабак

Син бит миңа сүнгән йолдыз ише,
Нурың да юк, юк бит салкының.
Янганда да, беләм, миңа түгел,
Бик еракта яндың, балкыдың.

Онытыла, бары артта кала,
Мин икенче хәзер, мин башка.
Башларымда күптән башка хыял,
Башка йөкләр ята иңбашка.

Әллә нигә хәтта ят тоела
Ярсуымның ярдан ашканы.
Менгән атым бара үз юлыннан,
Артык үтеп бармый башканы.

Ачыламы тормыш асылы да,
Күз алдыннан күчә томаны.
Ул томаннар инде миннән күчеп,
Башкаларга барып кунамы?

Булган тойгым кабат тоелмас та,
Чыккан кояш байый бер кабат.
Рәхмәт инде сиңа, сине белү
Булды сыман бары бер сабак.

## Учак янындагы уй

Учак ягып, утка багып,
Күзем салам ераkларга.
Карап караш җитмәс җирдә,
Әй, аралар ерак калган.

Басылганмы эсселәре
Элек яккан учакларның?
Үтте шаулап колагымнан
Җыры шаһит учакларның.

Кызыл ялкын булып очкан
Ел да усак яфраклары.
Оча-яна үткән гомер
Әллә очкан яфрак бары.

Ә нигә җилләр очырмый
Йөрәктәге ялкынымны?
Нигә оныттырмый икән
Ялкын ялмар якынымны?

Сүнми ялкын, үзе салкын,
Нигә, нигә учак ягам.
Ялкын аша, еллар аша
Сүнгән учакларга багам.

Еллар аша яна-сүнә,
Учакларда күмер яна.
Әллә вакыт учагында
Сине сөйгән гомер яна.

## Еллар безгә баккан

Планетада җылы илләр исә,
Вәгъдәләп чуак көннәр.
Шомны куып, бикле чикләр аша
Йөри иң өметле өннәр.

Дөнья буйлап искән җылы җилләр —
Тыныч тыны тынычлыкның.
Яшәү сулышыдай нуры төшә
Илем салган тырышлыкның.

Ялкын сүнә кыйтга күлмәгендә,
Көл күтәреп үлән шыта.
Ә бит кемнәрнеңдер йөзен сытып,
Төрле томаннарны ерта.

Уңай җилләрмени инде еллар —
Алга җилә безнең җилкән.
Җиңеләйтә алар яшәүләрне,
Күтәргәндә аны җилкәң.

Без күтәрдек, күтәрәбез һаман
Җирнең иң җаваплы йөген.
Өметләнеп дөнья безгә карый,
Еллар безгә баккан бүген.

## Синең елмаю

*Рәис Низамов истәлегенә*

Кояш һаман әүвәлгечә чыга,
Әүвәлгечә төшә эңгер дә.
Тагын кояш безне ташлап китәр,
Офыкларга барып сеңәр дә.

Моңсу кошлар әллә кая оча,
Юлларында болыт оеган.
Кош юлының шәмдәлләре тонык,
Күк астында җирем боега.

Күңелемә соры болыт кунды,
Күчмәс сыман җилләр иссә дә.
Аны таратырга әмәлем юк,
Бәгыремне өзсә-киссә дә.

Әллә нигә килер көннәрнең дә
Шулай үтәр сыман ел-ае.
Минем күңел, минем дөнья китек —
Җитми бүген синең елмаю.

*** * ***

Күз алдында ятып айгыр үлде,
Үлде, диләр, бер корт чакканга.
Әле генә без соклана идек
Шушы айгыр ничек чапканга.

Чабып килеп, авып туктады ул
Җир селкетеп йөрәк кагудан.
Күз алдында ятып айгыр үлде,

Гарьлегеннән, әллә агудан.

## Май яңгыры

Җирем сызлауларын басаргамы,
Басаргамы бары тузанын
(Иртәгәсен илдә Җиңү көне),
Бүген яңгыр ява таңнан ук.

Ә кешеләр эркелешеп чыга,
Чәчкә белән тулы кочаклы.
Яңгыр коя, үзе кояш балкый —
Кеше күңеленә охшашлы.

Үтәр яңгыр җиргә шифа булып,
Сагыш кына озак тарала.
Яңгыр ага кеше битләреннән
Күз яшьләре белән аралаш.

Яңгырларда, күз яшенә юып,
Һәйкәлләргә чәчкә илтәләр.
Майның яңгырыннан сафлангандай
Килсен иде туар иртәләр.

Янәшәмдә бер ветеран бара,
Ул атлыйдыр җаны сулкылдап.
Аның буш җиңенә исе китеп,
Малай бара минем уң кулда.

Сабый чактан йөрәгенә сеңсен —
Малаема ымлап мин әйтәм:
Батыр итеп табынырга була,
Һәр яралы — үзе бер һәйкәл.

## Җыр яшәсә

Елга җырлап ага, урман шаулый,
Могҗизави өне кошларның.
Киекләрнең без аңламас моңы,
Үз моңы бар җәйнең, кышларның.

Бөтен яшәү серле моңнан тора,
Моңнарның бар хәтта өнсезе.
Җырсызмыни күккә ашкан кыя?
Күк моңлана төнен, көндезен.

Кояш нурын, айның боеклыгын
Аңлатырга нинди сүз белән?
Ә йолдызлар мәңге җиргә карый,
Сагышлардан янган күз белән.

Кешене дим әйтеп торасы юк,
Тормыш җыры аны яшәтә.
Канатсызга очар канат куя,
Йөрәкләрен күпме яшәртә.

Җыр — мәңгелек, җир мәңгелек булса,
Икесе тиң бермә-бер яшәр.
Җирне җыр да тота, җыр коткара,
Җирдә җыр яшәсә,
Җир яшәр!

## Хәйбулла

Өстәл кебек дала өсләрендә
Җәйрәп ята иркен Хәйбулла.
Кышы яхшы, язы-көзе әйбәт,
Юк, шәп чагы аның җәй була.

Гомереңә онытылмас иде,
Йөрсәң әгәр таңгы далада:
Дала көлеп кала җил иссә дә,
Киек казлар каңгылдаса да.

Беләм дисәң әгәр ни икәнен
Җирдә күтәрелгән чирәмнең,
Шушы чирәм белән яшәртелеп,
Җирләр монда ничек бизәнде.

Буран котырганда юлың төшеп,
Эләксәң син акман-токманга,
Аптырарсың кышның камчысына,
Дала җиле каты сукканга.

Көннәр учак кебек кызган чакта,
Авыз итсәң әгәр кымызын,
Күңелеңдә шундый бер моң калыр,
Һәм ул моңны булмас тымызып*.

Монда күңел дала кебек иркен,
Күңел кебек иркен Хәйбулла.
Кышы — яхшы, язы-көзе — матур,
Ә шулай да шәбе җәй була.

## Самолетта

Самолетта аерылдык җирдән,
Күтәрелдек шундый югары.
Һавада да булмый икән җанны
Җирең йөкләреннән тугарып.

Җан борчыган — җирем мәшәкате,
Башымда тик аның хәсрәте.
Җирне һаман әнә яшен ата,
Монда очкыннарын чәчрәтеп.

Чәчем белән җирне себерергә
Әзер чакларым да аз түгел.
Ул тилереп хәстәр көтә һәрчак,
Көткәне һич артык наз түгел.

Канатландым канатсыз да көе,
Кабат җиргә төшеп бастым да.
Бар кешелек учта тотар җирем
Ята һаман аяк астында.

*** * ***

Күрәсем килә һәммәсен,
Кем дөньядан туйган.
Кичерәсем килә барын —
Тормыш ниләр куйган.

Ачсам күзем дөньяга мин —
Сабый кебек кенә.
Ә барласам кичергәннәрне,
Мең яшь кебек миңа.

## Синең белән минем кебек

Үлән шытып баш күтәрә
Синең белән минем кебек.
Кыяклары тартылалар
Синең белән минем кебек.
Әнә кошлар чөкердәшә
Синең белән минем кебек.
Кошчыкларын күзәтәләр
Синең белән минем кебек.
Әй шаулаган була яфрак
Синең белән минем кебек.
Саргаюларын белмиләр
Синең белән минем кебек.
Исә җилләр кабаланып
Синең белән минем кебек.
Кире кайтмасын аңламый
Синең белән минем кебек.
Алар кая ашкыналар
Синең белән минем кебек.
Соңлап аңлар микән алар
Синең белән минем кебек?..

## Төштә

Исемеңне коры талга
яздым.
Күз алдымда талым яфрак
ярды.
Буш курага исемеңне
ырдым.
Көтү маллар белән тулды
ындыр.
Кипкән күл ярына язмак
булдым.
Суга күлем мөлдерәмә
тулды.
Кулымны мин сулган җиргә
суздым.
Көтмәгәндә коеп ләйсән
узды.
Дөм караңгы күккә чөйдем
уйны.
Кинәт анда мең-мең йолдыз
туды.

## Алачагым калсын...

Мин көнчелме икән әллә шулай?
Юмартлардан һәрчак көнләшәм.
Шатлык килсә — дусларыма, җиргә,
Кайгы булса җилгә өләшәм.

Кулымдагын, күңелдәгеn бирәм,
Кабат кайтаруны көтмимен.
Бирәчәкне биреп бетерим дим,
Алачакны алып бетмимен.

Дөнья белән алыш-биреш бара
Яуган яңгыр, яткан карда да,
Җирдән, җилдән алачагым байтак,
Алганы бар ала карга да...

Булганымны һаман өләшермен —
Кемнәр кайчан ничек алмасын.
Алачагым җирдә калса калсын,
Бирәчәгем берүк калмасын.

## Киткәнемдә

Еракларга тагын юлга чыгам,
Сәфәрләрне килми санасым.
Күзләремә нигә моң сарыла,
Нигә кибә әле тамагым?

Омтыламын үзем офыкларга,
Юлларымның юктай тәмамы.
Барыр җирләремә җитмәгәнмен,
Кайтырымны уйлап янамын.

## Икмәк

Авылга мин икмәк алып кайтам,
Күчтәнәчкә — арыш икмәге.
Анда муллык икәнен дә беләм,
Авылдашлар, гаеп итмәгез.

Хәтеремдә, елына бер барып
Калач китергәннәр каладан.
Шул чакларны искә алган саен,
Һаман әле тәмләп яланам.

Авыл хәзер кара икмәк салмый,
Кара икмәк хәзер пешерми.
Нишләп аны оныттыгыз икән,
Бу үпкәмне әйтәм яшерми.

Өстәлләрдә — кардай ак икмәкләр,
Мамык кебек сыгып тотарлык.
Ап-ак бәхет ята икмәк булып,
Татыганда телең йотарлык.

Кайтып киткән чакта бик кадерләп
Ак икмәген алам авылның.
Хәтта икмәксез дә чакларында
Авылым уе һәрчак сау булды.

Икмәктән дә олы күчтәнәч юк,
Аны зурлап шуңа алам да.
Күкрәгенә терәп икмәк телә
Бүген авылым да, калам да.

## Әкиятләр түгел

Картәнием әкият сөйләгәне,
Миңа бишек җыры көйләгәне —
Юк, исемдә түгел.
Туйганчы бер уен уйнаганым,
Бары аны гына уйлаганым —
Юк, исемдә түгел.

Кайда иртә чыккан балтырганнар,
Кай басуда башак калдырганнар —
Хәтеремдә һаман.
Көне-төне хатлар көткәннәре,
Күз яшьләре битне өткәннәре —
Хәтеремдә һаман.

Сабый чактан һушны алганнары,
Хәтеремдә мәңге калганнары —
Әкиятләр түгел.
Бу дөньяга күзне ачканы да,
Хыял булып алга басканы да —
Әкиятләр түгел!

## Йөрәкләрдә калыр сүз

*Таҗик язучысы Аскар Хәкимовка*

Син ерактан якын күреп килдең,
Чал Памирдан кундың Уралга.
Биеклектән биеклеккә аштың,
Бөтен күңелеңне җыр алгач.

Хуҗа атын мактагандай түгел,
Уралыма бактың яратып.
Үзеңне дә яраттыра алдың,
Олы сүзең белән каратып:

— Укытучыларга үпкәм туды,
Үпкәм туды, — дидең, — килгәндә,
Европадан алар Азияне
Урал бүлеп тора, дигәннәр.

Югарыдан күрдем, җирдә тойдым —
Йөрәгемнән әйтәм шуларны:
Урал кыйтгаларны бүлеп түгел,
Тоташтырып тора аларны.

...Зур әйберне читтән күреп була,
Тик биектән була күзәтеп.
Син ерактан килеп якынайдың,
Йөрәкләрдә калыр сүз әйтеп.

## Ир сүзе

Атлавыннан танып була ирне,
Кодрәтлеме, нинди куәтле.
Карашыннан танып була ирне,
Нинди уйлы, нинди ниятле.

Кулларыннан танып була ирне,
Нинди эшләр аннан килгәнен,
Эше белән кеше булганлыгын,
Үз кадерен үзе белгәнен.

Ярасыннан танып була ирне,
Нинди утлар-сулар кичкәнен.
Ак чәченнән белеп була хәтта
Кайгы-хәсрәт күпме төшкәнен.

Ирнең кем икәнен, ни икәнен
Раслый аны хәтта берүзе:
Ирне ир иткән дә, зур иткән дә,
Иң нык танытк ан да ир сүзе.

## Туган җиргә

Бу тормышта яшәвемнең сере,
Бөтен мәгънәсе — ярату.
Мәхәббәтнең барлык кайнарлыгын
Тик-тик туган җиргә тарату.

Илем өчен җанны җәлләмәсен,
Сөйләп торасы юк башкасын;
Аның бөтен сызлаулары миндә,
Даннарының күккә ашканы.

Кешеләрем минем — җанчишмәм сез,
Сездән башка җирдә яшәү юк.
Табындыра, талпындыра җирем,
Мәхәббәтсез җирдә яшьнәү юк.

Мәхәббәтле илем, җирем, кешем,
Гел артканнан-арта котлары.
Бергә-бергә кабындыра алар
Карашымның яңа утларын.

Аның сүнмәс күпме уты булса —
Сезне яратуның ялкыны.
Йөрәгемнән чыккан иң газиз сүз
Очар һәрчак сезгә талпынып.

*** * ***

Бик борыннан, кайбер чакларында,
Дүрт ягым да кыйбла, дигәннәр.
Дүрт кояшлы булды микән алар,
Бер үк кояш чыгып килгәндә.
Дүрт ягым да кыйбла, дигәннәр,
Дүрт ягым да ничек кыйбла булсын,

Бер кыйблада гына кояшым.
Һәр балкышын бер кыйбладан көтәм,
Бар дөньяны нурга буясын.
Бер кыйблада гына кояшым.

## Габдҗәлил

Күңелемне һәрчак ымсындырып,
Әйдәп торган сыман: әйдә кил;
Һич карамый мизгел хәлләренә
Кышын, көзен дә кил, җәй дә кил.

Килгәнем бар иген чәчкән чакта,
Йөргәнем бар кышкы буранда.
Җирдә дәррәү орлык шыткан мәлдә,
Үрчегәндә маллар куранда.

Тагын менә, түбәм күккә тиеп,
Килеп төштем урак беткәндә.
Барын куандырыр сөенечне
Янә бу төяктән көткәндә.

Сезнең уңыш ил шатлыгы булып
Бөтен күңелләргә эркелде.
Бураларга тулган иген булып
Ихлас кояш көлде, җир көлде.

Гел, Габдҗәлил, мин сокланам сиңа,
Биеклек юк буең җитмәслек.
Туфрагыңда синең сут бетмәслек,
Йөзләреңдә кояш китмәслек!

*** * ***

*Рәшит Солтангәрәевкә*

Әле генә гөрләп язлар үтте,
Җәйләр көлде шатлык яшьләрендә.
Нинди салкын җилләр кайсы төндә
Бәс калдырган тузган чәчләреңдә?

Әллә бар мизгелнең утын-суын
Һәрчак йөрәк аша кичергәнгә;
Әллә тормыш үтә якын күреп,
Бөтен шулпаларын эчергәнгә.

Син беләсең җиңел-җилпе хисләр
Ямь өстәми савап бизмәнеңә.
Үкенерлек түгел шырлыкларны
Мең газаплар белән гизгәнеңә.

Кадерләре шунда яшәүләрнең,
Кадерләре шунда арта җирнең. —
Атайсалга* солтан булып түгел,
Олтан булып түксәң кара тирне.

Ачык берни ике килмәгәне,
Аккан сулар кире акмаганы.
Аянычлы — мәхәббәтнең түгел,
Хәтта нәфрәтенең кайтмаганы.

Гомерләрнең шундый агышларын
Туктатырга ничек, Солтангәрәй?
Көн төшлектән үтә, бурыч арта,
Керфек каккан саен ел тәгәри,
Керфек каккан саен ел тәгәри.

*** * ***

*Мияссәр Басыйров истәлегенә*

Февраль, сиңа нәрсә җитми иде,
Соңгы көндә шулай иттең син?
Җирне, күңелләрне туңдырырлык
Яман эз калдырып киттең син.
Ул да синең кебек ярсу иде,
Яздай йомшак иде күңеле.
Март та бүген бездәй аңкы-тиңке,
Ул да елый яшькә күмелеп.
Бар дөньяны җылытырга идең,
Эретергә идең туңнарны,
Эссе көндә өшер чаклар булыр
Туймаганнан синең тыннарны.
Эссене дә, салкынны да сизми,
Әрнеп торды йөрәк көн элек.
Бөтен мизгелләрне бергә бутый
Шагыйрь китү, шагыйрь үлеме.
Һәммәбездә дәртләр уятканда,
Кем уйлаган шундый ир чәчәр,
Ни эшләвең булды, ярсу дустым,
Ни йөрәгең ярды, Мияссәр?

## Күңел талмас Талкаста

Тирә-ягы бер могҗиза,
Җитмәгән җир калмас та.
Аяк-кулың талса талыр,
Күңел талмас Талкаста.

Төпләрендә таш күренә,
Мөмкин түгел алмаска.
Күпме генә карасаң да,
Күзең талмас Талкаста.

Туй күлмәген бер кияләр,
Күл кигәндер салмаска.
Туйда булгандай тоярсың,
Килеп китсәң Талкаска.

## Кич көймәдә

Су астында ташлар белән
Йолдызлармы буталган?
Әллә эңгер төшү белән
Барча халык ут алган...

Кая баксаң, шунда йолдыз,
Йөзгәндә кич көймәдә.
Йолдызлар эчендә калгач,
Уең синең нәрсәдә?

Бер карасаң кичке күккә,
Бер түбәнгә багасың.
Карачы әле шәүләңә —
Йолдызларда агасың.

Йөзик әле таңга кадәр
Күкнең көзге күгендә.
Йолдыз сүнсә су төбендә,
Нуры калыр күңелдә.

*** * ***

Тәүге сөю онытылмый, диләр,
Онытыла микән «калганы»?
Әллә сөю тәүдә генә булып,
Азак китә микән ялганы?

Онытмаслык сөюеңнән язгач,
Ничек соң ул кабат ярала?
Нинди сөю тагын була икән
Тәүге сөю белән арада.

Бәхетлеме, бәхетсезме икән
Әллә ничә сөю кичергән?
Сөюем бер, шуның исеменә
Әзермен мин дәрья кичәргә.

Хыялыймын тәүге сөюемнән,
Сизелми дә гомер үткәне.
Ике гомер яшәсәм дә хәтта,
Төшемә дә кермәс бүтәне.

## Сүз

Үлән кибә, елга корый,
Җил-давылдан тузан кала.
Тик сүз генә батмый, янмый,
Уттан кала, судан кала.

Тик халыкның йөрәгеннән
Атылган ук кебек сүзләр
Вакыт дәрьяларын гизә,
Бөтен гарасатка түзә.

## Кылганнар

Тау башында яшь-яшь кылганнар,
Алар белән ниләр кылганнар.
Туар-тумас чәче агарган,
Чырайлары китеп кабарган.

Күренүе әллә карт булып,

Яшәвенә тора шарт булып.
Тауда икән тәртип катырак,
Озаграк яши картырак.

## Янгантауда

Таулар текә,
Һәрбер алым саен
Аякларым куя тайпылып.
Шулчак чыклар булып каеннарның
Күз яшьләре китә чайпылып.
Күпме йөресәң дә бу тауларда,
Мөмкин түгел тансык кануы.
Нинди могҗизалар, нинди серләр,
Шифа биреп шулай януың.
Күптән уйлап аны баш ваталар:
Берәр хикмәт монда юк микән?!
Мин уйлыймын: батыр йөрәгеннән,
Салаваттан калган ут микән?
Бер кабынгач, кабат сүнми хәтта
Таулар яна икән ташкача.
Мәңге тынмас батыр сулышыдыр,
Туктар иде, димен, башкача.
Басылырмы миндә янган утлар
Синең тауларыңда йөрүдән?
Йөрәк ярып туган сагыш сыман,
Таулар ярып ага Йөрүзән.

*** * ***

Кеше туа бер-берәсе өчен,
Шуңа аның җиргә тумышы.
Башлап тәүге адым атлавыннан,
Шуннан бөтен дөнья кумышы.
Бөтенесе бер-берәсе өчен:
Җирдән бетмәс гайрәт алу да.
Матурлыкны күреп соклану да,
Бер караштан каушап калу да.
Бер-берәсе өчен бөтенесе:
Тәүге сөю, тәүге нәфрәт тә,
Төймә кебек кенә сөенеч тә,
Гүя дөя кебек хәсрәт тә.
Туганнар тик бер-берәсе өчен
Адашканнар төрле тарафта.
Юллар бергә туры килгәндә дә,
Туры килми кала карашлар.
Шулай бер-береңә ярты гомер,
Ярты дөнья урап киләсең.
Инде үткәннең үтеп киткәнен дә,
Кабат килмәвен дә беләсең.

## Мирас

Аталардан калган, ай, ир бала
Күкрәк көче белән мал таба.

*Халык җыры*

Юлы, эше калды этиләрнең,
Җитмәсә дә ул чак көчебез!
Ләкин безнең буын бик тиз катты,
Безгә көч өстәде үчебез.

Бетмәс эшләр иде безгә калган,

Иң хак юллар — дәвам итәргә.
Һәм без юлга чыктык алар тоткан
Хыялларга барып җитәргә.

Үзләре дә эти булып бетте
Аталардан калган балалар.
Күкрәк көчен салгач, кулларына
Тормыш тезгеннәрен алалар.

Без бурычлы, эшле, юллы иткән
Әтиләргә, кайтмас ир-атка.
Аларның бит олы юлы калды,
Тоташ тормыш калды мираска.

### Үтечкә

Бу дөньяда бернәрсәм юк иде,
Барысын да алдым үтечкә.
Буш кулларым белән кыймый торсам,
Үзе әйтә тормыш: «Үт эчкә!»
Һәм мин үттем һаман ала-ала
Җирдән — җылы, уттан — ялкынны.
Җирдән-судан алып, туфрактан да
Үлән белән бергә калкындым.
Бөтенесе миңа җирдән, күктән
Тик үтечкә генә түләнгән.
Кайтарырга кирәк алганнарны
Шул туфракка, шул ук үләнгә.
Җирдә башкаларны яшәртергә,
Яшәтергә үлән яшәргән.
Алыр өчен түгел, салыр өчен
Калдырырга иде яшәргә.
Үтечкә артык алып-алып та
Бермәл бирелмәс үтенечкә.
Үтечкә алынган гомерләр
Булмасын үкенечкә.

# «Мин — башкорт!» китабыннан

## (1993)

### Салават һәйкәле

Син — заманга,
Син вакытка һәйкәл,
Сине шулай вакыт күтәрде.
Кайгылардан көйгән җиргә һәйкәл
Калкытты җир, сөеп күкләрне.

Син — ярсуга, януларга һәйкәл,
Мең йөрәктән чыккан ут сымак.
Өмет булып очкан ук-хыялга
Вакыт киртәләре юк сымак.

Син — нәфрәткә, мәхәббәткә һәйкәл,
Үтәдең син йөрәк кушканын.
Хыялларны җәя итеп тарттың,

Дошманнарга нәфрәт — калканың.

Батырлыкка, чаялыкка һәйкәл,
Алыштың син җаның аямый.
Аргамагың белән мәңге бергә
Бөркет булып кундың кыяга.

Сине халкым утлы гасырларның
Газабында янып тудырды.
Бар максатың — богауларны өзеп,
Ил күзенең яшен юдыру.

Һәйкәл булып бастың азатлыкка,
Һәйкәл булып бастың хаклыкка.
Син һәйкәлсең җирдә берләнбергә —
Син һәйкәлсең яугир халыкка!

*** * ***

«Иң мөһимен генә яз син!» —
Колагымнан китми аваз.
Нәрсәдер ул, кемгә мөһим
Килер кичтә, аткан таңда.

Миңа, беләм, кояш үзе,
Аны көткән газиз җирем,
Эчәр суым, сулар һавам —
Шулар белән дөньям тере.

Менә шуңа көнем, төнем
Рәхмәт белән озатыла.
Бу бәхетне артабан да
Инде ничек озайтырга?

...Ел да җәе соңлап килә,
Иртә килә кырыс кышлар.
Көзен бераз үрчеп китсә,
Язын кимеп кайта кошлар.

Үләннәргә ләйсән түгел,
Көне-төне тузан ява.
Болганадыр эчәр сулар,
Авырлана сулар һава.

Сызлану арта йөрәгемдә,
Төягемнән киек китсә,
Ятим торса кош оясы,
Чәчкә коймый үлән кипсә.

Арта бара күз алдымда
Куаксыз кош, кошсыз куак.
Нигә кими җирем яме,
Аның котын кем соң куа?
Бары суга сусаганда,
Елга кими, күлләр корый.
Нигә һаман оран салмый
Бөтен дөнья үрә торып?

«Иң мөһимен генә яз син!» —
Колагымнан китми аваз.
Нәрсәдер ул, кемгә мөһим

Килер кичтә, атар таңда.

Җир бит берәү, юк бит кемнән
Барып алыр күрше-күлән.
Кайсысы соң мөһим түгел:
Җир, су, кош, күк, һава, үлән?

## Егерменче гасыр

Егерменче гасыр,
Түгелмени оят?
Авып әйләнгәнче
Намусыңны уят!

Кая басма — киртә,
Кая бакма — упкын.
Мин бүгенгә бар да,
Ә иртәгә юкмын.

Җир өстендә дөрли
Күпме тәмуг уты,
Шунда ташлар сымак
Иң якының тотып.

Юллар алга түгел,
Бары артка илтә.
Нур төшәр үр кайда?
Кичкә охшаш иртә.

Аермый башланды
Яманны яхшыдан.
Түбәнләп ташлыйлар
Яхшыны шакшыдан.

Ирләре йомшады,
Хатыннар каттылар.
Киттеләр сөюләр,
Нәфрәтләр кайттылар.

Артлары ал булып,
Аллары арт булды,
Таркату, бутауга
Көтелгән шарт булды.

Аңларга соң ничек,
Кор* башында — иблис.
Мондый могҗизаны
Көтмәгән иде ил һич.

Алтынның өстендә
Ач без, ялангач без.
Ыштансыз калабыз,
Кемнән талангач без.

Ярышып, дәртләнеп,
Булганны таратып,
Сорыйбыз хәерләр,

Дөньяны аптыратып.

Газапның башымы
Гасырның азагы?
Ул каян туа соң —
Бетмәслек газабы?

Егерменче гасыр,
Түгелмени оят?
Авып әйләнгәнче
Вөҗданыңны уят!

* * *

Иркәләнер иртәләрем бар дип,
Көн күрсәтер диеп көннәрем
Ымсынмыймын. Бер дә юкка пошмый,
Сынауларга торам көн дә мин.
Һәркем җирдә үзе юнен күрә,
Кемдә дисең минем кайгым бар.
Әле дә барын бердәй тигез күргән
Ал кояшым, якты аем бар.
Теләүчеләр бардыр аларны да
Тик үзенә борып куярга.
Нинди кыйммәт төшсен һәр үткән көн,
Мөмкин түгел аннан туярга.
Кара төнем ак өметтән тора.
Хак хакыйкать булып туа таң.
Мин үземнең яшьне үзем сөртәм,
Мин үземне-үзем юатам.

## Мин — башкорт!

Мин — күптәнге,
Күпне күргән башкорт.
Чал Урал да миннән яшьрәк.
Минем сагышымны, булмышымны
Тарих әле үзе яшерә.

Өметләрем Урал булып калыкты,
Күз яшемнән акты Агыйдел.
Куган юлым минем гел хак булды,
Хыялларым һәрчак ак иде.

Җирләр тетрәгәндә Урал чүкте,
Мин тетрәндем, ләкин чүкмәдем.
Яндым, туңдым, мең-мең газап үттем,
Тик яшемне юкка түкмәдем.

Әлмисактан башлап гомер бакый
Кояш белән җиргә табындым.
Хыял белән күккә күтәрелдем.
Көн өстендә байтак абындым.
Кем ышанмый — кыя ташларында,
Шүлгәннәрдә калды култамгам.
Хәләл каным белән яздым язмыш,
Изге туфрагыма ул тамган.

Елгаларга ятып сулар эчтем,

Күк күлләргә төшеп коендым.
Күккә күпме күз нурларым сеңде,
Җиргә күпме яшем коелды.

Карурманнан төнлә юллар үттем,
Ат йөздереп чыктым Җаектан.
Хәзер генә урман кырылган да,
Хәзер генә елга саеккан.
Арал ярларыннан төньякларга
Мин Кәнифә юлын сер тоттым.
Ихласлыгым, беркатлыгым белән
Мең отылдым җирдә, бер оттым.

Бүген торсам Торатаулар тормый,
Күлләр кибә, корый елгалар.
Урманнарны кырып бетерәләр,
Тауларымны бәреп егалар.

Киекләре кая булып беткән,
Хәтта үлән кими дәвага.
Бары кыйммәт, чик куясы калган
Эчәр суга, сулар һавага.

Нигә әле яңа буыннарым
Олы горефләрне санламый?
Бала холкын ана аңлый алмый,
Ана телен бала аңламый.

Җиргә килгән яңа алмашымның
Нигә кими бара иманы?
Киләчәккә һаман багыймчы мин,
Якты өметләргә инанып.

Мин — күптәнге,
Киләчәккә башкорт —
Меңәр еллык елым артымда.
Үткәннәре барның — киләсе бар,
Шуны белсен яшем, картым да.

## Табыннарга

Табын, дисәм, күз алдыма баса
Өстәл сыгылыр сыйлы табыннар.
Ачлык елны ыру хакы өчен
Бүлешенгән соңгы кабым да.

Туганнарым:
Кәлчер Табын,
Төкен Табын,
Дуан Табын,
Кара Табын,
Барын Табын,
Күрпәч Табын,
Кумырык Табын... —
Без бит нинди олы Табын!

Әй, ыруым!
Синең сүнмәс утың
Ничә мең ел элек кабынды?
Кабиләгә ничек сыенды да,

Ничә ыру сиңа табынды?

Бу исемең ничек кушылды да
Шунча гасыр ничек сакланды?
Меңәр еллар онытылмас өчен
Гамәлдә ул ничек акланды?

Ырымбурдан Чиләбегә хәтлем,
Ык буеннан алып Туккача,
Европадан Азиягә сузган
Канатларын башы сукканча.

Мең заманнар аша сөрән салдым,
Мин адашкан улы Табынның.
Эзли торгач, тик гасырлар аша
Гүя бүген генә табылдым.

Табыннарны тоташ табышырга,
Ныклап тупланырга чакырам.
Юлларыбыз тагын киңәер дә,
Шәфәгыбыз балкыр яктырак.

Без туплансак башка исем булмас
Безнең кабиләдән зуррак;
Безнең тамырлардан куәтлерәк,
Безнең табыннан да нурлырак.

Йөрәкләр дә, хыяллар да бүген
Кабат сүнмәс өчен кабынган.
Кабындыра, табындыра торган
Тупланыйкчы олы Табынга!

## Нигә икән?

Аңламассың бу дөньяны —
Тегеңә менә кара:
Чакырган җирдән кача да
Куылган җиргә бара.

Бик күп нәрсәне белгәннәр —
Белми нәфсене тыя.
Олы дөньяга сыймаган —
Тап-тар урынга сыя.

Син сөйгән сине яратмый,
Ярата һич сөймәгән.
Эндәшмәгән аңлашыла,
Аңлатмый күп сөйләгән.
Күз алдында торган нәрсә
Гел читтә торып кала.
Күзлеләр күрми килгәнне
Бер сукыр тоеп ала.

Үз-үземнең соравыма
Сизмәстән башым иям:
«Бер-беренә тими бүре,
Кешеләр нигә тия?»

Җавап тапмый күп сорауга
Кабынып китә чикәм.
Гади сымак, башым җитми,
Нигә соң, нигә икән?

* * *

Яндыруы булган күптән,
Янучы да, димәк.
Фаҗигаләр, могҗизалар
Тукталмаган кинәт.

Һәрберәүсе үз мәлендә
Үз өлешен алган.
Тик тарихта гомер бакый
Янучылар калган.

* * *

*РСФСРның халык рәссамы,*
*Русиянең художество академиясе*
*член-корреспонденты*
*Әхмәт Лотфуллинга*

Беркем сизмәгәнне, тоймаганны
Тик ул гына сизә, тик ул тоя;
Тере карашларны тере килеш
Бер чайпалтмый күчерә дә куя.

Иң тирәндә сүнми яткан очкын
Бары аның йөрәгендә каба.
Күңел сулышының беркем белмәс
Иң-иң якты буяуларын таба.

Көн дә күреп күрмәгәнне безнең
Өр-яңадан безгә ачып бирә.
Тормыш асылыннан качып түгел,
Һич тә татлап тормый, ачык бирә.

Нинди ачы булсын ул — хакыйкать,
Ул ачышны бары шунда сизә.
Әйтерсең лә бар тапканы белән
Бер сын түгел, бар дөньяны бизи.

## Хыялый

Ул хыялый диеп куркытмагыз,
Хыялдан ул шулай булган, мескен.
Хыялына беркем ышанмаган,
Уйларына төшенмәгән һичкем.

Мин хыялсыз кешеләрне беләм,
Бик күпләрнең үзәгенә үткән.
Хыялыйны да бит Алла түгел,
Хыялсызлар менә шулай иткән.

Алар белми җирдә теләгәннәр
Күктә хыял-йолдыз яндырганны;
Күп сусауны туган җирдә чыккан
Җанчишмәләр генә кандырганны.

Ышанмыйлар якты хыялга да,
Шикләнәләр яхшы төшләргә дә.
Әмма алар акны кара күрә,
Кулы бара яман эшләргә дә.

Әйдә ризамын мин, үзләренчә
Мине хыялый дип уйласыннар.
Минем дошманнарым, курыкканнарым —
Бөтен хуш күңелле хыялсызлар.

Төрле чаклар, төрле хәлләр булсын,
Бәхәсләр дә очрамасын кайчан,
Мин хыялый кешеләрдән түгел,
Мин хыялсыз кешеләрдән качам.

## Баш очында торам

Газиз җирем, баш очында торам,
Җиңеләйми һич тә сулышың.
Йөрәккенәң дарслап-дарслап тибә,
Яна күзең яшькә тулышып.

Ятасың син чак-чак тын алгандай,
Өмет кими бара күзеңдә.
Әйтерсең лә тәмам ваз кичкәнсең
Кемдер биреpеннән түземнәр.

Карап торганнарның инде хәзер
Берни килмәс кебек кулыннан;
Ятасың син шулай, ак бабакай
Тукмалгандай шакшы улыннан.

Тәннәреңә һаман дару түгел,
Агу яңгырлары явалар.
Нинди им-том килешер дә сиңа,
Шифа булыр нинди дәвалар?

Кулларымны өтеп алыр сыман,
Кызу маңгаеңа салганда.
Торам шулай, хәлсез әниемнең
Баш очында телсез калгандай.

*** * ***

*Муса Галигә*

Җирдә һаман каты сугыш бара,
Уе да юк әле туктарга.
Күкрәгегез һаман телгәләнә
Төрле утлар, төрле уклардан.
Уе да юк әле туктарга.

Сугыш бара кешелеклек өчен,
Кеше итү өчен кешене.
Шуңа кайтып калсын өчен бүген
Бар асылы бөтен эшенең,
Кеше итү өчен кешене.

Бара сугыш, атыш, шартлау белән,
Ешаялар йөрәк шартлаулар.
Хәвефле дә, шатлыклы да инде

Ал сызыкта сезнең атлаулар,
Ешая тик йөрәк шартлаулар.

Әллә нигә дөнья сәерләнә,
Әллә нигә кеше ваклана:
Сакланмастай чакта саклана да
Акланмастай чакта аклана,
Әллә нигә кеше ваклана.

Тауга карап тау булырдай булып,
Көннән-көнгә арта көнчелек.
Бары белән бәйрәм итә белми,
Бу яшәү, дип, гүя өч көнлек,
Көннән-көнгә арта көнчелек.

Җан дус булганнар да хөкемләшә, —
Бүленәме намус урталай?
Ана — кызны, ата улны белми,
Аксакалның битен ерталар,
Бүленәме намус урталай?

Әле күпләр кабынып та бармый,
Сез утларда ничек яндыгыз?!
Яуда юкка ятып калдыгызмы,
Бушка түгелдеме каныгыз,
Утларда сез ничек яндыгыз?

Төрле сугыш яланыннан ялсыз
Утлар, уклар һаман явалар;
Күпләр сугыш ярасыннан түгел,
Тормыш ярасыннан авалар.
Утлар, уклар һаман явалар.

## Сорау

*(Р.Рождественскийга ияреп)*

*Атаклы күз врачы*
*профессор М.Т.Азнабаевка*

Марат Тәлгат улы!
Аптырама —
Шигырь язам үзем аптырап.
Заман берчә күпме сорау куя.
Заман күпме җавап таптыра.

Алларыңда мең мәшәкать бардыр
Чал башыңны синең катырган.
Әллә ниләр борчыса да, булдым
Бу сорауга тагын кайтырга.
Күпме кешенең син күзен ачтың,
Нур кайтардың күрмәс күзләргә.
Булды алар яңа туган сыман,
Тотыш тормыш, дөнья үзгәргәч.

Алар сине әүлиядай күрә,
Тиң күрәләр хәтта Аллага.
Бүген сиңа башка соравым бар,

Бик күплəрдəн җавап алмаган.

Җирдə сукырлардан күзлелəр күп,
Күрелмəгəн эшлəр күбрəк;
Күбесенчə күрүчелəр күрми,
Шуңа ышанычсыз күп терəк.

Бүрəнə аша бүре күргəннəр дə,
Эргəсендə торсаң, күрмилəр.
Аяк астын күрмиенчə күплəр
Дус гəүдəсе аша үрлилəр.

Күрмəмешкə бердəм салышалар,
Күргəненə күзне йомалар.
Шуңа хаклык сукырлана бара,
Күрмəүчелəр һаман уңалар.

Шəйлəмилəр баскан җирлəрендə
Үзлəренең ничек торуын,
Яфрак шаулавына исе китеп,
Күрми тамырының коруын.

Марат Тəлгат улы!
Тик бер сорау,
Соравымнан юл юк качарга:
Нинди чара табып, ничек итеп
Күргəннəрнең күзен ачарга?!

## Олы Телəк. 1710 нчы чакрым

Монда 1989 елның 4 июнендə «Новосибирск—Адлер» поезды белəн фаҗигадəн соң янган кешелəрнең сөяк-күмерлəрен бульдозер белəн этеп күмгəннəр.

*Гəзитлəрдəн*

Сугыш яланында, ут астында
Дустын кабер казып күмгəннəр;
Кабер казыган чакта уттан, туптан
Хəтта үзе үлсə күнгəннəр.

Менə бүген тыныч күк астында
Аянычлы соңы гомернең;
Бульдозерлар белəн актаралар
Кешелəрдəн калган күмерне.

Бары оҗмах булыр башкорт җире
Əйлəнде соң нигə тəмугка?
Дөнья шулай дəвам итə калса,
Агачларың җитмəс табутка.

Сыймый башка мондый имансызлык,
Əрни йөрəк мондый җəбергə.
Бульдозерлар белəн гамьсезлекне
Күмеп булса икəн кабергə!

## Рəми

Киң дөньяда җанга урын тапмый,
Урын тапсаң, анда ямь тапмый

Изаланган чаклар ешаялар:
Йә кич булмый, яки таң атмый.
Базар сыман кайнап торган җирдә
Япа-ялгыз торып каласың.
Шундый чакта мендәр арасыннан
Сине эзләп искә аласың.

Төрле җыеннарда кеше юкта
Иң-иң туры сүзне әйтергә,
Күп елларны бозваткычтай ерып,
Син төшәсең һәрчак хәтергә.

Тормыш мизгелләре салкынайса,
Көннәр торса яман давыллап,
Әллә каян сулышларың килә,
Янгантауның янар тавыдай.

Еш эзлибез яшәү өлгеләрен,
Тормыш куйган чакта аркасын.
Офыклардан таныр сының белән
Җайлап кына килеп калкасың.

Чаң кагабыз:
Көрәшчеләр җитми,
Заман көн дә ала бугаздан.
Син бит яуда ялгыз солдат көе
Көйдең утта, туңдың кар-бозда.

Кинәт түзми, безнең күз алдында
Шартлаганда синең йөрәгең,
Авыз ачып карап торып калдык,
Юк иде шул һичбер терәгең.
Әйтерсең лә әйттең: җиләтте!
Һәм уятып киттең милләтне.

## Шагыйрь

*(Низаметдин Әхмәтов хакында уйлану)*

Мин күрмәгән, мин белмәгән —
Минем яңа ызам бит син,
Низаметдин.

Яхшы, яман арасында
Сагыш салган ызан бит син,
Низаметдин.

Тагын башкорт йөрәгендә
Канап торыр имза бит син,
Низаметдин.

Син түзгәнгә таш та түзмәс,
Шөкер, үзең чыдам бит син,
Низаметдин.

Сине шулай җыр яшәтә,
Чөнки үзең җырдан бит син,
Низаметдин.

## Ураза

Рамазан ае тагын килеп җитте,
Урап кайтты тагын ураза.
Карт-корылар көндез су да капмый —
Түгел микән артык зур ыза?

Мәле җиткәч, авыз ача алар,
Курка-курка гына азактан.
Бик чамалап кына тәгамләнә
Талонына килгән азыктан.
Бер изгелек җиде изгелеккә,
Бер савабың җиде савапка
Тора, имеш. Бер гөнаһың исә —
Тарттырырлык җиде җавапка.

Чакыра ул бары яхшылыкка —
Ызгышмаска, гөнаһ кылмаска.
Имештер, ул күпне үлчәр чара —
Барын үлчәр берчак бу мыскал.

Шушы карчыкларның, чал картларның
Алларында юк та гөнаһым.
Уразаны бүген мин тост сыман
Бик күпләргә килә санасым.

Ләкин шул тосттан соң бик озакка
Мин ураза тотам шәрабтан.
Кайберәүләр ышанмас та моңа,
Баш чайкарлар: «Булса харап ла...»

Уразаны тотучылар сирәк,
Күбрәк шул артык ашаучы.
Бер могҗиза туып, табылсачы
Шулар арасыннан башлаучы.

Кая гына бакма, дүрт тарафта
Чамалардан аша чамалар:
Артык ашаучыдан арба сына,
Җимерелә кышын чаналар.

Алар бушка ашый илнең малын,
Авырсынмый һич тә хәрәмгә.
Ә туюны бервакыт та белми,
Күпме мөлкәт китә әрәмгә.
Уразаны тамак кына түгел,
Тотсын иде куллар, нәфселәр.
Ана үрдәк кебек симез кошлар
Торып калсын иде нәкъ челән.

Кәсебендә янә уразаны
Уйнашчылар тотсын, азгыннар.
Яла ягучылар, гайбәтчеләр
Туктап торсын иде аз гына.

Кан эчүче ике аяклы ерткыч
Уразага бераз тукталса,
Картинәсен, картатасын уйлап,
Кеше булуына укталса!..

Кемгә генә ул килешмәс иде,
Тотса икән берәр ураза.
Юк шул, бик күпләргә барып җитми,
Көпә-көндез әнә бур аза.

Карт-корылар үрнәк күрсәтәләр,
Тик алар да үтә азайган.
Иман йокмасмы дип тырышалар
Алласыннан качкан адәмгә.

Иң зур теләкләрнең хәтта шунда
Кабул булса тик берничәсе.
Шулчак ачылырдай сыман була
Дөньяның бер Кадер кичәсе.

## Базар

Базар кыза:
Ачык базар,
Ябык базар,
Кара базар,
Эчтә базар,
Тышта базар,
Җәй дә базар,
Кыш та базар,
Илем тоташ олы базар.
Астан сату, өстән сату,
Күпләп сату, ваклап сату,
Күрәләтә күз алдында
Сатмастайны аклап сату.
Халык кызган, хакы чыкса,
Карап торган атын сата.
Атын гынамы соң әле,
Уйлап тормый, затын сата.
Иманы юк сата иман,
Акылы юк сата акыл.
Бөтен җирдә базар халкы,
Һәрнәрсәнең арта хакы,
Иң зур бәһа — базар хакы.
Кинәт кенә нигә шулай,
Нигә халык исем сата?
Җанын сата, тәнен сата,
Иртән сата, кичен сата —
Менә шулай исем сата.
Алыш бара, биреш бара,
Һәркем бүген базар колы.
Иң Югары Советлардан
Бездә хәзер базар олы.
Ни алмасын, ни сатмасын —
Һәммәсе дә бер үк базар.
Әй, илкәем, чара табып,
Шул базардан берүк тазар!

## Минем исем

Чит илләрдән, чит телләрдән түгел,
Минем исем гади — көн сыман;
Утыз җидедән соң кушкан әти
Ирекә оран-өн сыман.

Ил калтырап, җир калтырап торган,

Оран салыр форсат тыелган.
Ирек уйлаучылар кабат кайтмас,
Адәм белмәс җиргә куылган.

Әти шундый исем кушып киткән,
Йөрәгендә өмет кабынды.
Үзе ирек өчен яуда янды,
Аның уты миндә кабынды.

Төрле басым-кысым ачты күзне,
Аера төштек акны-караны.
Телем ирке, илем ирке, диеп,
Байтак авыз ачып карадык.

Иң-иң изге сүзләребез хәтта
Төрле ауга барып каптылар.
Көчле куллар шундук авызларны,
Кан ялатып, бик нык яптылар.

Төкермәдек авыз тулы канны,
Хаксыз көчсезлектән оялып.
Сукканнарның кулы әле һаман
Кара канга йөри буялып.

Без ирекле, тиң хокуклы илнең
Бик ирексез халкы нигәдер.
Шундый көнгә төштек әллә ышанып,
Әллә пәйгамбәргә инәлеп.
Ireклекне яулап алалар бит,
Тик көрәштән җиңел качуы.
Хәтта шуңа бүген Ирек дигән
Исемемә йөри ачуым.

* * *

Мин үземне-үзем сакламадым,
Мине һәрчак Аллам саклады;
Бөтен өмет өзелгәндә дә бит,
Үзем сизми калдым, акланып.
Әллә нинди нахак-ялганнардан
Беттем дисәм тәмам тапланып,
Әллә ничек тагын көн ачылды,
Үзем түгел, Аллам саклады.
Дәрья кичеп, суда батмый чыктым,
Янмый үттем янган утында;
Карурманнар ныклап адаштырмый,
Йотмый чыгардылар упкыннар.
Бер карасам узган юлларыма —
Гөнаһым аз сыман саваптан.
Алла аңлар, дидем, аңламаса,
Качып йөрмәдем һич җаваптан.
Бу гомернең бөтен мәгънәсе —
Мескенлек һәм ирлек арасы;
Һаман юлда һәрбер адымыма
Гадел хөкем туры карасын.
Ирмен диеп бик ирәеп китсәм,
Гөнаһымны берүк аклама.
Җебеп калып, мескенлеккә төшсәм,

Жәлләп торма, Аллам, саклама.

* * *

Яшьлек узган, буяулары тузган,
Юк та сыман артык уйларлык;
Бер уйласаң, торып бер көләрлек,
Бер уйласаң, ятып еларлык.

...Ямьсез кызлар гашыйк булды миңа,
Ямьлеләре гашыйк башкага.
Хәзер шуны уйлап, хыялыйдай
Үзем баш чайкыймын, баш кагам.

Нигә ул ямьсезләр гашыйк икән? —
Үзем ямьсездер дип гарьләндем.
Ә ул кызлар мине кем дигәндер,
Дусларымнан гына әрләндем.

Алар мине хәзер оныткандыр,
Бәлки, онытып та откандыр.
Белмиләрдер әллә нигә минем
Хәтер оныттырмый тотканны.

Еллар үтте, яшьлек искә төшә,
Хәзер сүгәм үзем җансызны.
Соңлап белдем: гашыйк хатын-кызның
Һич тә булмый икән ямьсезе.

Алар хәзер иң-иң сылу булып
Сирәк-саяк төшкә керәләр.
Дәрьялардан аша омтылсам да,
Минем көймәм комга терәлә.

Яшьлек узган, буяулары тузган,
Юк та сыман артык уйларлык.
Бер уйласаң, торып бер көләрлек,
Бер уйласаң, ятып еларлык...

* * *

Дан һәм шөһрәт юлы.
Арба — тулы.
Иң-иң кыска юлны эзлиләр.
Талаш-тартыш бара.
Аннан кемне
Төртеп төшерергә белмиләр.

Ләкин берәү төшми,
Бара алар.
Чәкүшкәгә басып булса да,
Ат артыннан җәяү йөгерәләр,
Анда урын күптән тулса да.

Басынкылык инде данга түгел,
Билгесезлеккә иң кыска юл.
Кем басынкы — үзен-үзе баса,
Үзен-үзе белми кыскан ул.

Менә шуңа елгыр, ерткыч җаннар
Дан, шөһрәт дип алдан чабалар;
Һич тә иҗат түгел, хәйлә белән

Алга чыгу юлын табалар.

Мин дә артта, һәрчак авыз ачып
Көллесен дә кылам тамаша.
Алга киткәннәрне, калганнарны
Күз яздырмый күзләп маташам.

* * *

Өлкәннәр безне алдады,
Без алдадык балаларны:
Алар безгә ышанмады,
Күңеленә сала барды.
Тыңласа да алар безне,
Өлге итеп карамады;
Ничек кенә кылансак та,
Безнең өлге ярамады.

Безгә бүген заман карый,
Шул балалар күзе белән.
Бала сыман без торабыз
Ләм-мим җавап сүзе белән.

* * *

Авыр чакта мин урманга килдем,
Аугач дустым ауган имәндәй;
Кайгым агачларга күчмәсен, дим,
Кара урманнарга керәм дә.

Агачларның суты аңкып тора,
Үләннәрнең исе — исерткеч,
Яшь үләннәр, яшь яфраклар мәле —
Яшәрүнең тыны искиткеч.

Ә тирәмдә гөрсләп агач ава,
Җир селкенә, агач ауганда;
Дуслар ава кискән агач сыман,
Яфракларга баллар яуганда.

Барчасы да гөжләп җиргә ава,
Алалмыйча җирдән аласын.
Агачларның телен аңламагач,
Аһ, дип кенә катып каласың.

Кешеләрем ава урман сыман,
Исәбе юк, барлап тормадым.
Синең хәлең безнекенә охшаш,
Ходай ярдәм бирсен, урманым!

* * *

Миңа шундый гаҗәп төшләр керә:
Имеш, мин яшимен Шүлгәндә;
Монда кичергәнне, тойганнарны
Онытырлык түгел үлгәндә.

Шундый бер төш: имеш, тирә-юньгә
Каратаудан карап ятамын.
Салаватның эзләренә басып,
Өнгә күчәр уйга батамын.

Ямантауны, Янгантауны күрәм,
Сүнмәс утларыннан ут алам;
Уянам да, ялкынында янып,
Өн белән төш бергә бутала.

Имеш, таштугайда килеп торып,
Сары сагышларга эләгәм.
Саташумы?.. Юктыр. Шул төшләрдән
Хәтта төшемдә юк җиләгән.

Имеш, мин уянам: өстә — кием,
Аягымны да бит чишмәгән;
Юл калмаган сыман үтелмәгән,
Су калмаган сыман кичмәгән...

## Кан хәтере

*(Басыйр Рафиковның «Карасакал» романын укыгач)*

Һичбер вакыт илем тын булмаган —
Үткәннәрдә калсын аңсызлык:
Башкортларның канын күп кайнаткан
Башкортларга булган кансызлык.
Халкым өчен тарих җиле һәрчак
Тискәредән генә искәндә,
Сәбәпсезгә аның күпме кабат
Башкисәр дип башын кискәннәр.
Тоташ-тоташ авылларын үртәп,
Үртәп тере адәм калмаслык,
Шаһит калдырмыйча кырганнар гел,
Җирдә һичкем искә алмаслык.
Мәңге кызышканнар, тырышканнар
Бар халыкның исен җуярга.
Тик башкортлар гына баш бирмәгән,
Зур болалар һаман куерган.
Нинди генә чара күрмәсеннәр,
Яздырырга теләп аңыннан.
Халкым кайчак өнсез торып калган,
Ә хәтере күчкән канына.
Акылыма сыймый — халкым күпме
Яшен түккән, канын агызган.
Менә каннан канга күчә килгән
Кан хәтере төшкән кәгазьгә.

## * * *

Башкортстан — байлык, хәзинәләр...
Исәбе юк бөтен тапканның.
Ничәмә юл синнән алып чыга,
Бер дә биге юк бит капкаңның.

Гомер буе ташыдылар синнән,
Тапкан бере читкә агыла;
Тагын күпме ташыласы бардыр,
Күпме калды икән тагын да?

Без бит һич тә саран түгел, ләкин
Һәрнәрсәнең була чамасы. —
Читкә елга булып агылганда,
Үзебезгә таммый тамасы.

Байлыкларың, хәләл байлыкларың
Башкаларга бар да, сиңа — юк,
Үткән булгач, киләчәгең бардыр,
Тик бүгенгең генә нигә юк?!

* * *

Җитәрлек күрсәтте бу дөнья:
Күп йөртте түрендә, тупсада;
Өйрәндем янарга, туңарга,
Давыллар яңадан купса да.

Басылмас гарасат алда да,
Иң соңгы сулышны алганчы.
Яшәлер, мөгаен, нәкъ шулай —
Өлгегә, гыйбрәткә калганчы.

Фәһемле булдымы тормышым? —
Табынмас ирләргә табындым.
Шырлыклар ерылып чыгылды,
Абынмас җирләрдә абындым.

Ораннар салмадым кайвакыт,
Тыгылмас бәхеткә тыгылдым;
Сынардай мәлләрдә нык торып,
Сыгылмас чакларда сыгылдым.

Яшәлгән елларның ызасы
Аерды, каерды канатны.
Төшмәдем кинәттән авып та,
Йөрәктән ярыйсы кан акты.

Шулай да ярларсыз язмышым,
Кирәкми әллә кем яклавы;
Авыры — дөньяның ярасын
Яралы йөрәктә саклавы.

* * *

Алып качкан атлар күргәнем бар:
Дилбегәләр шартлап өзелә;
Арба түңкәрелеп ятып кала,
Һәлак була аты үзе дә.

Тормыш бүген алып качкан аттай,
Алып качкан аттай дуамал;
Йөкне кая илтеп аудармактыр,
Үзен-үзе белми куа мал.

Әллә кайчан олы юлдан чыккан,
Басар җирен гүя чак таба...
Ак-караны күрми, күзе тонып,
Дилбегәсе өзек ат чаба.

## Атларга атланыйк!

Башкорт һәм татар халкы арасына чөй кагарга теләүчеләр һаман тынычланмый. «Ике туган талаша, атка менсә — яраша» дигән мәкаль хәтеремә еш төшә.

Әле без талашмаган,
Хәл дә юк аңлашмаган,
Һәрберебез чәчәрлек
Каннарны ялашмаган.

Өсләтүче мөртәтнең
Этенә әйләнмик без,
Азак ерып чыкмаслык
Мәхшәргә бәйләнмик без.

Мал бүләргә кирәкми,
Туплыйкчы булган малны;
Бүлә торгач, болай да
Бик азы кулга калды.

Җыр да, тел дә кушылган.
Нигә соң аерырга,
Йөрәккә кергән моңның
Канатын каерырга?

Меңәрләгән гаиләгә
Кычкырмыйкчы талакны.
Үтәтик без мөртәттән
Халык куйган таләпне.

Барып атлар бәйләрлек
Бозмыйк ла якынлыкны.
Бер яклап та җибәрмик
Арага салкынлыкны.
Менә шуңа бер төптән
Атларга атланыйк без;
Кайгыда бергә кайгырып,
Шатлыкка шатланыйк без,
Атларга атланыйк без!

## Кара атлар — ак бәхеткә

*(Айгөл белән Илгизнең туеннан)*

Алып очты, алып очты
Ап-ак юлдан кара атлар.
Аяклары җиргә тими, —
Ничек шулай бара атлар.

Кыза гына, кыза гына,
Ак күбеккә батсалар да;
Ярсулары бетмәс сыман,
Мәңге шулай чапсалар да.

Йөрәгемне учка тотып,
Һәр минутны барам санап.
Чаналарны аудармаска
Җир янтаеп кала сыман.

Егет кочкан җан сөйгәнен,
Җылы тунга урап кына.
Кара атлар оча сыман,
Ак бәхеткә юрап кына.

Җир сискәнгән, күк сискәнгән
Кыңгыраулар тавышына.
Кояш үзе каршы сыман
Көннең кичке авышына.
Җилеп барган чаналардан
Тузып кала кар бураны.
Авылымның, кыш дип тормый,
Кеше тулы бар урамы.

Каршы чыккан авылдашлар,
Ак тастымал, икмәк тотып;
Яңа пешкән икмәкләрдә
Төягемнең бетмәс коты.

Туган җирнең бетмәс коты —
Һәр морҗадан чыга төтен.
Урам тулы бала-чага,
Дөньялары нинди бөтен.

Ак дөньяның ак юлыннан
Кара атлар җилә генә.
Яшьләр гүя кушылып үскән
Бер-беренең беләгенә.

Ат җиле дә, кыш җиле дә
Йөзгә бәрә, өрә генә.
Түзем бирсен атларның да,
Яшьләрнең дә йөрәгенә.

Чажлап карны эретердәй
Сулышларның кызулыгы.
Офыкларга барып кунган
Туйларның бу кызулыгы.

Яшьлек килә, яшьлек җилә,
Белеп кайда җиләчәген.
Алып китте алар алга
Ыруымның киләчәген.

## Илне сагыну

Безнең күз алдында
Юкка чыккан илне,
Тик җырымда булсын,
Тергезәсем килде.

Еллар буе төзеп,
Таркатылган илне,
Хыялымда булсын,
Терелтәсем килде.

Күмәкләп бер төптән
Яшәртәсе илне,
Тик уемда булсын

Яшәртәсе килде.

Чын булмас бу диеп,
Тәүдә ышанмадык.
Башка сыймагачтын,
Хәтта кымшанмадык.

Ишеттек без байтак
Күпме матур сүзне.
Көтәргә күнектек,
Барсына да түздек.

Ил башына алмаш
Килде төрле башлар.
Чыгарылды күзләр,
Төзәтәм дип кашлар.

Дөм сукыр юлчыдай,
Югалттык юлларны.
Бөтенләй оныттык
Башланган юл барны.
Олы юл югалып,
Сукмаклар таралды.
Үрмәкүч авыдай
Мең сукмак яралды.

Көн дә аймак саен
Президентлар арта.
Юрганны һәрбере
Тик үзенә тарта.

Талашка, тартышка
Түзәрме бу юрган?
Бер көндә югала
Ничәмә ел корган.

Кылынган сыймый бит
Бернинди киртәгә.
Кем бүген һәммәсен
Керталыр тәртәгә?

Башсыз диеп, башны
Бәреп булмый ташка.
Ташлар күтәрмәслек
Уйлар төшә башка.

Бәйрәмнәрдән китте
Чын бәйрәмнең төсе,
Сагынам үткәнне,
Менә икмәк өсте.

Кеше йөзләреннән
Елмаюлар китте.
Илем чикләредәй
Бик күп күңел китек.
Көр илем, хөр илем,
Торсачы яңадан.
Бар халык соңламый

Килсәче аңына,
Килсәче таңына.

Булсачы исеме
Колакка ятарлык,
Тамгасы — танырлык,
Байрагы — багарлык.

Кешеләр кешедән
Белмәсен туйганны.
Эзләми дошманны,
Эзләсен туганны.

Кабынсын дим күпләр
Минем кабынудан.
Ни торгызыр илне
Шушы абынудан.

Тагын ни бар изге
Илгә табынудан.
Күк саргаер төсле
Илне сагынудан.

Мин дивана микән,
Ышанамын менә.
Чын кеше итә ич
Ил тойгысы гына.

Гөрләп торган илдән
Нәрсә торып калды?
Мондый таркалудан
Халык нәрсә алды?
Туганың чит илдә,
Дусларың чит җирдә.
Якыннар читләште,
Читләште бик бердәм.

Талаш, тартыш, сугыш —
Башларга сыймаслык.
Көн-төн булган хәлләр
Уйларга кыймаслык.

Ил күзендә — үпкә,
Ил күзендә — сагыш.
Сагыш кынамы соң,
Ил күзендә — каргыш.

## Елкы елы

Елмай, Елкы елы!
Мин кушкуллап
Ябышамын синең ялыңа.
Аллаларга табынгандай, бүген
Күзләреңә карап ялынам.
Тыңла минем изге теләгемне,
Тыңла минем әрнү сүземне,

Һәрбер елдан дүрт күз белән көтеп,
Инде күпме, күпме түзелде.
Булчы сүзеңдә дә, эшеңдә дә
Кешеләргә тугры елкыдай.
Күзләреңдә гүя озак көткән
Безнең соңгы өмет ялтырый.
Яшәдек без һаман өметләнеп
Бу дөньяның күпме елына.
Мең алданган сантый сыман һаман
Сукыр өметкәме җылынам.
Эшлә әле җитез елкы сыман,
Эшләт әле безне ат сыман.
Бурап яуган буш сүзләрдән туйдык,
Тыңлаганда булды хак сыман.
Хак та булды сыман, ят та сыман,
Акланырга сәбәп таптылар.
Андый сүзләр таулар булып ятып,
Кар суыдай эзсез актылар.
Хәзер сүзгә ышанучы кими,
Бетеп бара сүзнең кадере.
Синең алда мең-мең сорау тора,
Бер җавапның юк һич әзере.
Уйлан, Елкы елы, кыза бүген
Һәр тарафта тартыш-талашлар.
Һич саксызга әллә ниләр юллап,
Туа төшкә кермәс таләпләр.
Кайберәүдә — әллә нинди хыял,
Уйларга да хәтта кыймаслык.
Хәвеф-хәтәр, шик-шөбһәләр арта —
Уйлый китсәң, башка сыймаслык.
Киләсең син дөнья болганганда,
Язгы сулар ярсып ташкандай.
Намус тезгеннәре ычкынганда,
Әдәпсезлек хәттин ашканда.
Милләт белән милләт бит талаша,
Бер-берсенә бүген ут сала.
Күпне күргән, кайгы эчкән җирдә
Кан, тир һәм яшь бергә бутала.
Бәләкәйләр киң дөньяга сыймый,
Кемнәргәдер урын азайган.
Минем өйдә хуҗа булмакчылар
Фатир сорап кергән адәмнәр.
Һәр туган көн яңа сорау куя,
Мең-мең сорау ала халкымнан.
Әллә дөнья шулай акыл туплый,
Әллә яза булган акылдан?
Елкы елы, соңгы өмет синдә,
Абайлап бар, куйма сөрлегеп.
Син егылсаң, юллар өзелер дә,
Сынар сыман дөнья өрлеге.
Бар яманлык ияреңнән очсын,
Елдан елга күчеп утырган.
Сине озатканда насыйп булсын
Ләгънәт түгел, рәхмәт укырга.
Елкы елы, кузгал елдамрак,
Күзләреңә карап инандык.
Кешеләрнең намусларын уят,
Җиргә кайтар киткән иманны.

## Шарлавыкта бию

Миңа 1969 елда Башкорт халык биюләре ансамбленең Урал аръягы районнарында гастрольдә чакта кайсыбер номерларын Сибай янындагы Гаделша шарлавыгында кинога төшергәндә берничә көн рәттән күрү бәхете насыйп булган иде. Анда - ансамбльнең атаклы җитәкчесе Фәйзи Гаскәров та килгән иде. Аның исеме чыкканда, һәрчак шул хатирә күз алдыма баса.

Көн битендә,
Кызган чакта ташлар,
Биеделәр упкын өстендә.
Тынычландың кичен кояш сыман,
Бурыч төшкән кебек өстеңнән.

Таң атуга тагын, кояш ише,
Уяндың син ярсып, кабынып.
Күрдем шунда: һәрбер биючегә
Синең утың калды ягылып.

Бию һаман кыза гына барды,
Менгән саен кояш югары.
Әй бастылар, биеделәр шулай,
Утсыз ташның утын чыгарып.

Кыздырды көн, гүя шушы уттан,
Куәтеннән бию котының.
Үз күзләрем күреп, табындым мин
Алласына бию утының.

Әй бу утлы бию, утлы гомер
Кемнең йөрәгендә уелмас!
Бу биюне бер кат күргәннең дә
Хәтереннән мәңге җуелмас.
Гаделшаның биек шарлавыгы
Шаһит булды шундый биюгә.
Торышлы бу бию, бу очышлар
Ирәндекләр башын июгә.

Әй син утлы язмыш!
Сының калды.
Эзең калды кояш төсендә.
Сине тапкан бии алган халык
Шарлавыкта, упкын өстендә.

## Мәңгелек ут

Ил, җирем буйлап
Күп ут кабынган,
Һәр каһарманга
Бер ут табылган.

Күпме корбанның
Йөрәк ялкыны
Мәңгелек утта
Яна талпынып.

Кызыл ут гүя
Туганнар каны.
Батырлык өчен

Туганнар даны.

Аудылар алар,
Ил аумасын дип;
Аларны һаман
Яшибез көтеп.
Намус утлары
Яналар җирдә.
Аларга агым
Өзелмәс бер дә.

Хөрмәтләргә дип
Ялкын-көлтәне,
Көн дә киләләр
Яше-өлкәне.

Кандай чәчкәләр —
Бүген, кичәге...
Әйтерсең ята
Күңел кисәге.

Яна, дөрли ут,
Хәтер — мәңгелек.
Хәтер сагында
Тора кешелек.

## Сорау алу

Салават һәйкәле янында үткәрелгән шигырь бәйрәмендә Башкортстан Республикасының хәрби комиссары генерал В.Трофимов моңа кадәр Уфа гарнизоны Офицерлар йортында торган А.Кузнецовның «Салаваттан сорау алу» картинасын Башкортстан Язучылар союзына бүләк итте. Мәшһүр картина хәзер Язучылар йортына кергән һәр кешене каршылап тора.

Иртән килеп керсәм, һаман шул хәл:
Салаваттан сорау алалар.
Төшен чыксам, кичен кайтып китсәм,
Һаман сорау алып калалар.

Ничек бетми икән сораулары,
Әй алалар сорау, алалар.
Тагыладыр нинди зур гаепләр,
Ягыладыр нинди ялалар?

Ни җинаять, нинди гаеп, яла
Яудыралар икән батырга?
Димлиләрме халкын бастырырга,
Өндиләрме илен сатарга?

Нигә озак маташалар икән,
Нindирәк соң җавап таптырып?
Карашында күрмиләрме икән
Җавапларның иң-иң тапкырын.

Бирми микән инде бар җавапны
Һич баш бирмәс горур буй-сыны.
Бу карашка ялварулар читен,
Булсын анда нинди буйсыну.
Әллә ниләр кичерелә һәрчак,
Онытылып карап сурәткә.
Батыр безгә дәвер аша баккан, —

Оста рәссам шулай күрсәткән.

Әй, Салават! Хәл-шартларны бүген
Әйләндереп булса кирегә,
Син тиешле сорау бирергә дә,
Синең алда, заман каршысында
Без тиешле җавап бирергә.

## Торатау итәгендә

Торатауда йөрәк дертли хәтта
Тавышыннан бөре шартлауның,
Әллә авыр сулышыннан микән,
Аһлар итүеннән Шаһтауның.

Күтәрелеп сүнгән өермәдәй
Тик урыны калган Шаһтаулар.
Кыйратуга, таулар аударуга,
Табып була мең-мең сылтаулар.

Юкка чыккан Шаһтау — ышанычлы
Күгем гөмбәзенең терәге.
Буыннарым шуңа калтырыйлар,
Дертли шуңа минем йөрәгем.

Шаһтау сыман кинәт юкка чыга
Күпме өмет, күпме хыялым.
Тузган тауны, кипкән дәрьяларны
Җирдә көч юк кабат җыя алыр.
Торатауның итәгендә торам,
Оча болыт канат тигезеп.
Әрлән сыман заман җир кортлары
Кимерәләр тагын нигезен.

Күкне тишеп җәһәннәмгә юллый
Эз калдырып төрле очкычлар.
Тау язмышы — үзе таудай кайгы,
Җирне, күкне уйлап кот оча.

Итәгендә торам Торатауның,
Күгем бетеп бара тишелеп.
Син дә аусаң, терәкләре бетеп,
Төшәр сыман җиһан ишелеп.

## Чөнки

Чөнки минем вакыт үтеп бара,
Чөнки тиеше дә бетеп бара.

Чөнки бушка сөйләр хәбәрем юк,
Чөнки үземнән тыш хәлләрем юк.

Чөнки эчкән суым хәрәм булыр,
Чөнки әйткән сүзем әрәм булыр.

Чөнки сөю сүзе яңгырамый,
Чөнки аны аңлый аңгыра да.

Чөнки сөймәгәнгә сөйкәлмиләр,
Чөнки өймәгәнгә өйкәлмиләр*.
Чөнки тормышымның юк кызыгы,
Чөнки күзең кызар юк сызыгы.

Чөнки кояш китте баешына,
Чөнки төшендерде аешына.

## Мин — тоткын

Кайгырып әйтмим:
Чынлап та мин — тоткын.
Янымдагы сакчы
Шулай каты тотсын.

Яшәргә тиешмен
Чит-ятка карамый;
Елмаеп китүләр
Ул күптән ярамый.

Чыкмаска уң якка,
Сул якка чыкмаска,
Һәр уен хупларга,
Бер сүзен екмаска.

Тормышым үзенчә
Булсын әйдә төрмә.
Шушы тоткынлыктан
Тик коткара күрмә.

*** * ***

Инде бетте, син бит шуны көттең,
Тик артымнан чыгып чакырма.
Мин бит берни ишетмимен хәзер,
Пышылдама яки акырма.

Ни кыланма, берни күрмимен дә,
Үткәннәрдән — нәфрәт яңгырау.
Күңелемдә хәзер бернәрсә юк,
Дөм сукырмын, гүя саңгырау.

*** * ***

Аңламыймын, язмыш кая сөйри,
Шатлыгы юк, арта яралар.
Ни аерма бардыр, бер үк кайгы
Җирем белән минем арада.

Таулар чүгә, сулар корый һаман,
Мең сәбәп бар күңел сүнәргә.
Җирем белән мәңге береккәнбез,
Ни күрсәк тә бергә күрергә.

* * *

Һәммәсе дә бу дөньяда
Күз ачып йомган ара.
Бернәрсә дә кире кайтмый,
Күпме ялынып кара.

Менә хәзер очам дисәң,
Канатлар каерыла.
Кавышыйм диеп барганда,
Юл читкә аерыла.

Көллесенә дә күнегеп,
Минут та гасыр бара.
Тик мәхәббәт нигә шулай:
Күз ачып йомган ара.

## Үзебезнең абыйлар

Һәрнәрсәдән аралыйлар,
Әйтерсең без — сабыйлар.
Читкә бассаң, күреп тора
Үзебезнең абыйлар.

«Кыеш әйтмә, үлчәп сөйлә!» —
Өйрәтә, арымыйлар.
Һәр сүзеңә күз-колаклар,
Һай, молодец, абыйлар!

Ярдәм көтеп авыз ачсаң,
Аптырашып карыйлар.
Үзеңнеке карасын, ди,
Үзебезнең абыйлар.
Соравыңны тыңлый алар, —
Гадидән дә гадиләр.
— Ярар... — ди дә оныталар,
Һай, молодец, абыйлар!

Олы эшләр хәл итеlә,
Читтә кала «малайлар».
Читләр түгел, читкә типкән —
Үзебезнең агайлар.

* * *

Бәхетле дә, бәхетсез дә түгел,
Чынлап менә шундый хәлдәмен.
Әйтәм моны ихлас уйлыймын да
Язмышымның төрле мәлләрен.

Бәхетлемен, дисәм, дөрес түгел,
Көн кайгысы җанда бетмәслек.
Бәхетсезмен, дисәм, һич хак түгел,
Нинди хыял юк соң көтмәслек.

## Саташумы?

Тәмуг җир өстенә чыккан бүген,
Оҗмах җир астында калган чак.
Тәмугларда үлгәч аласыны
Әле яшәгәндә алган чак.

*** * ***

Күзләр телдән артык сөйли,
Яшермәче күзеңне.
Бөтенесе аңлашылыр,
Әйтмәсәң дә сүзеңне.

Күзләр телдән артык сөйли,
Яшермәче күзеңне.
Мин күрермен, мин тоярмын
Йөрәгеңне, үзеңне.

Күзләр телдән артык сөйли,
Яшермәче күзеңне.
Күзләреңне күрми торсам,
Бирсен Ходай түземне.

## Ул берүзе

*Газим Шәфиковка*

Ул берүзе ничек тарта
Унлап кеше тартачакны?
Белеп бара иңнәрендә
Йөге тагын артачакны.

Ничек әйтә базнат итеп,
Берәү әйтә алмаганда;
Һәрчак алдан килеп чыга
Башка чара калмаганда.

Әллә күпме ил улының
Әйтер сүзе ир сүзендә.
Әллә күпме шәхес сыны
Нишләп аның берүзендә?
Тәвәккәллек кыла калса,
Була шаклар катарлыгы.
Искә төшә, сискәндереп,
Салаватлар батырлыгы.

Дертләтеп тә куя кайчак
Алдан күрү зирәклеге.
Хәтерләтә карашлары
Вәлидиләр зирәклеген.

Әйткән сүзе аткан уктай —
Шытар орлык чәчкәнлеге.
Әйтерсең лә дәвам итә
Бабичларның чәчәнлеген.

Өр-яңадан башлый, ярсып,

Башкаларның ташлаганын.
Утка керсен, суга керсен —
Ташламый ул башлаганын.

Әллә күпме ил улының
Әйтер сүзе ир сүзендә.
Әллә ничә шәхес сыны
Нишләп аның берүзендә?

Күз алдымда балкып китте
Тик бер җавап — гүя ялкын:
Барыбыздан ул ныграк
Сөя бүген җирен, халкын.

* * *

Бөтен серләр ачыкланыр, дидем,
Бетәр араларда шикләр дә.
Бер карашың җуеп ташлар, дидем,
Җиткән чакта соңгы чикләргә.

Сине бүген аңлап бетеп булмый,
Күңелемнең тагын көе юк.
...Бөтен сере ачык хатын-кыз юк,
Бер гөнаһсыз гына сөю юк.

* * *

Адым саен шигырь эзләмәдем,
Адым саен шигырь язмадым.
Моннан адым саен зыян юктыр,
Адым саен юктыр ярдәмем.

Шигырь мине үзе эзләп табып:
«Менә хәзер утыр, яз!» — диде.
Өстәп аңа әрнү, сагыш куштым,
Монысы да әле аз иде.

Әрнеткәнне язам, зарланмыймын,
Кысыр көекләрне зар итеп.
Язсам язам башка чара юкта,
Тик язмыймын юкны бар итеп.

* * *

Яшьлектәге савапларга торыр
Гөнаһларым соңлап аклансын;
Соңгы кием, соңгы сумым бетсен,
Егетлегем генә саклансын.

Күгем — сирәк аяз, тагын-тагын
Кара болыт белән каплансын;
Күкләремне үзем балкытырлык
Егетлегем генә саклансын.

Намус — таза. Намуссызның кайчак
Зур гаебе белән таплансын;
Шуны күтәреп тә, акланырлык
Егетлегем генә саклансын.

Көтмәгәндә тәгам ризык бетеп,
Бер тамагым ачка каклансын;
Шул чакта да берни сиздермәслек
Егетлегем генә саклансын.

Белеп булмый, ярым ташлап китәр,
Мине хурлап, үзе пакьләнсен.
Эчтән янып бетеп, күрсәтмәслек
Егетлегем генә саклансын.

*** * ***

*Әсгат Мирзаһитов истәлегенә*

Мондый югалтудан, бу кайгыдан
Чаралар юк безне аралар,
Илем таянырлык ирләр ава,
Ауган сыман кинәт кыялар.

Син кыядай тордың бу тормышта,
Давылларга ачып күкрәгең.
Җирең белән бергә тетрәдең дә,
Күгең белән бергә күкрәдең.

Безнең мәңге йөрәкләрдә калыр
Кыяларга тиңдәш бар сының.
Тик хакыйкать өчен яшәдең дә,
Тик хакыйкать өчен ярсыдың.

Син кыясы булдың саф намусның,
Син кыясы булдың ирлекнең.
Нинди алышларда җиңеп чыгып,
Бүген әллә нишләп сөрлектең.

Кыя сыман ирләр белми хәтта
Кайсы җирдә килеп таясын.
Ләкин күз алдында мәңге торыр
Саф намуслык, ирлек кыясы.

*** * ***

Балачакның ерак хатирәсен
Һич алмыймын искә уеннан.
Имеш, мине алып кайтканнар
Күршедәге генә коедан.

Карадык без күрше малай белән,
Ышанып та бетми күбенә:
Суда шәүләм иде — мин коеның
Карап тора идем төбеннән.

Шулчак күрше малай ни уйлаптыр
Төкерде бит сәер төс белән;
Аның төкерегә эчәр суга —
Барып төште минем өстемә.

Җирдә күп су кичтем, күп су эчтем,
Аңлашып та бетми үземә:
Нинди суга төкерсәләр хәзер,

Төкерәләр кебек йөземә.

## Язмышыбыз

Тормыштагы хәлме төшкә керә,
Туры килер икән шултиклем:
Чыгып китеп булмый — капка бикле,
Өйгә кереп булмый — өй бикле...

## Туксанбай

*Мифтахетдин Акмуллага*

Без ярлыдан түгел, тик шулай да
Баерга дип килдек, Туксанбай.
Бөлеп калырмын дип аптырамый,
Каршыладың безне уфтанмый.
Синнән алган саен тик өстәлә,
Алган саен арта байлыгың.
Ымсындырмый безне бер көнлеге,
Атналыгы, хәтта айлыгы...
Без тормышка ут алырга килдек,
Гомерлеккә җитсен кузлары.
Белеп: ул чаткылар ялкын булып
Килер буыннарга юл алды.
Без баерга килдек, олы уттан
Алырга дип килдек бер күмер.
Тере эзләреңә басып бару,
Төягеңнән үтү бер гомер.
Алтыннардан артык акыл белән,
Яшьләр җыры белән барлы ул.
Туксан гына түгел, йөзләп байдан,
Меңләп байдан өстен ярлы ул.
Аклардан ак бөек исем белән
Түрләрең бай синең, тупсаң бай.
Тарих төпкеленнән киләчәккә
Иң зур байлык илтә Туксанбай.
*** * ***

Аңламассың инде бу дөньяны —
Башың ват син гомер буена:
Академик асылынып үлә,
Исәр мең яшәргә җыена.

*** * ***

Кая бакма кайный сүз боткасы,
Шаулашалар — тагын җыендыр.
Эштән качып шулай бер өйрәнгәч,
Сүз сөйләмәү инде кыендыр.

Аста нигез таркалырга тора,
Ун төрле эш тора, йөз тора.
Берәү эш таптырмый, эш сорамый,
Бөтенесе бүген сүз сорый.

* * *

Бөтен язмыш кыл өстендә тора,
Бөтен нәрсә бүген уй сала.
Беркем аптырамый, исе китми,
Кемдер кемне тотып суйса да.

Берәү берәүне дә яклап чыкмый,
Талanучы курка, бур — тыныч.
Нигә икән бүген көн өстендә
Яшәмәүдән яшәү куркыныч?!

## Үземә сораулар

Кем гаепле шушы бөлгенлеккә,
Кем гаепле шушы ачлыкка?
Барчасы да кем гөнаһы белән,
Килеп чыкты нинди хаслыктан?

Кем гаепле безнең ялгышлыкка,
Кем гаепле безнең хатага?
Кемгә генә аны сылтарга да
Нинди исем белән атарга?

Кемнән килә безнең түбәнчелек,
Кем гаепле түбән төшүгә?
Салкында да безнең януларга,
Көн битендә безнең өшүгә?

Каян килә шундый иман качу,
Каян килә рухи ярлылык?
Бик күпләрнең артык исе китмәс,
Баскан җире китсен ярылып.

Көннең ачылырын беркем белми,
Һаман, һаман өмет өзелә.
Безне әйдәр якты кайдадыр ул,
Җәйдән көттек, үтә көзе дә.

Бу сораулар әле соңгы түгел,
Мин барсын да сорап бетмимен.
Мин үземә-үзем сорау бирәм,
Беркемнән дә җавап көтмимен.

## Кыйгыда

Кыйгыларга килгән саен
Коелып төшәм инде.
Яшел җире — яшел келәм,
Зәңгәр күк — түшәм инде.

Яшел җир дә, зәңгәр күк тә
Юк түгел башка якта.
Тетрәнүләрем башкача,
Ымсыну түгел ятка.

Кыеп кына карап китә
Кызлары кыйгыларның.
Шуңа минем телсез калу,
Шуңа коелуларым.

Һәрбере үзенчә матур,
Үзенчә кыеп үтә.
Әллә үзе дә сизмәстән
Игътибар җыеп үтә.

Күзләре күктәй зәңгәргә,
Чәчләре карага да
Тәвәккәллекләрем җитми
Кыелып карарга да.

*** * ***

Һәммәсе дә кирәк. Бик тиз кирәк.
Кирәкләрнең иге-чиге юк.
Алгы юлда мең-мең киртә тора,
Арткы якка юлның биге юк.
Өметләре сүнә кешеләрнең
Шатлык, дисәң, беркем бүлмәслек.
Өсләренә кирәк — күренмәслек,
Өстәленә кирәк — үлмәслек,
Әле яңа гына күз алдына
Китермәдек мондый юклыкны.
Ил язмышы ялгышмыймы икән
Сыный-сыный безнең ныклыкны.
Ничек итеп шушы шартларда да
Һаман кеше булып калырга:
Бүген ничек өмет тудырырга,
Ышанычны каян алырга?

## Бөек көрәшче

*Әхмәтзәки Вәлидигә*

Бик күп көрәшләр күрмәстәйне
Берәү күргән дәвер башында.
Ерак тауга якынайган сыман,
Аның сыны үсә каршымда.
Көрәшенең күңел ярасыннан
Ярып чыккан шундый яктылык;
Челпәрәмә килеп кара төндә
Караңгылык калган ватылып.
Яктылыктан куркучылар шулчак
Котылганнар шашып-шаулашып.
Ә ул илдән киткән якалашып,
Халык, хаклык өчен даулашып.
Ә китмәсә, иң беренче иде
Башлар китәр утыз җидедә.
Шуңа аның хәтта туган җирдән
Китүе дә гафу ителә.
Ул башкортның иң баш көрәшче —
Алдан күрүчесе хак юлны.
Ә пычраклар күпме пычратмасын,
Асылда ул пакь һәм ак булды.
Урал сыртындагы таң йолдызы
Көрәшдәй күргән таңнарны.
Дәвер башыннан ук күзне ачып,

Мәңгелеккә борган аңнарны.

## Кадимге дус

*Кадим Аралбайга*

Була дуслар, антлар иткән була,
Кәеф-сафа корган мәлләрдә.
Авырлыклар килсә юк булалар —
Хәйләкәрләр алар, җәлләр дә.

Синең белән кәеф-сафа түгел,
Якынайдык уйлар корганда.
Үз фикерле һәркем өчен юлда
Адым саен киртә торганда.

Җан тартмаса, кан тартмыйдыр һич тә,
Җан да, кан да бергә тарткандыр.
Дуслар арткан саен тоябыз бит
Куәтебез янә артканны.
Артык якын җибәрмисең сыман,
Ләкин һич тә читкә типмисең.
Син үзең дә кереп бармыйсың бит,
Китәр булсаң, тиккә китмисең.

Бу тормышның йончу мизгелендә
Аерым да булдык, бергә дә.
Авыр чакта тоям, әйтерсең лә
Кадимге дус Кадим эргәдә.

## Елмаю

*Сафуан Әлибайга*

Йөзең гүя берни өчен түгел,
Тик елмаю өчен яралган.
Якты нурлар бар тоташы белән
Синең күзләреңнән таралган.

Битләрең дә синең түп-түгәрәк,
Кояш кына итеп куярлык.
Иртә әле шундый көн килергә —
Кеше елмаюдан туярлык.

Елмаясың әллә яшь аралаш,
Елмаясың әллә аптырап.
Сөйдерә дә, көйдерә дә тормыш,
Мең сорауга җавап таптыра.

Бу елмаю ничә еллар таныш.
Аңлагансың ничек яшьли син:
Сөмсереңне койсаң, нинди тормыш,
Елмаясың икән, яшисең.
Һәммәсе дә тоеп бетмиләрдер
Елмаюның төрле аешын.
Син елмайдың сыртларыңа еш-еш

Төшкәндә дә язмыш каешы.

Булган көнчелләрнең, кан дошманның
Ничек кенә йөзе карайсын,
Аларга да артык исең китми,
Тик елмаеп кына карыйсың.

Елмаюга дөнья мохтаҗ чакта
Кемдә генә нинди яра юк.
Бу чарасыз көндә — син беләсең:
Елмаюдан көчле чара юк.

## Көрәш келәме

Мин бу шигырьне Рәсәйнең халык депутаты Ю.В.Садыйков Кырмыскалы районының «Агыйдел» колхозы рәисе булып эшләгән чагында язган идем.

Син келәмдә һәрчак.
Тик әйтмимен
Эш бүлмәңнең йомшак келәмен.
Кырда, карда, ташта, туңган җирдә —
Алар йомшак түгел, беләмен.

Син — көрәшче,
Җиргә нык баскансың,
Каршы якта аны күрәләр.
Төрле яктан ташланырга сиңа
Ымлап тора көндәш түрә дә.
Алар белми
Пифагорлар, Платоннар язган
Көрәш тәмен, көрәш сәнгатен.
Ләкин мәкер белән көтеп тора
Уңайлы мәл, кирәк сәгатен.

Куандылар берчак илтеп тыгып
Тимер рәшәткәләр артына.
Әмма халык өчен янганыңа
Күтәрелде яше-карты да.

Чөнки синең, Антей сыман, җирдән,
Кешеләрдән алыр көчең бар.
Һәрчак тәгәрмәчкә таяк тыккан
Адәмнәргә гадел үчең бар.

Көн күрсәтмәс иде көндәшләрең —
Дәртләре бар, юк шул дәрманы.
Болай гына син бит бил бирмәдең,
Хаксыз килешүгә бармадың.

Аягың — нык җирдә.
Халкың яклый.
Теләсә кем җиңмәс егып та.
Алышларың бушка булмадылар,
Көрәшчене көрәш ныгыта.

## Төштә күргән Күк Бүре

Әкиятләрдә бүре коткарган бит,

Күпме сабый булса ташланган.
Әкиятләр дөрес булса, без бит
Шушы бүреләрдән башланган.

Әллә шуңа, әллә башка сәбәп —
Төшләремдә күрәм бүрене.
Ләкин ул бит әллә кая була,
Төшләремдә генә күренеп.

Күк астында мин сакаллы сабый —
Бер ташландык сыман тоямын.
Дүрт тарафтан дүрт күз белән көтәм
Җанны җылытырдай ояны.

Бәргәләнәм, суккаланам ялгыз,
Бер тын юк шул тирә-юнемдә.
Мин кычкырам сыман бар җиһанга,
Әллә чыкмый инде өнем дә.

Ничек котылырга шушы хәлдән,
Кем бар икән ничек йоларга?
Күк Бүрене эзләп, җан ачысы,
Әллә бүре булып уларга?

## Бер төркем иптәшләре

Зыянсыз, дип, бик кулай, дип,
Тапкандай шәп ишләрен.
Бер йолкышны күтәрделәр
Бер төркем иптәшләре.

Ымсынмас, дип, артыгына,
Булмас, дип, көндәшләре,
Колач җәеп каршылады
Бер төркем иптәшләре.

Монның эше гөрләп китте,
Буталды бит төшләре.
Кинәт менә уйга калды
Бер төркем иптәшләре.

Аның алга, баш бирмичә,
Китмәгәй, дип, эшләре,
Иплэп кенә таяк тыкты
Бер төркем иптәшләре.

Тешләсә — каты тешли, дип,
Яман, диеп, тешләре,
Арттан килеп тешен койды
Бер төркем иптәшләре.

Җайлап тәмам котылдылар,
Сытылгандай шешләре.
Төшерделәр кабергәчә
Бер төркем иптәшләре.

Әйе, күмеп тә кайттылар,
Акмады тик яшьләре.
Исем-атсыз кул куйдылар:
«Бер төркем иптәшләре».

* * *

Бала чакта көн дә исәпләдек
Кайчан бозауларын сыерның.
Көтә-көтә көтек булсак та без,
Вакыт кына кашын җыерды.

Бозауласа, башта бозау имде,
Вакыт җитми әни саумады.
Бозау белән без аякка бастык,
Авыз акка тигәч аумадык.

Инде хәзер күз ачылды дисәк,
Ябырыла юклык ян-яктан.
Илне төзүчеләр чиратларда
Егылырга тора аяктан.

Әле илем сыерлары кайда,
Әйтегезче шуны — инәләм.
Илне бүген бөтен имансызлар
Савым сыер кебек имәләр.

Буш вәгъдәләр, көн дә буш өстәлләр,
Ярдәм итмәс, беләм, бу җыр да.
Без тилмереп бозау көтәбез бит
Ничәмә ел кысыр сыердан.

* * *

Адым саен йөрәк сызлатырлык,
Шырпы сызсаң, дөрләп янарлык
Хәлләремдә, көзгеләрдән күрсәм,
Үз-үземне булмый танырлык.

Йөрәк кенәм тормыш утларында
Беткәндер, дим, янып-көйрәп тә.
Тоям кайчак — җаным-тәнем белән
Әйләнгәнмен гүя йөрәккә.

* * *

Мин түрдә дә,
Мин гүрдә дә булдым,
Эзе калып килә артымнан.
Атта җилдем.
Кайчак алдан килдем,
Байтак очып төштем атымнан.

Гомер сөрдем,
Инде күпне күрдем,
Җирдә күп нәрсәгә төшендем.
Ләкин гаҗәп: сине күргән көннән
Аермыймын өнне, төшемне.

## Сәхнә түгел, җир чайкалды

*Дөньяны тетрәткән мәшһүр биюче*
*Рудольф Нуриев истәлегенә*

Сәхнә түгел, җир чайкалды...
Бетте бию. Төште чаршау...
«Рудольф!» — дип уф иткәндә,
Бер минутка тынды бар шау.

Авыр сулап шушы мәлдә
Тынды дөнья, тынды алкыш.
Шаккатыргыч бар дөньяны
Тере яшен сүнде балкып.

Утлы яшен иде гүя,
Егет иде чаялардан.
Атылды ук чал Уралдан,
Болыт йөзгән кыялардан.

Тере яшен бөркет иде,
Каны бөркет токымыннан.
Шуңа чыгып очкандыр да
Чикле иҗат тоткынынннан.

Белде микән тоташ дөнья
Бөркет нәрсә уйлаганын?
Ташый бөтен тамырлары
Халкы каны уйнаганын.

Бу биеклек, бөеклеккә
Тартмагандыр аны дан да.
Кем соң тойды бу очышның
Кабынганын шушы каннан.
Париж, дөнья сәхнәләре
Алкышлардан дер селкенсә,
Аның бию-очуының
Тавышыннан җир селкенсә,

Тик шул гаҗәп: үз илендә
Аны аңлар аң булмады;
Йолдыз булып атылганчы
Аңа хаклы сан булмады.

Бөлгенлекне һәм байлыкны —
Бу дөньяда барын күрде:
Түбәнчелек, бөеклекне,
Тупсаны һәм иң-иң түрне.

Инде хәзер аның санга,
Аның данга мохтаҗы юк.
Иң югары йолдызлыкта
Аның инде юк таҗы юк.

Булды теле — бию теле,
Каны исә — халык каны.
Ә исеме, Урал сыман,
Тотып калды дөнья данын.

* * *

Нигә әле миңа акланырга,
Нигә кирәк, нинди пычагыма?
Әйтерсең лә бары мин гаепле
Бу дөньяның бөтен пычрагына.

## Илленче җәй

Илленче яз,
Илленче җәй килә,
Нигә икән шулай ашыга?
Аларны һич сагынып көтмәсәм дә,
Үзләре үк килә каршыга.

Көткән язлар, көткән җәйләр булды,
Алар инде артта калдылар.
Тик аларны тагын хәтерләдем
Бу илленче җәем алдыннан.

Сөю, нәфрәт, яну, туңу анда,
Абынулар, җавап-сораулар.
Уйда вакытны да узганым бар,
Торып калганым бар олаудан.

Бәхет байтак якынлашып куйган,
Тик борылган капкам төбеннән.
Бәлки, шулдыр бәхет дигәннәре,
Кирәкмидер өмет күбенә.

Күпкә өметләнеп, аздан калып,
Яшәве дә түгел күңелле.
Йөрер юлың, эшләр эшең арту
Үзе олы бәхет түгелме?

Үз язмышың түгел, җир язмышы
Төшләреңне бүлеп уяту:
Таңда өзгәләнгән моңлы кошлар
Инде тирәнрәк уйлату...

Бүген бары сагыш — сагышлырак,
Нәфрәт нәфрәтлерәк тоела.
Матурлыкка гына шул ук караш:
Әүвәлгечә ихлас тойгылар.
Вакыт кына әллә кая оча
Күзне ачып йомган арада.
Бер карасаң, таллар яфрак коя,
Бер карасаң, яфрак яралар.

Җәйләрендә җәйрәп китеп булмый,
Бик язылып булмый язында.
Җылы кими барган мизгелләрдә
Күп күрәбез инде азын да.

Көннәр салкынлыгы берни түгел,
Елаганда күңел мизгеле.
Әллә нигә кеше аралары
Салкыная сыман сизелеп.

Елларны да җылытырга кирәк,
Һәрберебез җылы өләшеп.
Дөрләсеннәр йөрәк ялкыннары,

Бер-береннән ныграк көнләшеп.

Туар көнгә изү чишеп барам,
Узганнары шулай өйрәткән.
Куган юлым — бөтен булышымнан,
Әйтер сүзем — бөтен йөрәктән.

## Утыз сигезләр

*Равил Бикбаевка, Тимер Йосыповка*
*һәм башка каләмдәш чордашларыма*

Бик-бик шанлы елны туганнар күп,
Ә без менә — утыз сигезләр.
Авыр бәхет белән тигезләр дә,
Бәхетсезлек белән игезләр.

Авыр бәхет, дидем, авыр алып,
Мин кузгатсам йөрәк ярасын,
Кем ышанмый, артка бер борылып,
Безнең туган елга карасын.

Кыраулары илне кырып үткән
Мең тугыз йөз утыз җиденең...
Нинди исәп белән исәпләнә,
Илем, синең үксез ятимең!

Җир тетрәгән, күк күкрәгән еллар,
Ил иңрәгән, еллар сыгылып.
Тарих аны бүген сөйләп бетми,
Тамагына төер тыгылып.

Шул кыраудан, шул кыраудан соң да
Корымаган халык тамыры.
Ләкин әле озак, күп көттерде
Шифа булыр хаклык яңгыры.

Кыраудан соң чыккан үсентедәй,
Шундый мәлдә җиргә килгәнбез.
Кан-яшь эчләреннән калкынганбыз
Яңа шытым булып илгә без.
Без чак кына буын ныгытканда,
Сугыш уты җирне ялмады.
Аксакалдан сабыйларга хәтлем
Шушы ялкын җитми калмады.

Күпме утлар безне яндырды да,
Күпме суык безне туңдырды!
Күз ачылды, дисәк, күз томалап,
Торгынлыгы иңгә тондырды.

...Әл дә заман кинәт сискәнде дә
Үз гаебен үзе таныды.
Көн ачыла, кешегә сан кайта,
Яңартыла тормыш кануны.

Без дә ирләр арасына кердек,
Ирләр булдык инде нигездә.
Бик-бик шанлы елда туганнар күп,
Ә без инде — утыз сигезләр.

## Йоклау һәм йокламау

Канауларда, койма буйларында
Йоклый ирләр, йоклый егетләр.
Бер кайгысыз, үлеп йоклый алар,
Хушбуй сыман аңкый дегет тә.

Өйләрендә көтеп алалмыйлар,
Урыннарны кат-кат түшәп тә.
Озын төннәр буе, йоклый алмый,
Яшь хатыннар дулый түшәктә.

## Телсез таулар...

*Чернобыль хәбәре*

Гарасатлы шартлау тавышыннан
Бөтен дөнья, җиһан дертләде.
Кешеләрнең йөрәкләре белән
Бергә җирнең җаны тетрәде.

Күпме-күпме асыл ирләр китә,
Исемнәре тере калырлар:
Җирдә бурычларын онытмаска,
Оран итеп искә алырга.
Тагын хәбәр: җирне җирләгәннәр,
Җирне казып җиргә күмгәннәр...
Җирем, моны ничек кичерәсең,
Күпме авырлыкка күнсәң дә.

Җир хәленә кереп үрсәләнәм,
Тагын шул хәбәрне алгач та.
Күз алдыма килә телсез таулар,
Акылыннан язган агачлар...

## Тик бер кабат

Сөю сүзен әйттем сиңа,
Мине тоташ алгач чорнап.
Әйттем аны тик бер сиңа,
Мең кат түгел, тик бер кабат.

Йөрәгемнең иң саф хисе
Бәреп чыкты — изге набат.
Бердәнбер ант күп әйтелми,
Әйтелә ул тик бер кабат.
Минем гомер — утлы күмер.
Башкаларга тик бер сабак.
Без киләбез бер дөрләргә,
Артык түгел, тик бер кабат.

## Ялгыз түгел

Төягемнең таңы борынлаган
Серле-могҗизалы бер мәле.
Челтәр-нәкышенә күз чагыла,
Сүз башласаң, телең көрмәлер.

Илгәзәк җил ни эшләргә белми,
Кыймый гына кага аркамнан;
Җанга рәхәт шулчак — җайлап кына
Галәм ихласлыгы арткандай.

Таңгы кошлар тора берәм-берәм,
Сак моңнары өзә үзәкне.
Һәрчак хәйран калам таң тууның
Хозур мәлен түзми күзәтеп.

Шаулап торган кичтә ялгыз идем,
Әле менә ялгыз түгелмен.
Тоташ дөнья белән тоташкандай,
Канатлана бара күңелем.

Әйтерсең лә менә бер-беребезнең
Хәлләренә белеп кергәнбез.
Галәм каршысында ялгыз түгел,
Җирем белән икәү бергәбез.

## Кешеләргә чыгам

Эчем пошып китсә,
Гел урамга,
Кешеләргә чыгам сагынып.
Анда һәрчак, тере китап сыман,
Шаулап торган халык агымы.
Шул агымга килеп кушылырга,
Шул агымда бергә агарга
Мин җилкенеп чыгам,
Җил иркеннән
Күңел басар азык табарга.
Балку күрсәм кеше арасында,
Күрсәм шатлык кеше йөзендә,
Канатланам алар белән бергә,
Шушы шатлык гүя үземдә.
Моңсу йөзләр йә кайгылы күзләр
Ара-тирә калса чагылып,
Күтәрәсе килә күңелләрен,
Искән җилдәй генә кагылып.
Ләкин бары алай ансат түгел,
Җиңел түгел дөнья йөкләре.
Бара кеше бер иңендә — шатлык,
Бер иңендә кайгы күтәреп.
Эч пошуы нәрсә,
Кайтып керәм,
Яңа уйлар белән тулышып.
Җаннарыма җаннар өрә һәрчак
Кеше тыны, кеше сулышы.

## Уклыкыя

Син югалгач, кинәт олыгайдык,
Гамьсезлекләр, инде хушыгыз.
Һәрчак истә:

Намус күзе булып
Безгә карап тора дустыбыз.

*Ә.Вахитов*

*Сокланргыч укытучым һәм остазым*
*Әнүр Вахитов истәлегенә*

Туган төягеңне гизгән чакта,
Тик син булдың безнең уйларда.
Яшәгәндә син бит утта булдың,
Читтә булдың бәйрәм, туйлардан.

Уклыкыя каршысына бастык,
Баскан сыман синең каршыга.
Күз иярми узган гомер кебек,
Әллә кая җилем ашыга.

Янартаудай эчең тулы утта,
Эчтән яндың, тордың кыядай.
Йөрәгеңдә уклар, утлар булды,
Әй, ирләрне язмыш аямый.

Хәтерләтә давыл әллә нигә
Кыяларга аткан укларны.
Очып барган укны белеп булмый,
Кемнең йөрәгендә туктарны.

Кырыс кыя сыман чакларыңда,
Аңлап бетмәгәндер кайсылар.
Сине ничек кырыслатмасыннар
Ябырылган кара кайгылар.
Кыяга ул нәрсә! Кешеләргә
Агулы ук арттан атыла.
Күтәргәндә синең күтәргәнне
Аунап китәр иде аты да.

Горур Уклыкыя тагын-тагын
Хәтерләтеп куя төсеңне.
Таулар кадәр эшләр аткарганда,
Шул кыядай булган өчендер.

Син күтәргән безнең иңгә төшә,
Язмыш безне шулай өйрәткән.
Синең йөрәгеңнән суырылса да,
Шул ук хәзер безнең йөрәктә.

## Йөргенчеләр сыман

Якташларым — Кырмыскалы районы Бекетово авылы крестьяннары — йөргенчеләр А.Шапошников, Т.Кондров, И.Кондров 1921 елгы ачлыкта Мәскәүгә В.И.Ленинга киңәшкә барган.

Шаулы тормыш бүген, даулы тормыш —
Тиз калырга мөмкин газапта.
Акыл килер берчак барысына,
Тик соң булыр сыман азактан.

Чабаталы данлы якташларым,
Хәтеремә шулай сеңешкән:
Илне борчыр сорау белән алар

Барыр кеше тапкан киңәшкә.

Шушы якташларым алдан сизгән
Басып килер афәт-ачлыкны...
Җиргә бүген әллә ниләр килә,
Тик без генә соңлап ашыктык.

Илдә, бәлки, андый ачлык булмас,
Бүген күпләр туеп сикерә.
Рухи ачлык, уйламаган хаслык
Көтелмәгән мәхшәр китерә.

Җайлап җирдә оҗмах көткән чакта,
Ашыккандай заман ахыры.
Һәрбер көннән якты көтә-көтә
Көтек була адәм бахырың.

Көн белән төн буталгандай булса,
Алла белән иблис — куштанда;
Ак, каралар бердәй бәһаләнеп,
Хак, нахакны бергә кушканда.

Сулар һавам һава булмаганда,
Су булмаса эчәр суларым,
Бер сорауга җавап бирә алмый,
Торган чакта кояш бузарып,

Язмышыбыз, диеп, юлдан яза,
Бу дөньям, дип, нигә тарыган!
Киңәш сорап кемгә йөрергә соң,
Ярдәм сорап кемгә барырга?

Шаулы тормыш бүген, даулы тормыш —
Тиз калырга мөмкин газапта.
Акыл килер берчак барсына да,
Тик соң булыр сыман азактан.

Бер сорауга бер җавап та юктай,
Бер карасаң, бөтен ил уңай.
Шундый чакта соңгы йөргенчедәй
Йөгерердәй булам Ленинга!

## Дәүләкән

Ул түбән дә, ул биек тә —
Ярым агач, таш кала.
Бу хакта күп әйтелгәндер,
Әйе, миннән башка да.

Агач аны һич төшерми,
Күтәрми тик таш кына.
Иң мөһиме — ул шул килеш
Киләчәккә ашкына.

Бар тарафка, күз тимәсен,
Яхшы ягы тарала.
Тик хәерле чыккан хәбәр
Менә якын арада.

Һәркем белә дәрәҗәсен,
Чумган һәркем хезмәткә.
Вакыт кына чамалырак

Бөтенесен тезмәккә.

Иң сыйфатлы кирпеч хәтта
Дәүләкәннең комыннан.
Тел йотарлык калачлар да
Дәүләкәннең оныннан.

Кем бер кабат авыз иткән
Сырыннан йә маеннан,
Кабат килер, карап тормый
Көненә дә аена.

Балаларга матур ката
Дәүләкәндә тегелә.
Тик шунсы бар: иң затлысы
Китеп тора тегеләй.
Китсә китсен, илгә китсен,
Җитсен бөтен дәүләткә.
Һәммәсен дә җиткерергә
Тырыша бит Дәүләкән.

Агач булсын, таштан булсын —
Дим буенда тәү кала.
Дәү хыяллар икән анда,
Дәүләкән ул — дәү кала.

## Уфа вакыты

Төрле ерак якка барды юлым,
Әле күптер тагын барасы.
Киткән чакта сизелми дә сыман
Вакыт аермасы, арасы.

Яңа юлның, яңа сәфәрләрнең
Ачылмастай икән күп сере.
Вакыт аермасын үтеп булмый,
Бары сәгать кенә күчереп.

Ерак якның асыл сыйфатлары
Әле бетмәс элек ялкытып,
Әллә нинди исемсез көй булып
Чыңлый җанда Уфа вакыты.

Шуңа очып-канатланып кайтам,
Сагышларым кала түгелеп.
Уфа вакытына сәгать түгел,
Күчерелгән бөтен гомерем.

*** * ***

Төрле чаклар була, калкып тора
Әллә нинди тормыш таплары.
Каршы чыгып чират алган сыман
Дөньяның тик ямьсез яклары.

Андый мәлдә күңел әллә нишли,
Җирдә рәхәт юктай сизәсең.
Яшәүнең бер мәгънәсе калмый,

Хәтта үз-үзеңнән бизәсең.

Шунда кинәт бер матурлык балкый,
Чал табигать белән бирелгән.
Дөрләп китә шулчак яшәү дәрте,
Матурлыкны күреп тереләм.

*** * ***

Мин үтәлмәс вәгъдәләрдән туйдым,
Туйдым аны үзем бирүдән.
Бушка саташудан, хатлашудан,
Юкка өмет өзми йөрүдән.

Ялган сүздән, алдау күздән туйдым,
Кул чабудан моңсыз җырларга,
Беләм үзем, гафу итмәс сыман
Шаһит айлар, шаһит еллар да.

Юкка янулардан күптән туйдым,
Көюләрдән кысыр көеккә.
...Сөю, синең белән әүвәлгечә
Мин түбән дә булам, бөек тә.
Җиңел-җилпе хыяллардан туйдым,
Сусаганга яңа яшьнәүгә,
Туймаганга күрә бу тормыштан,
Туймаганга күрә яшәүдән.

*** * ***

Су аккандай бик тиз ага гомер,
Яртылашы аның юлда үтә.
Кайсы яктан кайтып төшәремне
Нәни авылымда әни көтә.

Тыңлар өчен аның хак сүзләрен
Ашкынам мин төрле тарафлардан.
Күрү белән ул үтәдән-үтә
Аңлап ала мине карашлардан.

Җирдә кылганыма, булганыма
Аның рәхмәтләре иң зур бәһа.
Дөнья юлларында каушап калсам,
Һәрбер сүзе күз алдыма баса.

Әниемне кат-кат тыңлыймын да,
Тәү ишеткән сыман таңга калып,
Шуннан юлга чыгам, аның яңа
Фатихасын, рәхмәтләрен алып.

## Кешеләр җирдә балкый

Йолдызлар күктә яналар,
Кешеләр җирдә балкый;
Йолдызлар белән тиңләшеп

Балкырлар гомер бакый.

Җирне, дөньяны яктыртып,
Кеше балкуга күнә.
Ак көн туса, аяз күктә
Йолдызлар да бит сүнә.

## Яхшылык

Сәер сыман: нинди киң дөньяда
Кайбер юллар үтә тар сыман.
Бер карасаң, хәтта мөмкинлекнең
Мәңге бетмәстәе бар сыман.

Һәрвакытта, бөтен җирдә мөмкин —
Төнме, көнме, өйме,ураммы,
Җирме, очкан күкме, йөзгән сумы,
Җәйге чиллә, кышкы буранмы, —

Һәр минутта мөмкин — күпме теләү,
Көтеп торсын башка эше дә,
Кеше булган кешеләрдән һәрчак
Яхшылыклар көтә кешеләр.

Менә шуңа кичекмәстән һәркем,
Тик кулыннан гына килгәнчә,
Эшләсәче җирдә бер яхшылык,
Эшләсәче үзе белгәнчә.
Танышына, таныш булмаганга,
Көтмәгәндә, үзе көткәндә,
Бер яхшылык тисә, яманлык та
Бетә барыр иде беткәннән.

Эшләгез сез көн дә бер яхшылык,
Көткәннәрне мәхрүм итмәгез.
Сезне аннан беркем тыймаган бит,
Яхшылыкка рөхсәт көтмәгез!

*** * ***

Яхшылыгым — әниемнән,
Туган җирем, туган яктан.
Алар миңа һаман бирә
Киткән чакта, кайткан чакта.

Әнием дә, туган як та —
Чыганагы яхшылыкның.
Бирде алар бөтен нурын
Күңелдәге яктылыкның.

Яшермимен алганымны —
Алар бары таратырга.
Кеше үзе туган ягын
Яратырга яратылган.

Аңларлар, дим, мине тоташ,

Минем якта йөреп кенә.
Күреп туган җирләремне,
Әниемне күреп кенә.

## Аягөсте басып

Рәхмәт, мәктәп, башлап син өйрәттең
Мине аягөсте басарга.
Шулай туры басып якынлаштым
Дөнья асылларын ачарга.

Арта төште тормыш дәресләре
Соңгы кыңгыраудан соңрак.
Кайберәүләр сүнмәс ут кабызды,
Кайберәүләр булды туңрак.

Утырттты да алар, бастырды да,
Алар мине күпкә өйрәтте.
Вакыт җиткәч, аягөсте бастым,
Кулларыма тотып йөрәкне.

Аягөсте басып икмәк теләм,
Үзем яшәү җыры көйлимен.
Сөйләр сүзләремне посып түгел,
Аягөсте басып сөйлимен.

## Чарасыздан чарага

Нигә карадым сирпелеп
Кара сылу Сарага.
Йөрәгемдә уңалмаслык
Әйләнде бер ярага.

Басар өчен йөрәгемне
Табарга соң ни чара?
Күк астында үрсәләнәм,
Мин чарасыз бичара.

## Туган телем

Тел терелтә, тел илертә,
Телдән көчле чара юк.
Тел аңлатмас могҗиза юк,
Телләр үтмәс ара юк.

Шундый телем — башкорт теле —
Тиңгә-тиң дәүләт теле.
Халкым белән бергә туган
Меңләгән еллар элек.

Тел тамыры — ил тамыры,
Телем тамыры тирән.
Гүя нечкә гөл тамыры,
Аны белү дә кирәк.

Язмышыбыз — тел язмышы,
Беләм аның хакында:
Әгәр телем яши икән,
Яшәячәк халкым да.

**Чакырсаң**

Югалма күземнән, югалма,
Офыклар чакырсын, чакырсын,
Анда да син минсез юл алма.

Белмимен ниләргә тарырмын,
Чакырсаң шул җитә, шул җитә,
Артыңнан тәмугка барырмын.

Мин әзер янарга бергәләп,
Юк, син кал, янармын берүзем,
Тик син тор, тик син тор эргәдә.
**Яңа туган бала елавы**

Бу дөньяның иң зур сөенече —
Яңа туган бала елавы.
Тынып калсын ул чак шаулы кала,
Аягөсте бассын тын авыл.

Бу дөньяның иң зур сөенчесе —
Яңа туган бала тавышы.
Ул бит иртәгәгә оран салу,
Ул киләчәк белән кавышу.

Тавышларның иң-иң ягымлысы —
Яңа туган бала елавы.
Ул бит елау түгел, көлүгә тиң,
Бу дөньяга җырлап килә ул.

Әллә ничә тудым мин дөньяга,
Ничә кабат — беләм тик үзем.
Елар чакларда да еламадым,
Мин, күрәсең, шулай бик түзем.

Әйткән чакта тәүге сөю сүзен,
Мин дөньяга тудым яңадан.
Ул күзләргә карап, хәйран калып,
Килә алмый тордым аңыма.

Ташка басылганда тәүге сүзем,
Мин дөньяга тудым кабаттан.
Дустым хыянәте еккач мине,
Тагын тудым шушы сабактан.

Гел хәтерләп торам мин аларны,
Ишеткәч тә бала елавын.
Тыныч кала гүя шаулы кала,
Аягөсте баса тын авыл.
Тагын яшәү өметләре арта,
Җиргә яңа туган кот аша.
Бала туып, тәүге аваз белән
Заманнарга заман тоташа.

*** * ***

Бу юлдан, дим, кемнәр йөрмәгәндер,

Кемнәр генә килми уңасы.
Мин Бөрҗәнгә килгән саен телим:
Була күрмәсен, дип, соңгысы.

Йөрәгемә кабызырга киләм
Борынгымның сүнмәс ялкынын.
Мин Бөрҗәнгә киләм картәтиләр
Хаҗга барган сыман талпынып.

## Йөрәк синең белән

Бөрҗән инде минем белән бер җан,
Бергә булсын бөтен күрәсем.
Аның җырчы-хезмәтчесе булсам,
Ә ул — күңелемнең түрәсе.

Шатлыгымның олы-кечесенә
Түбәләрем тия күкләргә.
Бәлки, шулай тоеладыр да ул
Миңа гына түгел, күпләргә.

Сызлаулары — тоташ минем сызлау,
Яралары — минем яралар.
Кайнар сулышларын сизеп торам,
Әллә каян ятсын аралар.
Үткәннәре — минем узган юлым,
Иртәгәсе алда узарга.
Киләчәкне бергә китерергә,
Үтәр юлны бергә сузарга.

Беләм, әле хәлең җиңел түгел,
Кемгә генә әле җиңел соң?
Иртәгәсен соң булырга мөмкин,
Бүген тотынганда — түгел соң.

Мин җанымны кушарга да әзер,
Меңгә теленгәндә бер җаның,
Булган шатлыгыңда, бар кайгыңда
Йөрәк синең белән, Бөрҗәнем!

## Бөрҗән халкы

Бөтен илен ут алганда,
Ялмаганда җирен ялкын,
Йорты янган, җире янган —
Янмый калган Бөрҗән халкы.

Көтмәгәндә су ташканда,
Гарасатлы туфан калкып,
Малы аккан, йорты баткан —
Батмый калды Бөрҗән халкы.

Булгач һәрчак эше хаклы,
Хәтта аю аның яклы.

Бөҗәккә дә, аюга да
Хәстәр таба Бөрҗән халкы.

Яндырмаган аны ялкын,
Туңдырмаган аны салкын.
Утта янмас, суда батмас
Булып туган Бөрҗән халкы.

Күңелләргә үтә якын,
Үзе белә үзе хакын.
Үткәнең бар, көткәнең бар,
Яшә генә, Бөрҗән халкы!

## Заповедник

Безнең сүзлектә дә юк ул,
Югалтумы, әллә отыш.
Чөнки әүвәл минем җирем —
Заповедник булган тоташ.

Бүген инде шул җиремнең
Азы гына кала тере.
Кагылмаслык дип санала
Шул җиремнең меңнән бере.

Тиелмәскә дигән урман,
Йогынмаска дигән таулар.
Атылмаска тиеш җәнлек,
Корылмаска дигән аулар.

Чабылмаска дигән болын,
Йолкынмаска дигән үлән,
Якланырга тиеш мохит,
Сакланырга тиеш күләм —

Ул нибары меңнән бере,
Күз карасы кебек тора.
Карашлары ялварулы,
Чакыра ул ярдәм сорап.

Җан ачысы кычкырырлык
Хәлгенәсе аның бүген.
Берәү килеп иңен куймый
Күтәрергә олы йөген.

Таралыр да нинди коткы,
Заман җиле исәр кайда?
Күзе тонган дәүләт бүген
Һәрнәрсәдән даулый файда.

Отар өчен бер тиенне,
Югалта ул меңәр сумны.
Үз ботагын үзе чабып,
Нинди дәүләт кайчан уңды?

Уңай мәлне көтеп тора

Корган мылтык, зәһәр агу.
Җавапсызлык, битарафлык
Яманрак аннан тагын.

Бөрҗән җире, ничек итеп
Коткарырга соңгы котың.
Тавышымны кем ишетер,
Кычкырганда башым тотып?

## Шүлгәнгә кергәндә

1989 елның 30 августында Мостай Кәрим, Муса Гали, Динис Бүләков, Равил Бикбаев, Факиһә Тугызбаева, Таңсылу Карамышева, Әхмәт Сөләйманов һәм башка дус-танышлар Шүлгән мәгарәсенә кердек.

Керәм иң борынгы картәтәмнең
Ходай үзе биргән куышына.
Ыруымның якты дөньяларга,
Бәлки, ул шаһиттыр тумышына.

Укып керәм белгән догаларны,
Ходай ачып куйган ишегеннән.
Күз салыйкчы әле мәңгелеккә —
Ыруымның серле бишегенә.

Сабыр сулышлары борынгының
Килеп бәрелсеннәр йөзләремә.
Меңьеллыклар, ерак төштәй булып,
Бер салынып калсын күзләремә.

Юлда — эре ташлар, юеш балчык —
Бара торгач, дисәк, кимер мәллә.
Алтын сарай түгел алдыбызда,
Мәгарәчә тормыш мәгарәдә.

Адым саен аптырашлар арта,
Баш очыма караш ташлыймын да.
Нинди серләр саклаunion икән
Каткан меңәр еллык таш маенда?

Гасырларның бәгырьләре каты,
Күпне туңдырганнар, яндырганнар.
Мәңге көн күрмәгән Шүлгән күле
Кемнең тансыкларын кандыргандыр.
Алар гына түгел башны ваткан,
Ул гына да түгел могҗизалар.
Мең сораулар һаман җавап тапмый
Ничә гасыр инде җир гизәләр.

Бу рәсемнәр ничек төшерелгән,
Нинди буяу, кемнең каны белән?
Аңлап бетә алмый әле заман
Тик бүгенге генә аңы белән.

Монда тәмуг, әллә оҗмах булган —
Бөтенесен бары Алла белә.
Анда эшләнгәнне бизмәннәргә
Тик мәңгелек кенә сала белә.

Мәңге сере бетмәс бу дөньяның,
Бездән соңнар белсә беләчәкләр.
Күңелемне нигә бердәй борчый

Тәү тормыш та бүген, киләчәк тә.

Исен иснәп чыктык мәңгелекнең,
Мәңгелектә торып калмасак та,
Әлегә без аңа берни салып,
Аңа берни өсти алмасак та.

Очраштык бер без мәңгелек белән,
Үкенечләр кимер үлгәндә дә.
Җир хәтерен мәңге тере тотар
Эзләр кала Бөрҗән, Шүлгәндә дә.

## Сыймыйча сәхнәләргә

*Кабатланмас кеше һәм җырчы*
*Гыйльман Сәфәргалингә*

Синең җырың яңгыраса,
Сыймыйча һич сәхнәләргә,
Агыла ул күк тауларга,
Агыла ул сәхрәләргә.
Ягыла ул искән җилгә,
Ягыла ул үләннәргә.
Кагыла ул кыяларга,
Сарыла ул үзәннәргә.
Хуш килгәндәй болыннарда
Бал исләре аңкуына;
Яшь боланның чакыруы,
Бөркетләрнең чаңкуына.
Шуңа таулар монда изри,
Шуңа болыт монда йөзә.
Синең тавыш моңы микән,
Җир үземе — үзәк өзә.
Анда — дөнья фанилыгы,
Анда — яшәү куанычы,
Бөрҗәннең бар сызлануы,
Бөрҗәннең бар юанычы.
Тетрәткеч моң тирә-юньдә,
Шундый аваз сулда, уңда.
Аягүрә торган сыман
Тоташ Бөрҗән синең моңда.

## Инсебикә кыясы астында

Инсебикә сылу, язмышыңа
Башым иям кыяң астында.
Әллә нинди хисләр җанны телә,
Текә ярга аяк бастым да.
Сирәгәеп беткән карагайлар,
Корып бетеп барган урманнар...
Кинәт кенә сының агач булып:
— Уйланыгыз! — диеп торгандай.
Идел буйлап күпме кыя булса,
Аннан очкан күпме карагай.
Шуңа микән горур кыялар да
Суга башын иеп караган.
Карагайлар Инсебикә сыман,
Нәкъ шулай ук алар язмышы.
Мал артыннан куып, иртә кисеп
Урман кырылуы азмы соң?
Синең гәүдәң әллә кая аккан,

Шаһиттыр тик Идел күбеге.
Карагайлар агып китә алмый,
Су төбендә ята күбесе.
Сылу кыздай матур карагайлар
Сизми кала, авып китәләр.
Заманының төрле фәрманнары
Сикерергә мәҗбүр итәләр.
Инсебикә сыман Агыйделгә,
Япь-яшь көе җанын аямый,
Тезелешеп дистәләрчә еллар
Карагайлар оча кыядан.

## Яндырылган Алдар авылы

Астындагы ияр атка тияр,
Ияре дә белмәс, ат белә.
«Тәфтиләү»нең кылган, ай, каһәрен,
Үзе белмәсә дә, ил белә.

*Халык җыры*

Йөрәгемдә көйрәп янып китте
Алдар авылының ялкыны...
Ике йөз ел элек ут алса да,
Йөрәккәе яна халкының.

...Әтек эргәсендә күрсәттеләр
Шул авылның янган урынын.
Шулчак кинәт төсе бетте көннең,
Көче бетте кояш нурының.

Йөзәр еллап үткән, өй салынмый,
Йөзәр еллап кеше утырмый.
Йөзәр еллап ай моңаеп баткан,
Авыл исәпләрен тутырмый.

Сабак булсын диеп калганнарга,
Сабак булсын диеп күп чорга,
Рәсәй патшасының вәхшиләре
Алдар көлен күккә очырган.

Үчен алган алар төп башкорттан,
Калган болаларны басарга.
Ник курыккан алар батырның
Тик берүзен тотып асарга?

Ыру гөмбәзендә йолдыз ише
Алдар Инсәгилде гомере.
Мең ел аша дөрләп китәр сыман
Сүнгән авылының күмере.
Хәзер ничек болганса да дөнья,
Үзгәрсә дә ничек кануннар,
Алдар каны һаман ярсып ага
Бөрҗәннәрнең кайнар канында.

Кырык төрле уй үтеп китте баштан,
Йөрәккенәм кискен туралды.
...Яшьтәш урыс шофер җырлап бара
Башкорт халкы җыры «Урал»ны...

## Урманның аюларга эндәшүе

Бу урманда сездән акыллы юк,
Аң булыгыз әле, аюлар,
Яшисез сез чама белеп кенә,
Кирәк түгел сезгә баю да.

Ике аяклы аюлар күп хәзер,
Төпкелләргә юллар яралар.
Алар безне ялан итеп үтәр,
Алар һаман төпкә баралар.

Алар кызган, ак-караны күрми,
Күзе тонып, килә сыпырып,
Җаен тапса, тере көе сезнең
Тунызызны алыр сыдырып.

Кайберсенә сабак булыр иде,
Күкрәк киереп чара күрсәгез,
Балталарын ташка чабып ташлап,
Мылтыкларын бөгеп бирсәгез.
Аларны бит шулай барын кырып
Йөртми бит һич дөнья нужасы.
Әй, аюлар, бүген сез йокламый
Булсагызчы урман хуҗасы.

## Аптырап калма, дустым!

Аптырап калдым, әллә ни югалтып,
Әллә ниләр кинәт тапкандай.

*С.Габидуллин*

Бердәнберең туган, торган җирең
Адым саен хәйран калырлык.
Һәр төбәге аның искитәрлек,
Ләкин түгел күзең талырлык.

Ничә кабат карап үтеп киттек
Көндез болыт кунган Базалны.
Кичен аңа безнең күз алдында
Күпме йолдыз килеп кадалды.

Адым саен, әйе, адым саен
Һич тә кабатланмас тамаша.
Уйлап торсаң, уелып китәрлек,
Карап торсаң, күзләр камаша.

Буяу төсе җитмәс күчерергә
Төягеңнең асыл бизәген.
Кагылмасын аңа җир иңләгән
Матурлыкны кыру бизгәге.

Урманыңнан кошлар бизмәсеннәр,
Агачларны саксыз аударып.
Ишелешеп төшмәсеннәр кинәт
Һәр кич йолдыз кунар тауларың.
Бүген, дустым, шундый оран кирәк

Шушы хозурлыкны якларлык.
Шуннан кинәнүне кайтарырлык,
Шунда яшәүләрне акларлык.

Шундый сүзләр табар мәлең синең,
Йөз елдан соң ятлап алырлык.
Югалтудан түгел, шул табыштан
Хәтта үзең хәйран калырлык.

## Нокытчыга* килү

Мин төшемдә нокытчыга килдем,
Аның кырык бер ташы ни әйтер?
Өмет гөмбәземне күтәрерме,
Офыгымны, бәлки, киңәйтер.
Нигә әле хәтта Бөрҗәндә дә
Шик-шөбһәләр керә төшемә?
Өндә өнәп бетмәгәнне әллә
Төшләремдә күреп төшенәм.
Кыя-ташлар кайгыларда сыман,
Уйга баткан сыман урманнар.
Беләм, кыя булып калыкмадым,
Урман сыман озак тормам да.
Хыялымны әмма чынбарлыкка
Бик яшисем килә ашырып,
Һәм китәсем килә торган җирне
Ышанычлы кулга тапшырып.
Нокытчыга нокыт сөйләү яттыр,
Дөрес булыр, бәлки, юравы.
Төшемдә дә өндәй күрер идем
Җавап ала күрсә соравым.
Мин ялынып әйтәм, минем түгел,
Әгәр көчең җитсә, нокытчы,
Җирнең күрәчәген, киләчәген
Күзләремә карап укып чык.

## Узган гомер

Бабсак кабере янында танылган курайчы Мөхәммәт Кадергулов агай «Узган гомер»не уйнады.

Яңгыравы белән тәүге өннең,
Телгә килү белән курае,
Күк үләннәр башын түбән иде,
Карагайлар куйды тураеп.

Сайрар кошлар кинәт ялга тынды,
Баш өстендә болыт тукталды.
Бөтен дөнья аңа багып калды,
Күрше таулар аңа укталды.

Узган гомер... Тузган күмер түгел,
Очкыннары сүнеп бетмәгән.
Үткәннәрнең хәтер үкенече
Кемнең хәтерләрен өтмәгән.

Нинди генә юллар үтелмәгән,
Тыңланмаган җырныңниндие.
Хәтерләрне шулай тетрәткәне,
Сирәк насыйп була синдәе.
Монда юл елъязмасы түгел,
Рухым елъязмасы яңгырый.
Оемыймын моңнар дөньясында,
Уйлар дулкынында каңгырам.

Онытылды дөнья аны тыңлап,
Башларына мең төр уй ятып.
Яшә, курай, яшьнә борынгы моң,
Заман хәтерләрен уятып.

## Алты яшьлек җырчы кыз

Байназарда безне шаккатырды
Алты яшьлек кенә кыз бала.
Менә шушы кошчык шундый җырлый —
Гүя ил анасы сызлана.

Алтмыш яшьлек кеше уйланырлык...
Яшь кенәсе аның алтыда.
Шатлыгымның очы-кырые юк,
Тик күземнән яшем атыла.

## Бабсак батыр каберендә

Кабер ташына «Ыруыбыз башлыгы Бабсак бигә. Кыпчак халкыннан» дип язылган.

Үзе бер тау сыман тора
Бабсак батыр кабере.
Андый пәһлеваннарның
Җирдә хаклы кадере.

Без борылдык юл уңае
Туктап башны ияргә.
Кабер өсте — шау мәтрүшкә,
Моңа нәрсә дияргә?

Чәчкә салдык — сәбәп инде
Без туктауны аклауга.
Гаҗәпләндек кабер өстен
Мәтрүшкәләр каплауга.

Табигатьнең сереме бу,
Бу Алланың эшеме?
Туфрак, җилләр ничек итеп
Беләэ бөек кешене?

## Канатсыз да очып

*Биюче Рәуф Сиражетдиновка*

Ничек була шулай басып,
Була ничек биеп?
Йөрәктәге иң-иң нечкә

Тойгыларга тиеп.

Кинәт һәрчак гөлтләп китә
Торса күңел оеп.
Идән түгел, җир селкенә
Басканыңны тоеп.

Ничек кабыза ул сине,
Дөрли нинди ялкын?
Күзеңдәге очкыннардан
Китә дөнья балкып.

Җитезлектә китәр сыман
Яшь боланны узып.
Кирәк чакта чакыргандай
Тик кулларын сузып.

Хәтерләтеп биек күктә
Бөркет талпынуын,
Күк таулардан, бөркетләрдән
Өскә калкынуын.

## Таңгы чык кичкәндә

Таңгы чыклар аптыратты мине,
Салкын чыклар шушы таңдагы.
Төрле якта күпме чыклар кичтем,
Тик бу чыклар түгел андагы.

Бер карасаң, ул бит күз-яшь сыман,
Бер карасаң, салкын тир сыман.
Үзәк өзеп кошлар ни сөйлидер,
Таш кыялар — боек ир сыман.

Шул кыялар кеше күрмәгәндә
Елаганмы әллә егылып:
Меңәр яшьлек карт тауларның шулай
Кайгы яше чыккан сыгылып.

Әй, борынгы туфрак, жәл дә сыман
Йокың бүлеп сине таптавым.
Олы гөнаһ кебек — үзем куйган
Соравыма җавап тапмавым.

Таңгы саф чык, сине кичә-кичә
Әллә нәрсәләргә юралды:
Әллә җирнең салкын тире чыга,
Әллә таңгы яше Уралның...

## Бөрҗән эте

Чебен кебек үтә машиналар,
Этләр ятып кала, өрмиләр.
Бар урманны ташып бетеп барсын,

Этләр әйтерсең лә күрмиләр.

Этләр белән эт булмаска иде,
Нинди уйга этләр тарыган?
Әллә алар өрә белми туган,
Әллә алар өреп арыган.

Бөрҗән эте, ничек итеп, ничек
Өрмәскә син шулай өйрәндең?
Шуны күреп янам, гүя бәйле
Мин каравыл эте Бөрҗәннең.

Саклар өчен бүген, яклар өчен,
Әй күп кирәк әле йөрергә.
Эттән калышмаска исәбем бар,
Өйрәнмәсәм дә мин өрергә.

# «Аргамакта» китабыннан

# (1998)

*** * ***

Бер уйласаң, тагын нинди ирек,
Кирәк тагын нинди иркенлек?
Аерылып ялгыз торып калсаң,
Тоташ дөнья гүя бер тиенлек.

Бәлки, шуннан олы бәхет юктыр,
Торадыр, дим, ничек бүлүдән.
Халкың арасында көннәр күреп,
Халкың арасында үлүдән.

Йөрәгемдә ни барлыгын әйтәм,
Эчемдәге — тышта, серем юк.
Арка терәр башка халкым да юк,
Барып үләр башка җирем юк.

## Йөрәктәге һәйкәлләр

*(Поэма)*

*Салават Юлаев премиясе лауреаты, Башкортстанның тәүге халык язучысы Зәйнәп Биишева истәлегенә*

## I

Йөз елга бер балкый торган
Йолдызыбыз атылдымы;
Йолдыз тиеп чатнатты да,
Күк гөмбәзе ватылдымы?

Җиргә бактым, күккә бактым,
Без йолдызлы күксез калдык,
Күзне терәр кеше кайда —
Шул арада үксез калдык.

Кайда хәзер, хәзер кайда
Аркабыздан сөяр кеше,
Безнең өчен канатланыр,
Безнең өчен көяр кеше?

Ничә дистә еллар буе
Барчабызны туплап торган,
Явызлыкка каршы басып,
Тик яхшыны хуплап торган.

Дошманына гына түгел,
Туганына ярып әйткән;
Аңдып торган маңкортлыктан,
Гамьсезлектән арып әйткән.
Күпме генә татымасын
Әйткән өчен хак сүз хакын,
Үз язмышын уйламады,
Уйлады ул бары халкын.

Җанын бирер, ул намусын
Алмаштырмас малга, данга.
Ә хак сүзен әйтер өчен
Батарга да әзер канга.

Ул сатарга мөмкин түгел,
Мөмкин түгел сатылырга,
Туры килсә сатылганчы,
Әзер иде атылырга.

Яратмады ярамсакны,
Юлатмады ялагайны.
Ярамсактан, ялагайдан
Артык күрде алабайны.

Берекмәде берекмәскә,
Кушылмады куштаннарга.
Югарырак карады ул
Югарыдан кушканнарга.

Сиздe һәрчак башкалардан
Артыграк мең мәртәбә.
Бүген язмыш корылганын,
Дучарлыгын мең киртәгә.

Эзләде ул дәваларын,
Эзләде ул чараларын,
Дәваларга милләтенең
Меңәр еллык яраларын.
Беләм, озак юксынырбыз,
Беләм, озак сагынырбыз.
Әле озак аптырарбыз,
Кайчан кемгә табынырбыз?

Беләм, тоям: шушы сынны
Вакыт һаман зурайтасын,
Дәвер аша шушы сыннан
Мәңге сүнмәс нур кайтасын.

Күз алдымда гел торасың,
Төшләремдә гел каласың,
Шундый кеше кайда, диеп,
Кайда, диеп, ил анасы?!

## II

Ә ул күктән төшмәгән иде,
Ил анасы илдә үсте.
Йөрәгендә ниләр булса —
Җирдән күчте, илдән күчте.

Эчкән судан, карт туфрактан,
Һавасыннан, җилләреннән,
Бәгырь өзәр моңнарыннан,
Балдай татлы телләреннән.

Тик татлыдан гына түгел,
Кайбер телнең агуыннан.
Басуына караганда
Күбесенчә кагуыннан.

Хәтта, димен, гамь күчкәндер
Җанлыгыннан, кошларыннан.
Тормышның һәр мизгеленнән,
Җәйләреннән, кышларыннан.
Үзәгеңә күп үткәндер
Чатнама кыш зәһәрләре.
Кыш суыгы нәрсә әле —
Авыр язмыш каһәрләре.

Сабый чактан тойгангамы
Бу тормышның хикмәтләрен,
Тәти итеп тоттырганга
Җәфаларын, михнәтләрен.

Иркәләнер генә чакта
Ятим торып калганга да,
Иң тәү адымнардан башлап
Әче сабак алганга да.

Мондый язмыш кемнең генә
Башларыннан үтмәгән иде.
Тик берәүне синнән башка
Мондый очыш көтмәгән иде.

Мондый очыш йөз елга бер,
Бик күпләрдән тик син берәү.
Тарих ничек киң булмасын,
Күп меңнәрдән берәү кирә.

Син халыкны күтәрерлек,
Син аңнарны терелтердәй.
Исемеңне мәңге-мәңге
Дастаннарга йөретерләр.

## III

Иң борчулы ил анасы,
Күрәм сине төрле сында.

Карашыңнан көн яктырды,
Җир җылынды синең тыннан.
Әй, халкымның туа тора
Йөзәр елга бер чәчәне.
Күтәрүче милләтемне,
Кадерләүче Җир-ананы.

Син — чәчүче, җирең бик зур —
Заманалар ызаннары.
Күтәрелә мәңге яткан
Гасырларның тузаннары.

«Син» дип язам якын итеп,
«Син» дип язам, инәй, сиңа.
Ишеткән юк берәүнең дә
«Сез» дигәнен инәсенә.

Үзең куштың: кирәк түгел
Һәрчак «һез» дип сөйләшергә.
Бөекләргә бер сүз белән
Мөмкин «син» дип эндәшергә...

Онытмаслык итеп әйттең:
«Сез» дип әйт, дип, вак-төяккә,
Йөрәкләре бәләкәйгә
Йә булмаса аксөяккә.

Син — чәчүче, төп шөгылең
Түгел тузан күтәрүдә.
Таңнан кичкә җир өстендә
Төп хыялың үткәрүдә.

Син яланбаш, яланаяк,
Изү ачык, җиң төрелгән.
Беләсең син, җир корыган,
Әллә кайчан бер сөрелгән.
Барасың син түмгәкләрне
Яланаяк изеп-ваклап.
Никадәрле чәчүлекне
Тискәре ел киткән каклап.

Коргаксыган, җир ярылган,
Түзми сабан төрәннәре.
Җирме әллә телдән язган,
Яңгырамый сөрәннәре.

Шундый җирне сөреп кара,
Шуннан җирне тырмап кара,
Аркаң белән ятып кара,
Кулың белән тырнап кара.

Җилгә чәчми, җиргә чәчеп,
Шуннан уңыш алып кара,
Ил кышларлык ашлыгыңны
Бураларга салып кара.

Син — чәчүче! Нәкъ шул кеше,

Нәкъ шул кеше бар булмышың.
Көзен җыйган ашлык сыман,
Шуннан да зур бар уңышың.

Син борынгы, күп беләсең:
Вакыт ничек җиләчәген.
Кеше нишләр, нишләр кеше
Бүгенге көн, киләчәген.

Син — чәчүче, нур чәчүче,
Җиргә якты таратучы,
Халкы өчен җан бирүче,
Дөньяны нык яратучы.
Син — чәчүче, син — багучы,
Синең басу икенчерәк:
Тоташ кеше язмышлары,
Кеше тумый икенче рәт.

Күрсәтәләр күрмәгәнне,
Заман каты, заман кырыс.
Бәла килә, каза килә,
Озак килә һаман ырыс*.

Кешеләрнең бушап калган
Күңеленә җан өрергә,
Ничек итеп коты киткән
Дөньясына ямь өрергә?

Туңып беткән, катып беткән
Туң күңелне эретергә.
Таш йөрәкне йомшартырга,
Мескен ирне ир итәргә.

Күз белән каш арасында
Ир сыйфатын ир югалта.
Ходай биргән чирдән элек
Сатып алган чир югалта.

Кай хатыннар, нинди зәхмәт,
Ирләреннән уздыралар.
Тик өендә генә түгел —
Дөнья ямен туздыралар.

Ул гынамы, тик ул булса...
Һәлакәт бит — аза дөнья.
Күз алдында, көн битендә
Акылыннан яза дөнья.
Гүя бары син җаваплы,
Сине күпме күзәткән бар.
Тыныч бул, дип, кабат-кабат
Инде күпме йөдәткән бар.

Бер куанам, бер юанам
Белеп шундый хәлләреңне.
Шушы дөнья өчен синең
Ятып елар мәлләреңне.

**IV**

Әсәрләрең зур гомерле,
Геройларың — мәңге тере.
Алар яши үз халкының
Йөрәгенә үтеп кереп.

Син чакырдың, күрсәттең юл
Караңгыдан — яктылыкка,
Түбәнлектән — биеклеккә,
Яманлыктан — яхшылыкка.

Кимсетелгән, рәнҗетелгән
Бу дөньяны уятырга.
Ил язмышын язышырга,
Иртәгәсен уйлатырга.

Ачып салдың адәмнәргә
Гомер бушка акканнарны,
Якладың да, сакладың да
Җил-давыллар какканнарны.

Арабызга килеп керде
Бүген шундый кирәклеләр:
«Патшалыкка баш имәгән
Горур, яугир йөрәклеләр».
Хамматлар да Тимербайлар
Дәртләндерде башкаларны.
Калтыратты хакимнәрне,
Бәләкәй, зур патшаларны.

Уяндылар, уйландылар,
Тынычның да каны кыза;
Аягүрә күтәрелде
Ир йөрәкле хатын-кызлар.

Һәр өлкәдә, һәр тарафта
Ишәйделәр Җимешләр дә.
Алар тора кыя сыман,
Җиңә алмый җиңмешләр дә.

Әни, сине еш күрделәр
Нәкъ әнә шул Җимеш итеп.
Булмастайны булдырырлык,
Җиңелмәсне җиңмеш итеп.

Үзең белән булаштылар
Мәкер белән жиңәргә дип.
Йә өркетеп, йә куркытып,
Җилкәңә дә менәргә дип.

Заманасы заманмыни —
Нинди хәйлә кормадылар.
Синең белән алышканнар
Тырнагыңа тормадылар.

Ыгы-зыгы, болганыштан
Күңел бераз таушалса да,
Аякларны киереп бастык,
Кайчагында каушалса да.

Илдә арта ир-егетләр,
Варисларың базыклана*.
Сабак алып үткәннәрдән,
Олы рухтан азыклана.

Ил язмышы — ир камусы,
Җыелган ир торып баса.
Ил акылга килә бара,
Җыелган ил торып баса.

## V

Мәрмәр түгел, бакыр түгел,
Ул үзенә һәйкәл салды.
Берәү түгел, икәү түгел,
Аңа мең-мең һәйкәл калды.

Төрле-төрле авылларда,
Зур шәһәрдә, шәһәрчектә,
Сарайларда, куышларда,
Иң бәләкәй алачыкта.

Самолетта очканнарга,
Җилүчегә машинада,
Ышанмаган сөюенең
Азагына, башына да...

Игүчедә, тегүчедә,
Түрдә булган түрәләрдә,
Кем шахтада, кем вахтада,
Ял йортында, төрмәләрдә...
Иң кыскасы: бөтен җирдә —
Илебездә, чит илләрдә,
Кем укыган үз телендә,
Кем укыган чит телләрдә.

Ул халкының күңелендә
Үз-үзенә һәйкәл куйды.
Хәтеренә, исләренә
Онытмаслык итеп уйды.

Тагын мең-мең сүз өстәрләр
Әле минем әйткәннәргә.
Чал башымны җиргә иям
Йөрәктәге һәйкәлләргә.

*2—19 гыйнвар, 1997*

## Баллада

*Башкорт халкының легендар улы Таһир Кусимов истәлегенә*

Заман ярсу, заман хәтәр,
Аргамаклар — шул ук.
Тоягында — шул ук чаткы,
Каннарында — һаман шул ут.

Атылалар лачындай
Һич арымас аргамаклар.

Давыл булып оча алар
Бәйгеләре тар сымак та.

Яшен булып дошман өчен
Күтәрелеп күк Уралдан,
Мондый башкорт атларына
Юл йомгагы күп уралган.
Һаман ярсып җилә алар,
Заманыннан калмас өчен.
Баш бирмәсләр сыман хәтта
Йөгәннәрен салмас өчен.

Өсләрендә бүз малайлар,
Шпоры юк, ияре юк.
Атлар үзе коштай оча,
Камчының да тияре юк.

Кулларында кылыч түгел,
Бер бәләкәй камчы гына.
Бу толпарлар тоеп тора,
Күрсәтеп ал тамчы гына.

Көн кыздыра, көн битендә
Кыза бара һаман уен.
Анда — уен, монда — уен,
Әбҗәлилдә сабан туе.

Болай да бик гүзәл җирне
Тагын бизәп иген чыккан.
Яшел дәрья сыман булып,
Чәчкән орлык тишеп чыккан.

Малчыларның күңеле көр —
Җыелган бит барча халык.
Кешеләрнең бәйрәменә
Таулар иңри хәйран калып.

Хәйран калып тора таулар,
Мондый шатлык килә каян?
Көн кыздыра, көн битендә
Кызган саен кыза мәйдан.

Кыза мәйдан, кызган саен,
Кызган саен халык арта.
Алдан килгән — урын өчен,
Ә күпмесе килә артта.

Килә артта әле күпме
Төрле җирдән, төрле яктан.
Җилдерәләр машинада,
Килә җәяү, килә атта.

Менә кинәт алда әйткән
Ат чабышы — бәйге кызды.
Өермәдәй тузан очты,
Тузан күмде яшел кырны.

Кыркыт белән Ирәндек тә

Дер селкенеп торган сыман.
Бөтен дөнья монда бүген —
Күз карашын борган сыман.

Әйтерсең лә хәсрәт беткән,
Һичбер кайгы күрелмәгән.
Бөтен афәт урап үткән,
Җиргә нужа үрелмәгән.

Чал генерал уйга баткан,
Кырыслана бара йөзе.
Кара көеп киткән саен,
Төпкә төшә бара күзе.

Түшендәге йолдызыдай
Күзендә яшь китте ялтлап.
Чумган да үз дөньясына,
Ара-тирә йөри атлап.

Мин ни күрәм, менә берчак
Яшен сөртә читкә карап.
Гаҗәп: ул бит күпне күргән,
Аның күзе яшькә саран.

Таң калырлык тормышында
Күпме утны-суны кичкән.
Төрле мәлдә, төрле хәлдә
Азмы шатлык, кайгы эчкән.

Әй, тойгылар бәйгесе бу,
Алып китә күрмә кырын.
Шул яшь сәбәпче булса да,
Яшь хакында түгел җырым.

Бәйге бара, түзеп кара,
Һаман кыза сабан туе.
Ул бәйгене күзәтсә дә,
Яу кырындадыр, дим, уе.

Чирек гасыр ат өстендә,
Чирек гасыр өзәңгедә.
Әйтү ансат, исләр китә
Аңа ничек түзгәненә.

Бәлки, шулчак чал генерал
Бар гомерен барлагандыр.
Күңелендә дәрья булып
Бар хатирә яралгандыр.

Гомеренең төрле чагы
Күмер кебек терелгәндер.
Янартаулардай ялкынлап,
Төрле хискә бирелгәндер.

Һәрхәлдә, нәкъ аны шулай
Укыдым мин күзләреннән.
Тик тойганны әйтеп булыр
Нинди генә сүзләр белән?

Мондый хәлне тәүдә күреп,

Күзләреннән күз алмыймын.
Шушы тере легенданы
Мин үземчә күзаллыймын.

Яшь арыслан — яшьлегендә,
Карт арыслан — картлыгында.
Яшьлегендә яшен булгач,
Картлыгы да шартлы гына.

Хезмәткә дә сабантуйдан
Аргамакта киткән бит ул.
Шуннан төшми оча-җилә
Җир чигенә җиткән бит ул.

Хатлар җитмәс якларга да
Иярләгән атлар җиткән.
Атлар җиткәч, артларыннан
Рухландырыр хатлар җиткән.

Алып очкан аргамаклар,
Җил сызгырган битләренә.
Үтеп Кавказ сыртларыннан
Ирак, Иран чикләренә.

Асыл улларын тупларга
Үрә торды Урал сырты.
Аргамаклар да түзмичә
Кешнәделәр җирне ертып.

Ат иярләп яу чабарга
Кушты намус, җан сорады.
Батыр иргә канат куйды,
Дошманга үч, ил ораны.

Атланды атка башкортлар,
Асыл ирләр чыкты яуга.
Туган җир, дип, туганыбыз, дип,
Канга — кан, дип, чыкты дауга.

Соры үләт үтмәсен дип,
Саклар өчен газиз җирне,
Атлы гаскәр, затлы гаскәр
Уктай булып утка керде.

Җир гүләде, күк гүләде,
Ирләр янды, җирләр янды.
Таулар чүкте, кан кайнады
Белми кичне, белми таңны.

Ут кабыза итәкләргә,
Ут үрмәли ат ялына.
Ялкын яллы атлар курыкмый,
Бернәрсәдән кот алынмый.

Утка керә, суга керә,
Каршы бара танкларга.
Өстендәге егет үче
Атларны да каныктырган.

Әй, дәһшәтле бәрелешләр...

Югалтулар күпме булды.
Янәшәдә үлем җилде,
Янды йөрәк, күңел тулды.

Кисеп чыкты күпме суны
Башкорт аты, башкорт ире.
Күпме яулар артта калды,
Канат куйгач башкорт җире.

Ыңгырашкан чал Днепр —
Ташып торган казан икән.
Чума-бата кичә атлар,
Һаман яшәү язган икән.

Судан чыккач, тирләр каткач,
Ярсу атлар кыза гына,
Сылашкандай туган җиргә,
Дала буйлап сыза гына.

Тазартыла Украина,
Иркен сулыш ала Киев.
Җир шатлана бала кебек,
Яңа юган күлмәк киеп.

Әй яңгырый колак ярып:
— Алга! — дигән катгый оран.
Җиз шпоралар чыңлаганы
Тир-юньдә чыңлап тора.

Батыр ирләр белән сугыш
Табыштырды, аерды да.
Бик еракка очарлыкның
Канатларын каерды да.

Ләкин ерып чыкты алар
Баткагын да, карларын да.
Ат эчерде данлы гаскәр
Висла, Одер ярларында.

Аргамакта ул Мәскәүгә
Килеп җитте әллә каян.
Илнең Җиңү парадына
Күтеп алды Кызыл мәйдан.

Кан елаудан туктады җир,
Ул хезмәтен дәвам итте.
Шинель киеп узган гомер
Ярты гасыр булып китте.

Сабан туе — төшләрендә,
Өннәрендә — сабан туе.
Халыкның бу бәйрәменнән
Булмый икән һичбер туеп.

Ләкин тормыш түгел икән
Сабан туе тоташ кына.
Нинди батыр булсаң да син,
Түгел икән отыш кына.

Чирек гасыр — ияр өсте,
Чирек гасыр — өзәңгедә.
Соңгы вакыт җан алырдай
Бик еш тарта көзән генә.

Төштә түгел, менә өндә
Чыгам диеп аргы якка.
Теләде ул соңгы кабат
Атланырга аргамакка.

Басам дисә өзәңгегә,
Басам дисә — аягы юк.
Беркемгә дә, бернәрсәгә
Бу тормышның аявы юк.
Аның соңгы аргамагы
Кайлардадыр ярсып дулый.
Яулар җиңеп чыккан батыр
Мәңгелеккә очты шулай.

Мин җыр язам, аның сыны
Аргамакта җилеп үтте.
Ул чакырган соңгы оран
Йөрәгемне телеп үтте:

Олы юлда — олы халык,
Нигә генә тарымасын,
Башкортларның каһарманлык
Аргамагы арымасын!

## Галәм сакчысы

*(Поэма)*

*Каләмдәшем, дустым, Салават Юлаев премиясе лауреаты язучы Динис Бүләков истәлегенә*

Атылган йолдыз кабат кабынмый,
Нинди батырлар калмый абынмый.

Тауда елгалар ничек ярсымый,
Аны йотарга диңгез тарсынмый.

Көчле давыл да бер бит басыла,
Чаң-тузан гына күккә ачыла.

Хәтта толпар да арып туктала,
Иң соңгы чиккә барып ноктала.
Мең яшьлек имән корып егыла,
Җирләр чайкала, күкләр сыгыла.

Атылмас йолдыз,
Буйсынмас елга,
Басылмас давыл,
Арымас толпар,
Егылмас имән
Сыман идең син...

Син алар белән ярыштыңмыни?
Гүя дөньяга карыштыңмыни?

Галәм алдында
Атылды йолдыз,
Батыр абынды,
Елга туктады,
Давыл басылды,
Пешлекте толпар,
Имән егылды,
Килгән кайгыдан җирем сыгылды,
Күпме тамакка төер тыгылды.

Олы галәмне син саклый идең,
Барчабызны да син яклый идең.

Нишләп үзеңне саклап булмады,
Әҗәл алдында яклап булмады.

Кыелып төште капыл ил кашы,
Башың очында торды ил башы.

Яше-карты да бергә сыкрады,
Йөрәгем таштай, яшем туктармы?
Ут йота-йота ташка җан керде,
Синсез дөньяда нинди ямь инде.

Зыяратыңа килдем баш басып,
Йөрәккәемә гүя таш асып.

Әүлия микән әйтә теләкләр:
— Бик еш тумый бит Динис Бүләкләр.

Илегезгә ул зур бүләк иде,
Бурычыңны кал тиз түләп, диде...

Мәгърур сыныңны,
Эссе тыныңны,
Хисләргә тулы күңел кыныңны,
Синең еш булган давыл чагыңны,
Рәхәт чагыңны, кыен чагыңны,
Кайчакта булган боек чагыңны,
Бахыр егетләр батырланырлык,
Кайчак батыры бахырланырлык,
Әле тереләр калтыранырлык...
Сиңа күзләр дә тигән чакларны,
Сиңа сүзләр дә тигән чакларны,
Безгә зур терәк булган чакларны,
Күңелләр еш-еш тулган чакларны
Йөрәгемнән мин кат-кат актардым.

Синең хакта, дим, бик күп сөйләрләр,
Синең хакта, дим, хаклы язарлар.

Көлле яклап та, төрле яклап та
Күпләп өярләр, күпләп казырлар.

Булды бит кайчак ак айга карап
Өргән эт сыман, эттәй өрделәр.
Егетлегеңә күз йомып йөреп,

Юлда бер тайсаң, барын күрделәр.

Каберенә, дим, өзелмәс һич юл,
Бик озак еллар чәчкә ташырлар.
Замандашларың диңгездәй булып,
Әле басылып, әле ташарлар.

*

Баш очыңда ялгыз басып торам,
Язгы җилгә чәчем таратып.
Синең сыман изү чишеп торам,
Җан ярасын җилдән ялатып.

Күзем юеш, җил киптерер әле,
Әллә ничек йөрәк кагышы.
Якыннардан гафу үтенәмен,
Яңартканга сары сагышын.

Бер уйласаң, күнегеп тә беттек
Сагышлардан торган гомергә.
Җан дусларны бик тиз күмәбез дә,
Сагышларын кая күмәргә?

*

Сагыш җырын үз йортымда түгел,
Яки түгел иҗат йортында,
Йә бакчада,
Йә сәхрәдә түгел,
Мин башладым синең
Соңгы сулыш алган урында,
Шуңа моңсу булыр җырым да.
Сүз башлаган чакта ул мәлдә,
Мин дә ята идем шул хәлдә.
Синең үлем алды котларны,
Тик табиблар мине коткарды.

Егерме бер —
Гүя һәр хәрефтә егерме гер.
Егерме бер,
Егерме бер,
Егерме бер дип
Егерме бер кабат әйтүдән
Берни үзгәрми шул, әй, түзәм.

Егерме бер дигән хастаханәгә
Китергән идек сине
Ничә табиб бергә-бергәләп.
Сират күпереннән үткәрмәскә,
Көтеп торган әҗәл эргәдә.

Сират күперләре өзек булган,
Синең йөрәк кинәт ярылган.
Шундый пәһлеван да бирешерлек
Нәрсәләргә икән тарылган?

Нәрсәләргә, дустым, тарыдың син,

Калыр микән мәңге сер булып?
Башларыңны ашадылар микән
Хаин дошманнарың бер булып?

Белүләре кыен, гөнаһ алсам,
Ходай мине ничек ярлыкар?
Мин бит беләм байтак бәндәләрне
Синең язмышыңа тарыккан.

Синең гомер сокланырлык булды,
Көнләшерлек булды язмышың.
Тормышыңа куанганнар белән
Тарсынганнар әле азмы соң?

Синең ирлек, синең егетлегең,
Әй, күпләрнең күзен кыздырды.
Сине мактый-мактый шәраб эчеп,
Хыялында тирең сызгырды.

Күз тиярлек шушы егетлекләр
Килә иде синең каныңнан.
Әллә нинди бер горурлык булды
Басып кына тору яныңда.

Арысланда туган арыслан син,
Каты тордың дөнья сагында.
Аягүрә торып алыштың гел,
Бастың һәрчак хаклык ягында.

Синең белән мин дә бәхәсләштем,
Без бит яшәмәдек макташып.
Туры сүзле, ачык йөзле булдың,
Кинҗә Арысланов якташы.

Йә Салават мәйданында еш-еш
Сүз сөйләдең меңнәр алдында.
Халык хәтерендә бер әйдәүче,
Син Салават сыман калдың да.

*****

Беләсең килсә син кешене —
Бул син туган якларында.
Тиз күрәсең, тиз аңлыйсың
Карасын да, акларын да.

Никадәрле чакырдың син
Яшел Нөгеш буйларына.
Төрле шигъри кичәләргә,
Язгы сабан туйларына.

Юллар төшми торды байтак,
Бөтен гомер юлда үтә.
Һәр очрашу ул — бер гомер,
Һәркем аны зарыгып көтә.

Авылыңның ак йөзләрен
Күрәсе килә иде күптән.

Сиңа илле тулып китте —
Сәбәп килеп төште күктән.

Чакырдылар якташларың,
Чакырдылар кабат-кабат.
Көне-төне шалтыратып,
Хат яздылар табак-табак.

Барып төштек канатланып,
Җан дусларың белән бергә.
Дус бәйрәмен бәйрәм итеп,
Аяк бастык изге җиргә.

Бәйрәм генә дисеңме син,
Сабан туе көтеп тора.
Зур сәхнәнең иң түренә
Барча халык сине сорый.

Күтәреп үк алдылар бит
Сине генә түгел — безне.
Мәйдан шундый балкый, яна,
Куйган кебек чәчкә тезеп.

Баскан җирдә ут чыгарып,
Янып тора ир-атлары.
Сине котлый ил анасы,
Котлый сине ил картлары.

Дүрт күз белән халык көткән,
Җир зарыккан яңгыр көтеп.
Сабан туе кызган чакта
Яңгыр үтте коеп-түгеп.

Олы рәхмәт укыдылар
Төягенең баласына.
Инандылар Җир улының
Мәңге шулай каласына.

Сабан туе таралмады,
Сабан туе кызды гына.
Тик өлгереп кенә булмый
Аның бөтен кызыгына.

Син сүз әйттең яңгыратып,
Бәгыреңне ачып салып.
Улларының йөрәк сүзен
Тыңладылар таңнар калып.

Таңга калып тыңлап торды
Тауларың да, яланың да.
Синең өчен мин куандым,
Яшьләремне яладым да.

Әйттең илгә рәхмәт сүзен:
Мәңге сүзем аклармын дип,
Җирем рухын, халкым рухын
Йөрәгемдә саклармын дип.

Синең өчен җырладылар,

Биеделәр синең өчен.
Көрәшчеләр бер-бер артлы
Күрсәттеләр гайрәт-көчен.

Биергә дә чакырдылар,
Чакырдылар һәр табынга.
Үтенделәр утырырга
Ичмасам да бер кабымга.

Вакытың да җитмәгәндер
Һәрберенә кул бирергә.
Менә берчак фәрман булды
Зур бәйгегә юл бирергә.

Кызды бәйге, бәйге кызды,
Тын да алмый күзәтәләр.
Кем аты да кем аты, дип,
Бер-берсен йөдәтәләр.

Бәйге башы белеп булмый
Иң беренче кем килерен.
Тәү стартны карап кына
Җилдән җитез кем җилерен.

Менә берчак бер яшь толпар
Калганнарны китте узып.
Безнең тыннар кысылганда,
Кызган саен китте кызып.

Шушы толпар килде алдан,
Баткан иде манма тиргә.
Ходай нинди куәт биргән,
Ходай нинди йөрәк биргән?

Шул толпарны тоттырдылар,
Синеке, дип, Динис дустым.
Толпар ялый синең кулың,
Уттай иде синең учың.

Иркәләдең толпарны син,
Сыйпый-сыйпый көмеш ялын.
Күз тимәсен дигән кебек
Ялларыңа — шундый калын.

Йөре, диден, җирне бизәп,
Нөгеш тугайларын иңләп.
Бәйгеләргә чыккан чакта
Йөрәгеңне миңа тиңләп...

Олы бәйрәм дәвам итте,
Кызу кояш сүрелгәнче.
Бәйрәмнәр гел дәвам итми,
Бөтен күңел күрелгәнче.

Көндез мәҗлес, кичен мәҗлес,
Бөтен авыл кунак итә,
Берәү чәйгә кереп чыга,
Икенчебез куна китә.

Зур кунактан чыгып киттек,

Качып Динис белән икәү.
Арысланның ак йөзләрен
Карап йөрү бәхет икән.

Мин дустымның тамырларын,
Тере тамырларын күрдем.
Үкенмәдем калдырганга
Кунактагы олы түрне.

Җайлап кына нигезеңә,
Өйгә килдек үзең салган.
Анда хәзер башка яши,
Анда күпме эзең калган.

Анда тәүге шатлыкларың,
Анда тәүге кайгыларың.
Өнсез генә тордың озак,
Хәтерләпме кайгыларын.

Илле бердә үлгән әниең,
Нәнәң дә илле бердә.
Бу илле бер нинди чик ул,
Син үзең дә илле бердә...

Ә нәрсә дип шаулагандыр
Меңәр яшьлек бу тирәкләр.
Бары алар гына шаһит
Ни булганга бу төбәктә.

Тирәк кебек дустым аугач,
Сөялергә кай тирәккә?
Сөялерлек, таянырлык
Тирәкләр дә бик сирәкләр.

Сабантуйдан башладым бит
Сөйләр сүзне, әйтер сүзне.
Тагын-тагын искә төшә,
Аңа кайтам, чак-чак түзеп.

Ничек кенә җырладылар,
Ничек биеп әйләнделәр.
Биеттеләр Ләйсәнне дә,
Биеттеләр Рәйләңне дә.

Күзәттеләр күзе төшеп
Өч йөз яктан өч сылуны.
Тормыш гүя матурлыкта,
Белми дөнья үч кылуны.

Җаның — Рәйләң — озын юлдан
Йончып торды әллә кичтән.
Синең туган җиргә баскач,
Сер бирмәде шунда һич тә.

Ут чыгарып биеп киткәч,
Вәт, ичмасам, килен, дидек.
Шундый киленнәр ишәеп,
Әй кинәнсен илем, дидек.

Рухы нинди, балкытырдай
Ирецне дә, илеңне дә.
Алар белән саклап була
Илне тотар билеңне дә.

Сезнең шундый пар килүгә
Сокландылар кая барма.
Син гадидән гади идең,
Булмадың һич эре ярма.

Бу соклангыч язмышларга
Каты күзләр тигәндер лә.
Бирешмәссең сыман иде,
Таллар башын игәндер лә.

Сабантуйны кем яратмый,
Тормыш түгел — уен-көлке.
Эттәй тугры дуслар да күп,
Араларда — күпме төлке.
Бәләкәйдән тезген тоткач,
Тезгеннәрне озак тоттың.
Син камчысыз көенчә дә
Өсти алдың кирәк утны.

Кирәк чакта сабыр иттең,
Хас булмады түземсезлек.
Канатландыра кешене
Гаделлек һәм үлемсезлек.

Юлда белеп атладың син
Үлемсезлек юлы белән:
Үкенечле, соңлабрак
Ил дан ала улы белән.

Ир язмышы — ил язмышы,
Чын ирләр бит илгә карый;
Сайлый белгән угланнарын —
Ил яхшысы илгә ярый.

*

Бу дөньяда ниләр кичермәдек,
Кемнәр генә ярдан этмәделәр.
Алла бәндәләре ачтан бөлде,
Кирәк чакта ярдәм итмәделәр.

Бер мин генәме соң әле шулай
Сөялүче синең иңнәреңә.
Кеше өчен син чыгарып бирдең
Карап тормый соңгы тиеннәреңә.

Юньле адәм белән «сез» дип түгел,
Туры «син» дип кенә ымладың да,
Кеше хәсрәтләрен сөйләгәндә,
Йөрәгеңне биреп тыңладың да.
Кинәт һава җитмәгәндәй була —
Арабызда синең җитмәүләрең.
Дусларымнан елап үтенәмен
Бу дөньяны ташлап китмәүләрен.

Миңа да бит үтенгәннәр байтак,
Дөрес кенә яши белмәгәнгә;
Меңнәр кабат үзәгемә үтсен,
Колагыма һаман элмәгәнгә.

Ачы тормыш ачы шулпаларын
Сузып торды, тулы табакларын.
Ничә буын шулай чират белән
Яңгыратты арка сабакларын.

Авызлар да еш-еш томаланды,
Кисеп алмадылар телне генә.
Буын ныгыттылар түзем яшьләр,
Бары үзләренең белдегенә.

Сөйләп кенә бетерерлекме икән,
Туймый безне күпме кагуларын.
Адым саен корган тозакларын,
Дару диеп биргән агуларын.

Карап торсаң, бер сихерче сыман
Җаен таптың шәпнең, җаең да.
Кесәләрең буш чак күп булгандыр,
Рәхәтләнеп рухи баедың да.

Өлкән белән олы була белдең,
Кече белән булдың аннан кече,
Эчеңдәге гел тышыңда иде,
Йөзеңдә дә иде күңел эче.

Ул байлыкны үлчәр бизмәннәр юк,
Ул байлыкны илгә өләшерлек,
Дусларыңны атка мендерерлек,
Көнчелләргә көеп көнләшерлек.

Китапларың — ак канатлы кошлар,
Очкан юлы гелән уңа торды.
Китап киштәсеннән бигрәк тә
Күңел киштәсенә куна торды.

Син тереме, диеп сорагандай,
Таңгы йокылардан уятты ул.
Нинди генә уйга салмады да
Нинди генә уйлар уйлатты ул.

Бу тормышның бөтен якты ягы,
Бу тормышның байтак каралары;
Нинди генә күңел очышлары,
Нинди генә йөрәк яралары.

Син язганда, гелән яздың, чөнки
Үз намусың кушкан берне тыңлап,
Алай гына түгел, ил йөрәген
Күкне тыңлап, тоташ җирне тыңлап.

Сөйләгәндә ут чәчрәтеп тордың,
Кирәк икән ихлас көлдердең дә.
Иң хак сүзне күзгә карап әйттең,
Кайберәүне сүзсез бөлдердең дә.

Булды, битсезлекнең битен ачтың,
Һич ертмадың берчак кеше йөзен.
Кәпәч кулда булды — яланбашсың,
Изү ачык — кышын, язын, көзен.

Бушка сөйләмәдең бер сүзеңне,
Бер эшеңне юкка эшләмәдең.
Аркалардан юкка сыйпамадың,
Тешли икән, юкка тешләмәдең.

Бүген менә кайбер дусларымны
Синең кебек эшләтәсе килә.
Чәчләреннән сыйпатасы килә,
Синең кебек тешләтәсе килә.

Бернәрсәне һич кайтарып булмый,
Кем алдына гына тезләнсәк тә.
Өнең, тының ераклаша сыман,
Көндез шәмнәр белән эзләсәк тә.

Табигатькә даһиең дә бер үк,
Җирдә мыжгып торган кырмыска да.
Аңа каршы берни кылып булмый,
Канун артык шулай кырыска да.

Бурыч кимер иде язганымнан
Кемлегеңне әгәр тоеп булса,
Сүз куәсе белән бер могҗиза
Горур сының тулы коеп булса.

Һәр сүземне язам туры итеп,
Минем һәрбер сүзем гади булсын:
Иң мөһиме әйтеләме икән,
Шуңа күңел генәм абай булсын.

Абай булыр чакта күп сөйләндек,
Әйтмәс сүзләр әйттем авыз ачып.
Үз-үзеңнән генә түгел инде,
Ул узганнан хәзер булмый качып.
Без бикләндек кайчак үзебезгә,
Бөтен серне артык ачмадык та.
Без этисез булып гомер сөрдек,
Туган җирдән бизеп качмадык та.

Күкрәк көчең белән бар малыңны —
Тик хәләлен җиреңбуйлап таптың.
Тормыш кебек гади сүзләр белән
Ил тетрәнер,
Ил куаныр сүзләр уйлап таптың.

Сүзең җитте ерак тарафларга
Хәтерләтерлек төрле ыруларым.
Сине хәтта кымшандырмады да
Кемнәрнеңдер тамак кырулары.

Кино сыман күз алдында тора
Кеше язмышының хафалары.
Уй җиткәндә буй җитәрлек җиңү

Яки төзәтмәслек хаталары.

Нинди генә заман гыйбрәтләре,
Язмышларның төрле олаулары.
Кешеләрнең ничек күккә ашып,
Кешеләрнең ничек егылулары.

Кешеләрнең күпме көлүләре,
Кешеләрнең күпме елаулары;
Йолдызларга кулын сузулары,
Кара җирдә ятып дулаулары.

Мәхәббәтнең канат куюларын,
Җирне яндырыр нәфрәтен дә,
Кеше кайгыларын уртаклашып,
Иң-иң олы үзең хәсрәтеңдәй.
Барчасын да санап чыгарлыкмы,
Барчасын да айкап бетәрлекме,
Кайсылары күңел ачарлыкмы,
Кайсылары җанны өтәрлекме...

Алар гүя сосып алынганнар
Кайнап торган тормыш казаныннан.
Күпме гыйбрәт, өлге булды алар
Акыллысына да наданына.

Язып киттең олы васыятең,
Оран салдың «гомер бер генә» дип,
Таянырга туган халык кына,
Табынырга туган җир генә, дип.

Йөрәгеңне үзең тотып тордың
Иң-иң кызган вакыт сандалында.
Синең сүзең Данко йөрәгедәй,
Оран булыр заман алларында.

## Көзге сагыш

Тискәредән салкын җилләр исә,
Басып алган көзне сарысы.
Уйламыймын дөнья җылыныр дип,
Үтеп киткән сыман барысы.

Белдермимен сиңа берни хәбәр,
Чыкмассың да эзләп каршыга.
Бер узгынчы сыман карап торам:
Нигә икән көзләр ашыга.
Кошлар китеп барган, дөнья буп-буш,
Көзнең миндә бер дә эше юк.
Үзем белән үзем торып калдым,
Игътибар да иткән кеше юк.

Белмимен дә синең кайдалыкны,
Көз түгелдер инде уеңда.
Миңа калса, синең язмыш һаман

Торган сыман бары уеннан.

Көнләшмимен сиңа, үпкәм дә юк,
Алда көтә күпме язларың.
Син татырга тиеш бөтен булган
Бу дөньяның хәләл назларын.

Җирдә шатлык миңа шартлы гына,
Күнеп беттем моңсу тавышка.
Әллә кайдан томан төшеп килә,
Көне дә бит кичкә авышкан.

Тагын язлар килер, дигән булып,
Өннәремдә өнсез саташам.
Сиңа әйтеп өлгермәгән сүзне
Искән җилгә сөйләп маташам.

Күңелемне үзгәрмәслек итеп
Тоташ көз мизгеле чолгады.
Ярый, яшь куаклар кулың сыман
Сары яфрак миңа болгады.

*** * ***

Кичен ятсам, иртән торсам,
Тел очымда бер дога —
Теләгәнем бар дөньяга,
Теләгәнем бер аңа.
Каршылыйк без һәр иртәне
Кече шатлык тау булып:
Башкортстан исән булып,
Башкортстан сау булып!

## Курайга һәйкәл

*Баймак районының Төрекмән авылында куелган*
*курай һәйкәле авторы Мидхәт Бәйрамголовка*

Дөньяда бер булып җир өстендә,
Торасың син җиһан астында.
Чал башымны идем бөеклеккә,
Алларыңа килеп бастым да.

Мәгъруурлыгың синең, курай-һәйкәл,
Күкнең үзен терәп торгандай.
Вакыт агышларын туктаткандай,
Искән җилне кире боргандай.

Җил тудырган моңың күккә ашсын,
Ишетелсен бөтен Уралга.
Такыяңа килеп кошлар куна,
Такыяңа болыт уралган.

Бөркет чаңкып утырадыр анда,
Ирәндекнең күреп ак сыртын.
Курайларга һәйкәл куйган чакта,

Моңы бетмәс горур башкортның.

## Зур ерактан күренә

*(«Русиянең Башкортстанны басып алуы»*
*китабының авторы Америка профессоры*
*Алтон Стюарт Донелли белән*
*очрашу уңаеннан)*

Дөнья башкортлары корылтае.
Тәмамланган көнне җыеннар
Алтон Донеллилар кунак булды
Раил Кузеевның сыенда.

Монда гүя Америка ачты
Ерак Америка вәкиле.
Түбәләре күккә тигән кебек
Чакырылып монда вә килеп.

Әллә ничә телдә теле талмый
Сайрап торды сылу Шамилә.
Әле бүгенгедән, әле килеп
Тарих төпкеленнән шаң килә.

Төрле сүзләр күп сөйләнде монда,
Профессорлар торды гел үрә.
Таңга кадәр безне таң калдырды
Башкорт сандугачы Флүрә.

Шаккаттылар, сокландылар җырга,
Зур кунаклар кат-кат сорады.
Сый да, җыр да майдай сеңә бирде,
Соң инәлтеп башкорт торамы?

Күп сөйләде, хәтта җыр җырлады
Ничә кабат торып Донелли:
Зур коллыктан юкка котылмаган
Башкортстан, диеп, дан иле.
Тыңладым мин артык кысылмыйча,
Һаваланып, хәтта эрерәк.
Дөнья алларында сер бирмәгән
Башкортымны тойдым тererәк.

Ерак кыйтгалардан килеп безгә
Сокланырлык җирләр булганга,
Сокланырлык кызлар булганга да
Сокланырлык ирләр булганга.

## Ил агасында

*Зәкәрия Акназаровка*

Мин чәй эчеп кайтып киләм
Ил агасы Зәкәриядән.
Әйтерсең лә кинәт баеп
Кайтып киләм Мәкәрьядән.

Байлык дисәм, кулым — буп-буш,
Баемадым алтын алып.

Зиһенемне балкытырлык
Кайттым сүнмәс ялкын алып.

Гаҗәп итеп кайтып киләм,
Күп нәрсәгә күз ачылып.
Нинди гади, нинди серле
Бу дөньяның үз асылы.

Утырдым мин һәрбер сүзен
Йотып кына, җөпләп-хуплап.
Йотып кына, киңәш туплап,
Илгә бирер акыл туплап.
Без икәүдән-икәү идек,
Гүя монда ил җыелган.
Азмы фикер, азмы акыл
Тупланган иде җыенга.

Сансыз еллар елъязмасы
Аның талгын сүзләрендә.
Нинди шаулы тормыш ага
Моңсу янган күзләрендә.

Барчасы да якын аңа:
Ераклары, янәшәсе,
Әйтерсең лә бер башында
Тоташ тормыш киңәшмәсе.

Сөйләми ул бу акылны
Гомер бакый җыйнауларын.
Бар үткәнен әйтеп тормый,
Кат-кат тормыш сынауларын.

Аксакалның хак киңәше
Һәр күңелгә йокса икән.
Гадилекне зурлык итеп,
Һәр акыллы тотса икән.

Мин чәй эчеп кайтып киләм
Ил агасы Зәкәриядән.
Әйтерсең лә кинәт баеп
Кайтып киләм Мәкәрьядән.

## Авырайган чакта адымнар

*Тимер Йосыповка*

Тимер дустым, нигә син иртәрәк
Авырая дисең адымнар?
Әле көтеп алыр көзләрең бар,
Ярсып килер күпме язың бар,
Сүрелмәслек күпме назың бар.

Шул язларда ятып дулыйсың бар,
Үзең сыман кара җиреңә.
Сөюеңне сөйләп бетмәгәнсең
Мәңге тугры бердәнбереңә.
(Артык кысылмыймын сереңә.)

Инде безгә карамасын да ди,
Адым җиңеләйтер кызлар бар.
Билең биштән буып чәчкән җирдән
Урып-сугып алыр кырлар бар,
Кырда языласы җырлар бар.

Синең җырлар йөрәк ярып чыга,
Шуңа кала алар йөрәктә.
Терелткәнгә сүнгән өметләрне
Алар безгә тугры терәк тә,
Шуңа кала алар йөрәктә.

Алышасы ничә мәйдан көтә,
Көнчелләрнең үче канмаган.
Мәлең юктыр синең яңа сүз, дип
Манма тиргә төшеп янмаган,
Сине сүнмәс ялкын ялмаган.

Йөкне үзең көчең җитеп тарткач,
Авырлары сиңа терәлә.
Барчасы да аңлыйлармы икән,
Хәлләреңә микән керәләр,
Авыр йөкләр сиңа терәлә.

Адым авыр, чөнки йөгең авыр,
Ил хәстәре ята иңеңә.
Офыкларны үтәр сәфәр чыктың,
Карап тормый юлның иңенә,
Заман тарта юлның киңенә.

Әй син, заман, синең кыланышны
Кайда көч бар кире борырлык?
Тере кеше авып китәрлек бит,
Үлгән кеше килеп торырлык,
Юлы бармы дөрес корырлык?

Барчасы да шагыйрь йөрәгенә,
Барчасы да шагыйрь башына.
Йөгәнсезләр бүген тезген тоткач,
Дөньяларга сыймый шашына,
Барчасы да шагыйрь башына.

Тимер дустым, бүген чынлап та
Авырая икән адымнар.
Заман җиле уңай борылсын дип,
Кирәк сүзне әйтер адым бар,
Авырайса да бит адымнар.

*** * ***

Мин — янгыннан торып калган кеше.
Озак янды минем гомерем.
Башлап бергә булган көннәр янды,
Сүнә-сүнә соңгы күмере.

Янә бергә булган айлар янды,
Сыдырылып янды айларым.

Сүндерергә беркем теләмәде,
Уттан көлләр очты каядыр.

Азак бергә булган еллар янды,
Көйри-көйри янды елларым.
Көннәр, айлар, еллар төтененнән
Томаланды барыр юлларым.

Мин — янгыннан торып калган кеше.
Баш өстендә көлләр тузалар.
Минем көннәр көлләр арасыннан
Тере күмер эзләп узалар.

*** * ***

Бу тормышны бераз рәтләр өчен
Минем байтак кына көч кергән.
Йөрәгемне бүген каннар сава,
Минем гомер тормый өч тиенгә.

Үземә дә сабак, гыйбрәт булды
Язмышымны ничек кормышым.
Менә сиңа — җырчы көнкүреше,
Менә шулай — шагыйрь тормышы.

## Йокысызлык

Шәһәрем йоклый,
Иң якыным йоклый,
Тыныч йокы гына аларга.
Миңа инде мең уй давылында
Дуларга да әле дуларга.

Һаман шулай дәвам итәр инде,
Соңгы кабат тыным алганчы.
Йокысызлык түгел,
Тик моңсызлык борчыр
Мәңге йокыларга талганчы.

*** * ***

Бер кәккүктән килер көннәремне
Исәпләтеп сорап маташам.
Исәр кәккүк, минем башны бутап,
Калган гомер белән саташа.

Синең өчен, кәккүк, берни түгел,
Тагын ярты гомер ал да бир.
Ичмасам, дим, белеп торган көе,
Исәр кәккүк, әйдә,
Мин исәрне тагын алдый бир!

## Үтәгән

*Якташым академик Гайса Хөсәеновка*

Тормыш көн дә зур бер сорау куя:

Төп бурычын кемнәр үтәгән?
Кемнәр аны тәмам онытканнар,
Кемнәр башлап үтәп бетмәгән.

Син кешесең икән, шул бурычны
Тулысынча тиеш үтәргә.
Әллә ничә кеше көче җитмәс
Йөгең авыр синең күтәргән.

Буыннарың түзсен генә инде,
Түзсен генә инде беләгең.
Тотынгансың икән үтәргә дип
Син халкыңның олы теләген.

Гасырларны күрер карашың бар,
Меңне ега алыр акылың.
Бирелгәндә сиңа, сеңгән сиңа
Туган халык, төяк аркылы.

Ата-бабайлар рухы, җирем рухы
Сеңгән сиңа үтә-үтәдән.
Шундый улын көтеп туган җирнең
Күзе талган иде күптәннән.

Ил көткәнен белеп әүлиядай,
Яшисең тик шуны үтәргә.
Чөнки сине Кырмыскалы биргән,
Биргән сине чөнки Үтәгән.

## Меңле дигән исемеңне

*Меңле ыруының*
*балалар Сабан туенда катнашучыларга*

Мең ыруы төякләрен беләм,
Асыл төякләрен җиремнең.
Мин үземә-үзем аптыраштa —
Чиштерсәләр бүген серемне.

Мең мәртәбә дәртләндерде мине
Көрәшләрдә меңле батыры.
Көрәшләрдә утлар салганы бар
Йөрәгемә меңле матуры.

Батырлары, матурлары белән
Арта даны һаман меңнәрнең.
Яңа буын олы юлга әйди,
Әзерләнгән төреп җиңнәрне.

Килер еллар агышында, меңнәр,
Ишәюне килә күзәтәсем.
Шулчак меңле дигән исемеңне
Миллионлы дип килә үзгәртәсем,
Миллионлы дип килә үзгәртәсем...

## Син югалдың

*Галим Дәүләдигә*

Әй, мосафир дустым, гел юлдасың,
Күз алдында бетмәс юл һаман.

Юллар өчен генә тумагансың —
Җырлар өчен туган юламан.

Йөргәнгә юрмә* эләксә дә,
Көтеп кенә тормый юрмәләр.
Жирәбәләр тапкан мәлләреңдә
Шатлыгыңнан телең көрмәлә.

Синең белән байтак юллар үттем.
Чын дуслар бит юлда сынала.
Күпләр ярты юлда пешлегәләр,
Күпләр ярты юлда тыналар.

Бу җырымны мин дә юлда яздым,
Олы юлда, көннең битендә.
Син тормышның һәрчак уртасында,
Тормадың син юлның читендә.

Мәңге юлда, олы юлда бул син,
Син — тынгысыз, тынмас юлаучы.
Син халкыңа, туган төягеңә
Хыял, өмет, бәхет юллаучы.

## Гашыйк Кеше — чын Кеше

*** * ***

Синең йөзең күз алдыннан китми,
Куркып торам: бермәл югалыр.
Ул югалса, югалырмын үзем,
Куркуым да инде шуңадыр.

Синең йөзең гел алдымда торсын,
Кыйтгалардан аша танырлык.
Күз алдыннан бер югалтсам, куркам:
Җир шарыннан булмас табарлык.

*** * ***

Күңел — туп-тулы,
Бүлмәм — туп-тулы,
Шәһәрем — туп-тулы,
Син килгән чакта.

Күңелем — буп-буш,
Зур бүлмәм — буп-буш,
Шәһәрем — буп-буш,
Син киткән чакта.

*** * ***

Мин кояшның чыгышында,
Син киттең баешына.
Кем төшенә ала икән
Язмышлар аешына?
Якынаям дигән саен,
Китәсең кебек ерак.
Мине яшәткән кояшны

Китәсең кебек алып.

Ничек кенә хыялланмам,
Төшенмәм аешына.
Миңа кояш чыккан сыман
Көннәрең баешыннан.

* * *

Иң озын төн хәтта җитмәде бит,
Иң озын төн ничек җитсен инде.
Җиһаннардан серле бу күзләрең
Күз алдыннан ничек китсен инде.

Килер көннәр, синсез үтәр төннәр
Шушы төнгә килеп ялганырлар.
Җиһан төпләреннән күзләреңне
Булыр көтеп күзем талганы да.

Беләм инде, беләм, күпме янма —
Озын төннәр гелән көтмәсне дә.
Төннәр нәрсә, көннәр нәрсә соң ул,
Белгән чакта гомер җитмәсне дә.

* * *

Минем күңел булсын дипме,
Син тамчылап эчтең шәраб.
Балкыдың син әллә нидән,
Әллә шул тамчыга карап.
Мин исердем син балкудан,
Мин исердем эчмиенчә.
Онытмамын ул балкышны,
Бу дөньядан күчмиенчә.

Мин шул кичне искә алам
Әллә ниләр кичергәндә:
Эчкән чакта айныганда,
Эчмиенчә исергәндә.

* * *

Бөтен дөнья ап-ак булды,
Шундый сихри кыш инде.
Әйтерсең лә дөньяда без
Кышка калган кош инде.

Безгә җылы, безгә эссе,
Тирә-якта кыш сыман.
Атламыйбыз, без очабыз,
Без канатлы кош сыман.

Безнең канат — соңгы сөю,
Берни түгел кышлары.
Без — дөньяның суыкларда
Кышлый алган кошлары.

* * *

Иң-иң татлы төшләр онытылды,
Өндә булган эшләр онытылды.
Мин төш сыман өнне хәтерлим,
Теге соңгы көнне хәтерлим.

* * *

Икәү үткән юлдан барам,
Эзләреңә карлар салган.
Ап-ак карда нурлар булып
Карашларың гына калган.

Җилдә калган тавышыңнан
Көтеп барам синең сүзне.
Җавабымны эндәшмичә
Барам үзем чак-чак түзеп.

Ерактагы шәүләләрдән
Эзләп барам синең сынны.
Беркем миңа киңәш бирми,
Бер җавапсыз җилләр тынды.

Китеп барам борылмаска,
Китеп барам белми кая.
Икәү үткән юлдан барам,
Эзләреңә яуган карлар...

* * *

Өметләнәм зәңгәр һавалардан,
Өметләнәм зәңгәр күкләрдән.
Өметләнәм бүген аздан гына,
Өметләнәм бүген күпләрдән.

Өметләнәм һәрчак тын кичләрдән,
Өметләнәм якты таңнардан.
Өметләнәм горур имәннәрдән,
Өметләнәм нечкә таллардан.
Өметләнәм бүген бар дөньядан,
Булмаса да аны һич байкап.
Яшь-яшь таллар гына бәвеләләр,
Өметемә минем баш чайкап.

* * *

Кайгырдым мин карурманда,
Сөялергә агач тапмый.
Әй сусадым дәрьяларда
Сусын өчен йотым капмый.

Көн күрдем мин, әйтерсең лә
Кеше көлгән чакта елап.
Күңелләрем тулганда да

Карамадым бер дә дулап.

Елмайганда кояш сүрән,
Бәйрәмнәрдә толка* юкта,
Кинәт көнем балкып китте,
Минем алда бер син туктап.

Сөялергә урманым бар,
Сусап китсәм — дәрья суы.
Гади көн дә бәйрәм сыман,
Тик өлгерсен генә туып.

* * *

Бөтерелеп карлар ява,
Биткенәем янып-пешкән.
Бөтерелеп иртә белән
Ашыккан чак син дә эшкә.

Син еракта, син еракта,
Җир аягы җир башында.
Мин дә барам кар астында,
Бер генә уй бер башымда.

Ничек кенә, ничек итеп
Җаннарга җылы кертергә;
Иренеңнән яшь карларны
Яуган саен эретергә.

Сиңа минем тыным җитми,
Кулым сузам — кулым җитми.
Гомер буе бара торган
Тик бер адым юлым җитми.

* * *

Мин яклаусыз, мин саклаусыз,
Күк астында — яланөсле;
Килер бөтен гарасатны
Миндә сынар өчен төсле.

Өскә яуды гарасатлар,
Чама да юк аһ-аяга.
Тик яшеннәр миңа түгел,
Сугылалар кыяларга.
...Көн битендә иңнәремә
Ятты нечкә беләкләрең.
Тормышка дим аштымыни
Кинәт бөтен теләкләрем.

Йөрәккенәм тибә дарслап,
Түгел һич тә тынар өчен.
Гүя торам мине түгел,
Мин заманны сынар өчен.

* * *

Син бит минем аерылмас җаным,
Вакытлыча кисеп алынган.
Урынына өмет калдырылган,
Тынмый торган сагыш салынган.

Син бит минем аерылмас җаным,
Вакытлыча йолкып алынган.
Урынына хыял утыртылган,
Бөреләре күзгә чалынган.

Син бит минем аерылмас җаным,
Вакытлыча өзеп алынган.
Урынына көтү ялганган да
Инде көтә-көтә арылган.

Син бит минем аерылмас җаным,
Вакытлыча гына алынган.
Әй көттерә заман, юксың һаман,
Әллә авыз ачып калынган.

Син бит минем аерылмас җаным...

* * *

Сагышларым баштан ашкан,
Һичбер кайчан үтәре юк.
Син дәрьяның аръягында,
Дәрья ташкан, күпере юк.

* * *

Исемеңне комга яздым,
Давыл чыгып, комнар тузды.
Күккә яздым, җәйгор итеп,
Аркыч-торкыч яшен сызды.

Шәүләңне мин суга яздым,
Суны каплап болыт ятты.
Көн битенә төшергән идем,
Караңгы төн килеп япты.

Бер юаныч таптым кинәт —
Шунда гына җаным тынды.
Җирдә беркем сыза алмый
Йөрәгемнән синең сынны.

* * *

Күз алдымда: күзләремә карап
(Кабатланып тора, тора ул),
Җаның бармы, диеп сорагандай:
— Мин ничәнчең? — диеп соравың.

Беренчесе микән, соңгысымы —
Күз алдымда янды мең чаткы:
Син меңенче булыр идең һаман,
Сөю китеп, килсә мең тапкыр.

* * *

Сине көтеп, шул сәгатьтә
Таш сын сыман горур торам.
Үткенчеләр, көнләшепме,
Карашларын миңа бора.

Көттерәсең, вакыт үтте,
Ары барам, бире барам.
Синең килер якка табан
Китәм, дим дә кире барам.

Шундый мәлдә тик берәүнең
Бер карашы харап итә;
Гүя мине һәр үткенче
Мыскыл итеп карап китә.

* * *

Сөю мине урап үтәр,
Читләп үтәр дигән идем дә.
Бөтенесенә күнеп бетеп,
Башым басып килгән идем дә.

Ниһаять, мин гашыйк булдым,
Бар дөньяга җитте уты.
Төнне балкытырга мөмкин,
Шәмдәй итеп мине тотып.
Мин өлгердем, соңлый күрмә,
Сөюеңә ашык, кешем.
Мәхәббәтсез кеше ярты,
Чын Кеше ул — Гашыйк Кеше.

* * *

Синә рәхәттерме — киттең бардың,
Кыенрак — торып калганга.
Бөтен нәрсә сине хәтерләтә,
Һәр адымга сагыш ялганган.

Син нәрсәләр уйлый торгансыңдыр,
Сагышыңны искә алганда.
Алар булмасалар нишләр идем,
Әле дә сагышларың калганнар.

* * *

Өметләрем акланмый да,
Өмет өзми көтәм көн дә.
Алдансам, мин алданыймчы,
Син алдана күрмә миндә.

Бәлки, мин дә ялтырармын,
Күзең явын алып нинди.

Алдансам, мин алданыйм ла,
Син алдана күрмә миндә.

Ялгыш бастым күп мәртәбә,
Абайлап бас инде син дә.
Алдансам, мин алданыймчы,
Син алдана күрмә миндә.
Дөнья — ялган. Төп башына
Утыртырга мөмкин кем дә;
Алдансам, мин алданыйм ла,
Син алдана күрмә миндә.

*** * ***

Барчасыннан күпне күргән кебек,
Сукыр кебек берни күрмәгән;
Гүя әле берни кичермәгән,
Хак язмышын җанга үрмәгән.

Күңелләрдән күңелләргә күчеп,
Баса-баса төрле эзләргә,
Чыктым бөтен дөньялардан — сине,
Синнән бар дөньяны эзләргә.

*** * ***

Син гадәти җирдән түгел сыман,
Әйтерсең син башка бер чордан:
Минем күптән күнегелгән илгә
Башка дөнья сине очырган.

Күзләреңне күреп, куанычтан
Тамагыма төер тыгыла:
Күрмәгәнсең әллә хыянәтләр,
Очрамаган ыгы-зыгылар.

Шундый сафлык төпсез карашыңда,
Гүя күзең яңа ачылган.
Минем утлар, нәкъ шуларны көтеп,
Ничә янып, ничә басылган.
Әллә син дә, күрмәгәнне күреп,
Яңа гына күзең ачтыңмы?
Очар өчен яңа җиһан эзләп,
Иске дөньяң ташлап качтыңмы?

Оҗмах көтмәс, беләм. Яңа язмыш
Бер көлдерер, берчә елатыр.
Алдыбызга яшәлмәгән гомер,
Яңа җиһан, яңа ил ятыр.

*** * ***

Бик килешә, дисең, шулай,
Ак чәчләрең — ап-ак көе;
Көләсең син, көлдәй булсын
Минем ялкынымда көеп...
Теләк тә юк, чара да юк

Ак чәчләрне каралтырга;
Мөмкинлек юк яшәрергә,
Хокукым юк картаерга.

* * *

Кояшның бу кыздыруы,
Җирнең мәңге әйләнгәне —
Һич сер түгел, мәңгелек сер —
Юлым сиңа бәйләнгәне.

Мин югалып калган чакта,
Сагыш дәрьялары кичеп,
Күп меңнәрнең арасында
Син тукталдың миңа ничек?

Бер карашың белән бары
Бар дөньямны бер иттең син.
Күз ачып йомган арада
Үлгән җирдән терелттең син.

Таш бәгырьле бу дөньяда
Күпме ут-су кичелмәсен,
Җиһаннан зур сер булып кал,
Серең мәңге чишелмәсен.

* * *

Мең мәртәбә уйламаскамы дип,
Мең мәртәбә куркып тукталам.
Уйларымнан уелып китәр чакта,
Башка уем барда, юкта да.

Сине уйлаганда, кояш балкый,
Җир терелә кайнар буына.
Син уемнан чыксаң, җылы бетә,
Күз алдымда галәм суына.

* * *

Бу дөньяда бөтен нәрсә
Сөю өчен яратылган.
Тик гашыйклар әллә нигә
Адашкан да таратылган.

Берәүләрне кавыштыра,
Сарыларга сабыштырмый.
Берәүләрне һичкайчан да
Бер-берсен табыштырмый.
Безне дә бит очраштырды,
Гомер үтте дигән чакта.
Эзләнгәнбез әллә каян
Син бер якта, мин бер якта.

Күз күреме араларга
Ярты дөнья урап килдек.
Әле дә юллар ялгышмаган,

Юллар менә туры килде.

Һаман саксыз — рәнҗетмәскә
Язмышларын башкаларның;
Безнең бәхет булмасын дип,
Сызлануы башкаларның.

Кем борчыла безнең хакта —
Уйлый микән меңнең бере.
Без уйлыйбыз кеше хәлен —
Безнең хәлгә кемнәр керер,
Безнең хәлгә кемнәр керер.

* * *

Беләм сиңа хат бармасын,
Беләм сиңа ат бармасын.
Язсам ничек барыр иде,
Атым җитми арыр иде.

Сәбәбе һич хатта түгел,
Минем җигәр атта түгел.
Син бит миннән хат көтмисең,
Ярсып килер ат көтмисең.

* * *

Мин — хыялый, мин — куктәмен,
Җирдә түгел аягым.
Без кавыштык хыялларда,
Ходай белә аръягын.

Мин — хыялый, мин — куктәмен,
Патшалардан олымын.
Минем кулдан килмәс эш юк,
Мин — мәхәббәт колымын.

* * *

Мине кемең итәр идең икән,
Әгәр кулларыңнан килгәндә.
Әйтмә миңа, әгәр белмәсәң дә,
Әйтмә миңа, әгәр белсәң дә.

Мин үземне беләм: беренә дә
Икеләнмәм хәзер бер дә мин:
Баш очында янган кояш та мин,
Аяк астындагы җир дә мин.

* * *

Безнең араларда еллар ята,
Юллар ята безнең арада.
Шушы араларны якынайтып,
Кем алыр соң безне аралап.

Безнең араларда таулар тора,
Аулар тора куптән корылган.

Мәхәббәт һәм намус кебек иң саф
Кояш кына безгә борылган.
Бөтен нәрсә безне аерса да,
Безне кавыштырмас ара юк.
Без икебез ике якта, ләкин
Инде аерырлык чара юк.

*** * ***

Эзләгәнмен сине гомер буе,
Сиңа гомер буе килгәнмен.
Нәрсә уйлап, кемне көттең икән,
Җирдә барлыгыңны белгәнмен.

Бөтен эзләгәнем синдә булган,
Синдә булган бөтен көткәнем.
Каян белеп очраштыра язмыш
Көтәр әмәлләрем беткәнен.

Җаным хәзер ничек түзәр икән,
Башка сыймый фараз итүе.
Калган гомер — сине югалтуым,
Калган гомер — синнән китүем.

*** * ***

Бик якында сыман кара шәүлә,
Бик еракта сыман якты сын.
Әллә кемнең күләгәсе төшә,
Әллә кемнең төшә яктысы.

*** * ***

Быелгы яз юлдан яздырамы,
Юлга чыгарамы тизрәк.
Күптән көткән караш төбәлде дә,
Торам шуннан җаным изрәп.

Шул карашны һич югалтмас өчен
Юллар бик күп, түгел аз санда.
Нинди юрау булсын, язык булмас
Мәхәббәтсез юлдан язсам да.

*** * ***

Син утырып киттең тыныч,
Тик калдырып бөтен утны.
Ул ялмады бар дөньямны,
Әллә нинди янгын купты.

Әйләнеп кил, мин дөрлимен,
Утны сүндерергә кире.
Мин сөялгән агач яна,
Мин баскан таш ага эреп.

*** * ***

Барчасы да сәер иде,
Алар безгә шикле иде.
Барчасы да хикмәт көтте,
Тик безнең сер бикле иде.

Барысы да ачык хәзер,
Яшренмибез, бикләнмибез.
Һаман дөнья шикле карый,
Тик без икәү шикләнмибез.

* * *

Синең яшьлек елларыңны уйлап,
Дөрләп китә һәрчак хәтерләр.
Урын да бар, иркәм, бу очракта,
Соң бит инде, диеп әйтергә.

Бер кайтырга иде шул елларга,
Айга, көнгә түгел — сәгатькә.
Мөмкин булса, табар идем бүген,
Табар идем мең төр сәбәпләр.

Кадерләрен белми узган еллар
Синең сөю, минем сөюнең.
Мин туктамас утлар эчендәмен
Ялкыныннан соңлап көюнең.

Аны ничек аңлатырга белми,
Эчтән генә көн-төн сыгылам.
Мин уемнан көннәренә ничә
Тезләреңә килеп егылам.

* * *

Бар авылны каратырлык
Матур булып булмады.
Сабантуйда алга чыгар
Батыр булып булмады.

Ләкин соклана белдем мин
Авылдагы матурга.
Кирәк чакта куәт бирәм
Миннән көчле батырга.

* * *

*Кәтибә Кинҗәбулатовага*

Әниеңме, диеп сорасалар,
Әйе, димен горур мин һәр җирдә.
Тыңлаганнар моны, түгелдер, дип
Әйтмәделәр әле миңа бер дә.

Туганыңмы, диеп сорасалар,
Әйе, димен, күзгә туры карап.
Үзем шулай якын күргәч һәрчак,
Туганыңнан туган булгач ара.

Апаңмы ул, диеп сорасалар,
Уйлап тормый, әйе, апам, димен.
Һич тә үлән үсмәс сукмагыма,

Тупсасын бит байтак таптыйм, димен.

Якташыңмы, диеп кызыксына,
Туган җиребезне күпләр сорый.
Без икебез ике кыйтга түгел,
Урал мәңге тоташтырып тора.

Кешеләрне кеше итү уе —
Әйткән сүзе, җиргә түккән көче.
Хәсрәтләрне бергә хәстәрләүдә,
Кайгыларны җиңеләйтү өчен.

Ул ким түгел һич тә әниемнән,
Һич тә апамнан һәм туганымнан.
Эчләремне күпме бушаткан бар,
Чайпалырдай күңел тулганында.

Тынгы бирми тик бер борчылуым:
Исеменә лаек микән эшем?
Миңа гына түгел, ул меңнәргә
Чын ана һәм апа булыр кеше!

*** * ***

Ак каеннар язга кереп бара,
Бил тиңентен бозлы су кичеп.
Ярларыннан ашкан ташкын сыман
Ташып чыкты нигә бу хисем?

Ак каеннар язга кереп бара,
Фәрештәдәй ап-ак тәннәре.
Читлегеннән чыгып очар сыман
Дертләп кенә торган җаннарым.

Ак каеннар язга кереп бара —
Сабыр гына ап-ак сылулар.
Күзекмәсен инде гәүдәләре,
Кызмасын күз дөнья елудан.

Ак каеннар язга кереп бара,
Күз сирпегәнче күзең камаша.
Телләреңнән һич яздырмас димә
Менә шушы сүзсез тамаша.

Ак каеннар язга кереп бара,
Белми мизгел ничек узасын.
Алар бүген төшендә дә күрми
Сары яфраклары тузасын.

Ак каеннар язга кереп бара,
Кара чәчләремне агартып.
Каеннардан туган ак хисемне
Җыя алмый торам таратып.

Ак каеннар язга кереп бара,
Бил тиңентен бозлы су кичеп.
Ярларыннан ашкан ташкын сыман
Ташып чыкты нигә бу хисем?

## Кыр казлары

Кыр казлары китә, дөнья моңсу,
Китә алар әллә кайларга.
Каңгылдашып, саубуллашып китә,
Көнгә түгел, озак айларга.

Оча алар шәфәкъ өсләреннән,
Куркам, канатлары өтелер;
Бу ашкынган җаннар, күрмиенчә,
Гүя кыяларга төртелер.

Кыр казлары йорт казлары түгел,
Өйрәнмәгән кулга, курага.
Оча алар әзер сыман әнә
Җирне әллә ничә урарга.

Син дә, сылу, кыр казлары кебек,
Тыя алмас чик тә, бикләү дә.
Тарта сине гелән киң офыклар,
Кояш астындагы битләүләр.

Өрекмисең син тормыш утларыннан,
Канатларың янса, көйсә дә.
Авыз ачып карап торучылар
Күрә алмаса да, сөйсә дә.

Дәртләндереп вакыт оча алдан,
Йөрәккенәң китә канап та.
Син ярсусың, син беләсең, күктә
Тик очканда ныгый канатлар.

## Салаватстан*

*(Җыр)*

Башкорт җире, башкорт иле,
Күргәннәрең баштан ашкан.
Батырларың түккән каны
Әй, Йөрүзән булып ташкан.

Салаватстан — чал тарихлы,
Тартып торган горур як.
Үткәннәргә, киләчәккә
Һәйкәл сыман торыр як,
Тартып торган горур як.

Безнең бәхет: сөю, хезмәт;
Тулы бәхет һаман даулау;
Салаватның хыялларын
Тулысынча тәмам яулау.

Салаватстан — чал тарихлы,
Тартып торган горур як.
Үткәннәргә, киләчәккә
Һәйкәл сыман торыр як,
Тартып торган горур як.

Балкый тормыш, җилә вакыт,
Заман бүген ярсу аттай.
Данлы батыр варислары —
Сынатмаслар салаватлар.

Салаватстан — чал тарихлы,

Тартып торган горур як.
Үткәннәргә, киләчәккә
Һәйкәл сыман торыр як,
Тартып торган горур як.

## Асыл ирләр җирдән киткәндә

*Шәриф Биккол истәлегенә*

Җирдә гүя җырлы чишмә тынды,
Балкып торган йолдыз атылды;
Табанымнан җир таешып китте,
Кулымдагы гәлсәр* ватылды.

Күзге кояш һич күзгечә түгел,
Күн кыздыра — җанда җылы юк.
Бар дүрт тараф әллә кара томан,
Кайгылардан чыгар юлы юк.

Тормыш аянычлы йөрәкләргә
Арынмаслык әрнү-моң яга.
Югалтулар, бетмәс югалтулар,
Болай да бит моңсу дөньяга.

Тагын ятимсерәп калдык инде
Синең яшәлмәгән елларда.
Кинәт киләчәккә уздың киттең
Озак телдән төшмәс җырларда.

Ничек итеп күңел юатырга,
Кайгылардан ирен кипкәндә,
Якты кояш тотылгандай була,
Асыл ирләр җирдән киткәндә.
*** * ***

Ничәнчесе икән — исәбе юк,
Бу, мөгаен, соңгы артылыш*.
Күнем кичләп бара, юлым байтак,
Китәм әле алга тартылып.

Тау артында әнә ерак ут бар,
Бер эт өрә анда абалап.
Кинәт күктә йолдыз атылды да,
Баш очыннан очты ябалак.

Юлда бер мин түгел, Ходай үзе
Ярдәм итсен минем ишегә.
Мин табынып юлны дәвам итәм
Эткә, утка, очрар кешегә.

## Автор турында белешмә

Ирек Лотфи улы Киньябулатов 1938 елның 15 июлендә Башкортстанның Кырмыскалы районы Абдулла авылында туа. Башлангыч мәктәпне үз авылында тәмамлагач, күрше Иске Бәпес урта мәктәбендә укый. Дүрт ел Кара диңгез флоты корабларында рулевойлар командасы старшинасы сыйфатында диңгез, океаннарда йөзә, аның исеме хәрби корабның Почет кенәгәсенә кертелгән, ул — запастагы хәрби диңгез флоты офицеры.

Хезмәтен тутыргач, Башкорт дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала. Башкортстан радиосында эшли. Алга таба иҗади һәм журналистлык хезмәтен «Совет Башкортстаны»

газетасы редакциясендә, байтак вакыт Урал аръягы районнарында үзхәбәрче сыйфатында дәвам иттерә. «Агыйдел», «Һәнәк» журналларында, «Китап» нәшриятында эшли. Озак еллар Башкортстан Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау бюросы директоры була.

Ирек Киньябулатов мәктәптә үк шигырьләр яза башлый. Аның беренче шигыре 1953 елда, җиденче класста укыган чакта, «Пионер» журналында басылып чыга. Университетта «Шоңкар» әдәби-иҗат түгәрәгенең старостасы була.

«Басу юлы» дигән беренче шигырьләр китабы 1970 елда чыга һәм шигърият сөючеләрнең күңелен яулап ала. «Сыерчыклар бала очыра», «Сөю иртәсе», «Мин — башкорт!» исемле китаплары башкорт шигъриятенә үзенчәлекле, үз тавышлы шагыйрь килүен күрсәтә. «Аргамакта» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы башкорт шигъриятендә яңа күренеш буларак бәяләнә. Ирек Киньябулатов шигырьләренә һәм поэмаларына югары гражданлык, ил-тел тойгысы һәм нечкә лирика хас. Ул киң даирә укучыларына үтемле публицист һәм очеркист буларак та билгеле.

Ирек Киньябулатов — Мөхәммәтсәлим Өметбаев, Мәҗит Гафури, Зәйнәп Биишева, Фатих Кәрим, Рәми Гарипов, Сергей Чекмарев исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Башкортстан Республикасының мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

## Эчтәлек


Шагыйрь гомере — утлы күмер... *Х.Әюп* .............

**«Басу юлы» китабыннан (1970)**

Җирем ...................................
Сагынып кайтам җиремне .......................
Буразна ..................................
Тәүге яңгыр *(этюд)* ...........................
Басу юлы ................................
Өч торна ..................................
Ялбыр каен ................................
Урам көе .................................
Синең аша .................................
Сабантургай ...............................
Гомер ....................................
Яңа елга аяк басканда ..........................
«Су-күл чагы җитте тагын...» .....................
«Язын кар китсә...» ...........................
Киләчәк ..................................
Йолдызлы җир ..............................
Борчак яңгыр ...............................
Кыяларда ................................
Уралда таң ................................
Искән җилләр ..............................
Һаман ут яндырып ............................
«Тик гашыйклар йөрер сәгатьтә...» .................
Акъярда .................................
Байрак төсе ................................
Бүгәслетау — Җаек ярында ......................
Туган көнем ................................
Казлар китә ................................
Биеклекләр тартсын ...........................
Уралда кич ................................
Рәхмәт, буран! ..............................

**«Сыерчыклар бала очыра» китабыннан (1973)**

Бурычым бар ...............................
Йокыларым кача .............................
Төшлектәге кояш .............................
Ашыгам ..................................
«Йөрәгем очарга омтыла...» ......................
Синең аша күрәм .............................
Ялгыш бастым... ............................
Агымсу ...................................
Шатлык килә ...............................
Иртән яуган карлар ...........................
Имән ауды ................................
Нигә әле... ................................
Синең йөрәгең... .............................
Килермен .................................
Вакыт җитми ..............................
Ана әманәте ...............................
Канатлар оча җил белән ........................
Бәләкәй Шәүрәгә ............................
Ел чатында ................................

Язгы һава .................................
«Әллә ничек үтә вакыт...» ........................
Әти кулы .................................
Каенлыкта .................................
Апрель йөри ................................
Рәхмәт сүзе .................................
Ерак ара ..................................
Кичке сер .................................
Кышкы юлдан ..............................
Көтмәгәндә .................................
Яфрак яндыралар .............................
«Тагын яшен, тагын яңгыр...» .....................
Әйгә киләм ................................
«Өзә сугар яфрак җиле исә...» ....................
Чәчкәләр .................................
«Булсын сөю ачык диңгез сыман...» .................
Үз нурларын кайтар ............................
Ядәч аерыштык .............................
Сыерчыклар бала очыра *(Лирик поэма)* ..............
**«Сөю иртәсе» китабыннан (1988)**

Хәерле иртә! ................................
Вакыт оча ярсып .............................
Куанам ...................................
Дуслык төяге ...............................
Йөрәк яше .................................
Җирем — ак дәфтәр ..........................
Иске Бәпестә сугыш корбаннарына куелган обелиск янында .
Чыршы тургайлары ...........................
Мизгелләр ................................
Юлда ....................................
Аюлар ...................................
Кыска көннәр ...............................
Бәрәңге чәчкәләре ............................
Башкалар шикелле ...........................
Уңдык ...................................
Әбиләр чуагы ...............................
«Көн авышып килә. Ниләр эзләп...» ................
Киек казлар тавышы ..........................
Урал курае ................................
«Кичнең шәме — ерак айга бактым...» ...............
«Көтмәгәндә туктатты бер телсез...» ................
«Тәрәзәмнән тышка караем...» ....................
Сөю иртәсе ................................
Сүз солтаны ...............................
Карлар булып... .............................
Җир ярасы ................................
Ак яңгырлар ...............................
Сибай ...................................
Уен кыска икән ..............................
«Синең шундый матур чагың иде...» ................
Яңабаштан ................................
«Эчем поша: төркем бүз тургайлар...» ................
«Агыйделдә актарылып ага...» ....................
Чыкты ...................................
«Мине таңда уятмагыз...» .......................
«Башка берәү гөнаһына...» ......................
«Ян тәрәздән тургай карады дип...» ................
Көйгән каен ................................
«Беләм хәзер, җаның сызланганда...» ................
«Гөлдән яфрак очып төште...» ....................
«Күпме яшәлде вакытлыча диеп...» .................
«Язгы сулар, сәер бүлешеп...» .....................
Гомер яфраклары ............................
Ут алырга кайтам ............................
Җәй уртасы ...............................
Кайтты батыр туган җиренә ......................
«Ашыкмагыз сукранырга...» .....................
Дустыма кырык тулганда .......................
Гомер үтә, дибез .............................
Тагын теләп ................................
Юл яфрагы ................................
Яшен кайтаргыч .............................
Әти җыры ................................

Үскән саен ................................
«Тагын ялгыз ятам. Баш очымда...» .................
Туган төяк ................................
Йолдыз җитми кебек ..........................
«Учлап-учлап кулга туфрак алам...» ................
«Их, яшьлекнең яшел чагы...» .....................
Хак ....................................
Өлгермәдек рәхмәт әйтергә ......................
Учак ...................................
Өлге ...................................
Тоз сибәләр ................................
Кош юлы ................................
Баймак ягы ................................
Авылымның олы юлы ..........................
«Иртүк түгеп яңгыр коя...» .......................
«Барысын да әйтеп бетмимендер...» .................
Уем да юк ................................
Тик көтәм ................................
«Син бит бәләкәчсең, дисең миңа...» .................
Язмыш ..................................
Антлар аша ................................
Зарланма! ................................
Җәяүле буран ..............................
Ир канаты ................................
Бүген тагын ................................
«Кичтән генә әле көзге бакча...» ...................
«Дөнья, синнән күпме сорамыймын...» ...............
Төшсен кояш күзләремә ........................
Бары бер сабак ..............................
Учак янындагы уй ............................
Еллар безгә баккан ...........................
Синең елмаю ...............................
«Күз алдында ятып айгыр үлде...» .................
Май яңгыры ...............................
Җыр яшәсә ................................
Хәйбулла ................................
Самолетта ................................
«Күрәсем килә һәммәсен...» ......................
Синең белән минем кебек ........................
Төштә ..................................
Алачагым калсын... ...........................
Киткәнемдә ................................
Икмәк ..................................
Әкиятләр түгел ..............................
Йөрәкләрдә калыр сүз .........................
Ир сүзе .................................
Туган җиргә ...............................
«Бик борыннан, кайбер чакларында...» ..............
Габҗәлил ................................
«Әле генә гөрләп язлар үтте...» ....................
«Февраль, сиңа нәрсә җитми иде...» .................
Күңел талмас Талкаста ........................
Кич көймәдә ...............................
«Тәүге сөю онытылмый, диләр...» ..................
Сүз ....................................
Кылганнар ................................
Янгантауда ................................
«Кеше туа бер-берсе өчен...» .....................
Мирас ..................................
Үтечкә ..................................

**«Мин — башкорт!» китабыннан (1993)**

Салават һәйкәле .............................
«Иң мөһимен генә яз син!..» ......................
Егерменче гасыр .............................
«Иркәләнер иртәләрем бар, дип...» ..................
Мин — башкорт! .............................
Табыннарга ................................
Нигә икән? ................................
«Яндыруы булган күптән...» .....................
«Беркем сизмәгәнне, тоймаганны...» .................
Хыялый .................................
Баш очында торам ...........................

«Җирдә һаман каты сугыш бара...» ..................
Сорау ...................................
Олы Теләк. 1710 нчы чакрым .....................
Рәми ....................................
Шагыйрь .................................
Ураза ...................................
Базар ....................................
Минем исем ................................
«Мин үземне-үзем сакламадым...» ...................
«Яшьлек узган, буяулары тузган...» ..................
«Дан һәм шөһрәт юлы...» ........................
«Өлкәннәр безне алдады...» .......................
«Авыр чакта мин урманга килдем...» .................
«Миңа шундый гаҗәп төшләр кирә...» ................
Кан хәтере .................................
«Башкортстан — байлык, хәзинәләр...» ................
«Җитәрлек күрсәтте бу дөнья...» ...................
«Алып качкан атлар күргәнем бар...» .................
Атларга атланыйк! ............................
Кара атлар — ак бәхеткә ........................
Илне сагыну ...............................
Елкы елы .................................
Шарлавыкта бию ............................
Мәңгелек ут ...............................
Сорау алу .................................
Торатау итәгендә .............................
Чөнки ...................................
Мин — тоткын ..............................
«Инде бетте, син бит шуны көттең...» .................
«Аңламыймын, язмыш кая сөйри...» ..................
«Һәммәсе дә бу дөньяда...» ......................
Үзебезнең абыйлар ............................
«Бәхетле дә, бәхетсез дә түгел...» ...................
Саташумы? ................................
«Күзләр телдән артык сөйли...» ...................
Ул бирүзе .................................
«Бөтен серләр ачыкланыр, дидем...» ..................
«Адым саен шигырь эзләмәдем...» ...................
«Яшьлектәге савапларга торыр...» ...................
«Мондый югалтудан, бу кайгыдан...» .................
«Балачакның ерак хатирәсен...» ....................
Язмышыбыз ...............................
Туксанбай .................................
«Аңламассың инде бу дөньяны...» ...................
«Кая бакма — кайный сүз боткасы...» ................
«Бөтен язмыш кыл өстендә тора...» ..................
Үземә сораулар ..............................
Кыйгыда ..................................
«Һәммәсе дә кирәк. Бик тиз кирәк...» .................
Бөек күрәзәче ...............................
Кадимге дус ...............................
Елмаю ...................................
Көрәш келәме ...............................
Төштә күргән Күк Бүре .........................
Бер төркем иптәшләре .........................
«Бала чакта көн дә исәпләдек...» ....................
«Адым саен йөрәк сызлатырлык...» ..................
«Мин түрдә дә...» .............................
Сәхнә түгел, җир чайкалды ........................
«Нигә әле миңа акланырга...» ......................
Илленче җәй ...............................
Утыз сигезләр ..............................
Йоклау һәм йокламау ..........................
Телсез таулар... .............................
Тик бер кабат ...............................
Ялгыз түгел ...............................
Кешеләргә чыгам ............................
Уклыкыя .................................
Йөргенчеләр сыман ...........................
Дәүләкән .................................
Уфа вакыты ................................
«Төрле чаклар була, калкып тора...» .................
«Мин үтәлмәс вәгъдәләрдән туйдым...» ................
«Су аккандай бик тиз ага гомер...» ...................

Кешеләр җирдә балкый .........................
Яхшылык .................................
«Яхшылыгым — әниемнән...» ....................
Аягөсте басып ..............................
Чарасыздан чарага ...........................
Туган телем ................................
Чакырсаң .................................
Яңа туган бала елавы ..........................
«Бу юлдан, дим, кемнәр йөрмәгәндер...» ...............
Йөрәк синең белән ............................
Борҗан халкы ..............................
Заповедник ................................
Шүлгәнгә кергәндә ...........................
Сыймыйча сәхнәләргә .........................
Инсебикә кыясы астында ........................
Яндырылган Алдар авылы .......................
Урманның аюларга эндәшүе ......................
Аптырап калма, дустым! ........................
Нокытчыга килү .............................
Узган гомер ................................
Алты яшьлек җырчы кыз .......................
Бабсак батыр каберендә .......................
Канатсыз да очып ............................
Таңгы чык кичкәндә ...........................
Борҗан эте ................................

**«Аргамакта» китабыннан (1998)**

«Бер уйласаң, тагын нинди ирек...» ................
Йөрәктәге һәйкәлләр *(Поэма)* ....................
Баллада ..................................
Галәм сакчысы *(Поэма)* ........................
Көзге сагыш ................................
«Кичен ятсам, иртән торсам...» ....................
Курайга һәйкәл ..............................
Зурерактан күренә ...........................
Ил агасында ...............................
Авырайган чакта адымнар .......................
«Мин — янгыннан торып калган кеше...» .............
«Бу тормышны бераз рәтләр өчен...» ................
Йокысызлык ..............................
«Бер кәккүктән килер көннәремне...» ................
Үтәгән ..................................
Меңле дигән исемеңне .........................
Син югалдың ...............................

**Гашыйк Кеше — чын Кеше**

«Синең йөзең күз алдыннан китми...» ................
«Күңел — туп-тулы...» .........................
«Мин кояшның чыгышында...» ....................
«Иң озын төн хәтта җитмәде бит...» .................
«Минем күңел булсын дипме...» ...................
«Бөтен дөнья ап-ак булды...» .....................
«Иң-иң татлы төшләр онытылды...» .................
«Икәү үткән юлдан барам...» ....................
«Өметләнәм зәңгәр һавалардан...» ..................
«Кайгырдым мин карурманда...» ...................
«Бөтерелеп карлар ява...» .......................
«Мин яклаусыз, мин саклаусыз...» ..................
«Син бит минем аерылмас җаным...» ................
«Сагышларым баштан ашкан...» ..................
«Исемеңне комга яздым...» ......................
«Күз алдымда: күзләремә карап...» .................
«Сине көтеп, шул сәгатьтә...» ....................
«Сөю мине урап үтәр...» .......................
«Сиңа рәхәттерме — киттең бардың...» ...............
«Өметләрем акланмый да...» .....................
«Барчасыннан күпне күргән кебек...» ................
«Син гадәти җирдән түгел сыман...» .................
«Бик килешә, дисең, шулай...» .....................
«Кояшның бу кыздыруы...» ......................
«Мең мәртәбә уйламаскамы дип...» .................
«Бу дөньяда бөтен нәрсә...» .....................
«Беләм сиңа хат бармасын...» .....................

«Мин — хыялый, мин — күктәмен...» ................
«Мине кемең итәр идең икән...» ...................
«Безнең араларда еллар ята...» ....................
«Эзләгәнмен сине гомер буе...» ....................
«Бик якында сыман кара шәүлә...» .................
«Быелгы яз юлдан яздырамы...» ..................
«Син утырып киттең тыныч...» ....................
«Барчасы да сәер иде...» ........................
«Синең яшьлек елларыңны уйлап...» ................
«Бар авылны каратырлык...» .....................
«Әниеңме, диеп сорасалар...» .....................
«Ак каеннар язга кереп бара...» ....................
Кыр казлары ..............................
Салаватстан ...............................
Асыл ирләр җирдән киткәндә .....................
«Ничәнчесе икән — исәбе юк...» ..................

Автор турында белешмә ........................

Литературно-художественное издание

**Кинзебулатов** Ирек Лутфиевич

## Курай Урала

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Киньябулатов** Ирек Лотфи улы

## Урал курае

Башкортчадан *Х.Г.Әюпов* тәрҗемәсе
Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *З.З.Хәкимов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.06.2008.
Форматы 70r100 1/32. Шартлы басма табагы 14,95.
Шартлы буяу-оттиск 15,28. Нәшер-хисап табагы 12,87.
Тиражы 2000 д. Заказ Т-667.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.